www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 31 (1396) 12 август 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

12

Казан Кирмәнендәге Татар шәмаиле йортын бетерү дә халкыбыз өчен тагын бер зур югалту булды.

16

Рәссам Павел Беньковның хәзер Үзбәкстан сәнгате музеенда сакланган картинасында кем сурәтләнгән?

19

Илһам Шакиров исемендәге бүләкне беренчеләрдән булып алган җырчы Резеда Галимова тыйнаклыгы да сокланырлык.

Гармун күрегеннән саркылган моң Мең шифадыр безнең җаннарга!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Казан халыкара мөселман киносы фестивале 2 млн сум күләмендә федераль грант алуга ирешкән.
- Татарстан Премьер-министрының урынбасары – Татарстанның Россиядәге Тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин Мәскәү дәүләт университеты профессоры Ижат Сабитовка Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан истәлекле көмеш билге тапшырды.
- Бер төркем татар язучылары Әмирхан Еники хикәяләре буенча фильм төшерүдә катнашты.
- Арча районы Иске Ашыт авылы мәдәният йортына ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның халык артисты Фердинанд Фәтхинең әнисе Саяра Фәттерахманова исеме бирелде һәм истәлек тактасы куелды.
- Олы Әтнә авылында урнашкан «Туган якны өйрәнү» музеенда ремонт эшләре башланды.
- Аксубайда Татарстан һәм Россия рәссамнарының ике атналык пленэры тәмамланды.
- Чаллы картиналар галереясында ДЦП авырулы рәссам, картиналарны кулсыз ясаучы Ренат Мусинның шәхси күргәзмәсе ачылды.
- Әтнә районы Кышлау авылында Арча, Биектау, Балтач районнарыннан һәм Мари Эл республикасыннан килгән үзешчән коллективлар катнашында «Җиз самавыр» фестивале узды.
- Мамадыштагы урамга Дәүләт Думасының элеккеге депутаты, быел июнь аенда вафат булган Фатих Сибагатуллин исемен бирү планлаштырыла.
- Алабугада яшь рәссамнарның «BASHNYA» Халыкара иҗат лабораториясе узды.
- 27 августта «Черек күл» паркында узачак «Слэм» бөтенроссия заманча шигърият фестивалендә публицистлар, шагыйрьләр һәм әдәби конкурслар лауреатлары чыгыш ясаячак.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Әзһәр Шакиров, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты:

«Артист әшәке кешене уйный икән, тамашачы аның турында: «Үзе әшәке булмаса, аңа шундый роль бирмәгән булыр иделәр» дип уйлый. Яхшырак уйнаган саен сез моңа тагын да ышана төшәсез.

Мин беркайчан да тамашачы яратсын дип уйнамадым. Рольләр дә шундый иде. 25 яшемдә 60 яшьлек картларны уйный идем. Җыен әшәке һәм явыз кешеләрне уйнадым. Андый артистны нинди тамашачы яратсын?! Мин үзем дә андый артистны яратмас идем».

СЫНАМЫШЛАР

14 августтан (Бал Спасы) салкын чык төшә башлый; мәк уңышын җыялар● 15 августта көн нинди булса, сентябрь буе шундый була● 16 августның һава торышы октябрьнең нинди булачагын күрсәтә; көчле җил иссә, карлы кыш көтелә●17 августта нинди көн булса, ноябрьдә һава торышы шундый була● 18 августта көн нинди булса, шундый ук декабрь көтелә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 08 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 26 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **15 сәгать 18 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **30 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **19 августта 14 сәгать 48 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

12 август – Халыкара яшьләр көне.

14 август – шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әлфия Мирзанур кызы Ситдыйковага 65 яшь (1957).

15 август – шагыйрь Рәхим Сөләйман улы Саттарның (Габделсаттаров) туууына 110 ел (1912–1943);

– драматург, Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Гали улы Мингалимнең туууына 85 ел (1937-2014).

16 август – шагыйрь Рамил Мотаһар улы Чурагуловка 60 яшь (1962).

17 август – эстрада җырчысы, Татарстанның халык артисты Зәйнәп Фазлетдин кызы Фәрхетдиновага (55 яшь) (1967).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(12-19 август)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген мөхәррәм аеның
14 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

ГАЕПЛЕНЕ эзләп йөрисе юк!

Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездында ясаган чыгыш

Хөрмәтле милләттәшләр! Татарстан Республикасының илтәбәр президенты! Һәм җыенебызда читтән катнашучылар!

Бүгенге заманда дөньяның төрле төбәкләрендә яшәүче татарларның бергә җыелуы аеруча әһәмиятле һәм шактый ук гыйбрәтле дә. Бөтендөнья татар конгрессы оешуга 30 ел тулу, һичшиксез, халкыбыз тормышында күренекле вакыйга, һәм чираттагы корылтаебызда без бу датаны билгеләп үтмәсәк сәер булыр иде. Мондый мәрасимнәрдә гадәттә гел мактау сүзләре генә әйтелә, пафоска да җитәрлек урын бирелә, һәм бу, мөгаен, табигый да. Милләт тарихы өчен 30 ел зур вакыт аралыгы булмаса да, без шушы заман эчендә нинди генә иҗтимагый үзгәрешләр кичермәдек, дәүләт тормышында исә нинди генә әверелешләр күрмәдек! Халкыбыз әйтмешли, кем идек, кем булдык… Ярар, үткән-беткән, бүген без, чыннан да, кем соң? Нинди хәлдә икәнебезне аңлатып тору кирәкмидер, ә менә киләчәгебез нинди? Юлыбыз кая? Тукайның яратып әйтә торган сүзе булган: «Мин әле кая барам?» Без әле кая барабыз? Юлыбыз кая? Җавапны без, бәлки, бирелә бергәләп эзләрбез.

Совет чорында «өлкән туган» дигән гыйбарә бар иде. Хәер, чынлыкта, ул бүген дә өлкән инде. Ләкин дөньяда яшәү, үз урыныңны табу – геосәясәттә булсынмы, экке тормыштамы – өлкәннәргә дә кыен булса кирәк; менә ничә гасыр инде аларны ике сорау интектерә: «Что делать?» һәм «Кто виноват?»

Аның беренчесенә урыс философы В. Розанов җавап биреп калдырган. Җәй көне күпләп җиләк җыярга, варенье кайнатырга, ә кышын шул варенье белән чәй эчеп тыныч кына өендә утырырга кирәк, дигән ул. Шул чакта икенче сорауның кирәге дә калмый. Тамагың тук, кәефең әйбәт булса, гаепләне эзләп йөрисе юк…

Икенче сорау безне дә борчымый анысы. Аңа без күптән җавап тапканбыз! Кем гаепле? Үзебез, әлбәттә! Берәү җырлый бит: «Моңайма, кайгырма, ярсыма, Син үзең гаепле барсына». Үзеңне гаепле итеп таныгач, җиңел булып китә, җиләк кайнатмасы белән чәй эчеп, дөньядагы сәясәт белән кызыксынмыйча, тыныч кына өйдә утырасы килә. Ә җиләкне без күпләп җыябыз, татарлар катнашкан социаль челтәрләрдә хәзер гел җиләк – чиләкләп тә, кәрҗинләп тә… Әйтерсең безне бернәрсә дә борчымый, сәясәткә безнең катнашыбыз юк. Башны җиләккә яшерүебез аңлашыла да, шул каһәр төшкән сәясәт аркасында халкыбыз гасырлар дәвамында, бигрәк тә 20 нче гасырда, күпме җәфа чиккән, заман давыллары аны кая гына болгап ыргытмаган. Ләкин бер закончалык бар шул: син сәясәт белән шөгыльләнмәсәң дә, сәясәт барыбер, үзе килеп, синең белән шөгыльләнә башлый.

Шуңа күрә өлкән туганны да борчыган сорау, кәкрәеп, безнең алга да килеп баса: «Нәрсә эшләргә?» Юкса безнең сәяси амбицияләребез юк, без бары тик асылыбызны югалтмыйча, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап, җиләкләп чәй эчә-эчә яшәргә генә телибез. Ләкин бүгенге глобализм шартларында шушы гадәти, табигый максатка ирешү дә гаять авыр икән. Халкыбызның инде яртысыннан күбрәге татарча белми, белгәннәренең дә теле ярым-йорты гына. Чөнки безнең милли мәгарифебез юк кимәлендә, милли мәктәпләр челтәре тар-мар ителде, Бердәм дәүләт имтиханын үз телеңдә бирү мөмкинлеге юк. Ә ФГОС торган саен «камилләшә» бара, инде милли телләргә мәктәпләрдән бөтенләй куып чыгарылу яный. Инкыйразның шәүләсе мәктәпләрдә, урамнарда, эш кабинетларында гына түгел, ә өйләрдә, түр башында киерелеп утыра. Туган телләр рәтенә рус телен кертеп, аны ата-аналарга ирекле сайлау хокукы биреп, бик мәкерле эшләделәр, хәзер күп баланың ата-анасы гына түгел, әби-бабасы да татарча белми. Алар туган тел дигәндә нинди телне сайласын?! Ләкин бит болар – дәүләт тарафыннан ничә дистә еллар дәвам иткән ассимиляция сәясәте корбаннары. Чын федератив мөнәсәбәтләр гамәлдә булган дәүләт үзе үк шул элекке гөнаһларын бетерү юлында эшләргә тиеш иде кебек тә… Ләкин без инде соңгы ун-егерме елда үзәктәге югары җитәкчеләр тарафыннан «федератив мөнәсәбәтләр» дигән гыйбарәләрне дә ишетмәбез юк.

Хәер, нигә бу турыда сөйләп торырга? Татар теле һәм әдәбияты 10-11 сыйныфларда бөтенләй укытылмый. Димәк, безнең балалар әлеге фәннәр буенча урта белем дә ала алмый! Быел бөтен Татарстанга татар теленнән Бердәм дәүләт имтиханын бирдәнбер кыз бала бирде! Шатландык, әлбәттә. Тик утырып еларга гына оныттык. Тиздән бездә язучылар да, татар теле галимнәре дә, артистлар да һәм башка милли кадрлар да булмаячак. Сез беләсез инде, мәдәнияте юкка чыкса, милләт үзе дә юкка чыга. Бу – аксиома.

Дөрес, миңа каршы төшүчеләр булыр. Янәсе, үз-үзеңне нинди милләттән дип танысанда (ягъни самоидентификация булганда), иң мөһиме – кешедәге милли үзаң. Һәм мисал итеп гадәттә Польша-Литва татарларын китерәләр. Алар да бит әнә телләрен бернича гасыр элек югалткан, ә менә ислам динен һәм милли үзаңнарын саклап калган. Әлеге татарларның урта гасырларда ничә дистә мең булганын беләме икән алар? Хәзергеләре шуларның бер нәни кыйпылчыгы гына (бернича дистә!), калганнары тәмам эреп югалган. Әйе, шул кыйпылчык үзен татар дип саный, ләкин кайда аларның фольклоры, милли биюләре, гореф-гадәтләре? Гомум татар мәдәниятенә алар керткән өлеш кайда?

Әйе, милли үзаң зур нәрсә. Әмма без яһүдләр түгел, икенче-өченче буыннарда ул гадәттә тәтен кебек таралып бетә. Телен югалткан татар күп очракта бүтән милләтләргә ашлама гына…

Соң… безгә нәрсә эшләргә?

Әлбәттә, Татарстан җитәкчеләре дә, республикадан читтә тупланып яшәгән татарларның кайбер лидерлары да бу турыда уйлана, мөмкинлектән чыгып конкрет гамәлләр кылырга тырыша. Беренче Президентыбыз Минтимер ага Шәймиев башлангычында полилингваль мәктәпләр булдыру бу юлда зур эш. Минемчә, Бөтендөнья татар конгрессының да эшчәнлегендә әлеге юнәлеш иң мөһиме булырга тиеш. Югыйсә без җырлый-бии белүче өлкән буынга күбрәк игътибар бирәбез шикелле.

Ачыктан-ачык әйтергә кирәк: татарны татардан башка беркем кайгыртмаячак. Былтыр миңа Оренбург Каргалысында булырга туры килгән иде. Анда алар милли тәрбия бирә торган балалар үзәге ачкан. Шундый ук үзәкләр Чуашиянең зур татар авылларында, Пенза өлкәсенең атаклы Урта Әләзән авылында да бар. Хосусый мәктәпләр ачарга менә дигән җирлек!

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен, ата-аналарың да җәләп итеп, якшәмбе мәктәпләре челтәрен барлыкка китерү дә максатка ярашлы булыр иде. Гаилә мәктәпләре. Чөнки татар телен белү җәһәтеннән күп ата-аналар үзләре дә сабый хәлендә.

Каргалыдагы очрашу вакытында бер эшмәкәр: «Мәгарифтә без ерак бабалар тәҗрибәсенә кайтып төшәргә мәҗбүр», – диде. Беләсездер, большевиклар түнтәрелешенә кадәр кимендә 200 ел дәвамында безнең милли мәгариф системасы, дәүләттән бернинди ярдәм алмыйча, байларыбыз, хәлле кешеләребез тырышлыгы аркасында иҗтиһат иткән. Шөкер, татар тырыш халык, байларыбыз әле дә җитәрлек. Мәчетләр салырга акча табыла бит. Бик кирәкле, савапы гамәл. Ләкин хосусый мәктәпләр ачу савабы аннан ким түгел. Ул хокук бит әлеге дә баягы яһүдләргә генә бирелмәгән! Дөрес, аларның артында кодрәтле Израиль дәүләте тора. Тик шунысын да онытмаска, иң мөһиме, федераль җитәкчеләргә онытырмаска кирәк: бүгенге шартларда, Россиянең тышкы сәясәте Үзәк Азиягә һәм тулаем Шәрекъкә борылганда, дәүләткә татарның үз телен белүе, үз асылын югалтмавы файдалы. Моны элекке урыс патшалары бик яхшы аңлаган.

Һәм якын киләчәктә дә Россия Федерациясендә аз санлы халыкларның язмышына карата, иң мөһиме – милли мәгарифкә карата сәясәт уңай якка үзгәрер дигән өмет бар. Ашка каршы таш ату беркайчан да үз-үзен акламаган.

Безгә атаклы миссионер Н. Ильминскийның сүзләрен һәрчак истә тотарга кирәк. Татарны борыңгы заманнардагы кебек көчләп христиан диненә кертергә кирәкми, дигән ул, башта ул телен югалтсын, аннары инде ул иртәме-соңмы динен дә югалтачак. Дөрес, бүген инде тышта XXI гасыр, һәм конфессиональ нигездә безнең милләт эчендә ниндидер зур каршылыклар бар дип уйламыйм. Һәркем үзе телгән динен тотарга хаклы. Динсез булырга да хакы бар. Ләкин уйланырга да кирәк: салган мәчетләребез киләчәктә Аллаһ йорты булып калырмы? Татар һәм мөселман тәрбиясе алмаган яшь буынның юлы кая таба? Мәчетләрне, ерак бабаларыбыз кебек, хосусый мәктәпләр, мәдрәсәләр белән ныгыту кирәклегенә шик юк. Һәм бу җәһәттән әлеге мәсьәләдә күп хәзрәтләребез аңлап эш итә.

Билгеле, бүгенге хосусый мәктәп гомумбелем бирү мәктәбеннән бер башка югары торырга тиеш.

Бер генә халык та үз теләге белән тарих сәхнәсеннән төшеп калырга теләми. Безнең әле яшәү көчебез бар. Бер халык юкка чыгу белән икенче халыкның бәхете артмаячак.

Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллык бәйрәмен дә искә алып, чыгышымны оптимистик рухтагы шигырь белән тәмамлыйсым килә:

Илем! Син һаман шул. Без – шул!
Ул чакта да заман болганган.
Алтын Урда, Болгар… Аваз килә
Бик еракта калган еллардан.
Сыны каткан сыңар манарадан
Яңа азан гүя яңгырый:
Туган җиребездән сихәт алган
Тамыр исән! Нәсел тамыры…
Шытып чыктык тагын үлән сыман,
Көләч таңнар белән юандык.
Буразналар ярдык, йортлар салдык, –
Тамыр тирән безнең, иман нык.
Күтәрелде кабат манаралар,
Яңгырады азан – өр-яңа!
Мәйданнарга чыктык сөлгә тотып, –
Без яшәргә килдек дөньяга.
Аяк тиде Болгар туфрагына,
Борынгыдан калган эзләргә.
Без тезләндек монда. Чын мөселман
Тик сәҗдәгә генә тезләнә.
Без тезләндек Аллаһ каршысында,
Бер ил булып аннан калыктык.
Халык булып кабат чыктык юлга,-
Тамыр тирән безнең, иман нык!
Булса булсын юллар сикәлтәле,
Исемебез барыр югары.
Татар иле! Якты тор, зинһар,
Без үтәсе ерак еллары.

Мәң җидегән
вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

ҮЗОЕШУ

Табигатьтә көзен күпләрнең уникаль бер күренешне күзәткәне бардыр: меңнәрләгән кош, зур гына төркемгә җыелып, күктә кинәт ниндидер гаҗәеп хәрәкәтләр ясый башлый, әле генә болытны хәтерләтеп йөзгән өер, зур бер организмдай кысылып йә җәелеп, төрле формалар ала, синхрон рәвештә һәм кискен генә үзенең хәрәкәт юнәлешен үзгәртә һ.б. Шундый ук үзенчәлекләр судагы балыкларга да хас. Фәндә әлеге күренеш «мурмурация» дип атала. Илаһият кануннары нигезендә кылынган ошбу феноменның серләрен галимнәр әлегәчә ачыклап бетерә алмый: берәүләр аны ерткычлардан саклану янсә аларны куркыту чарасы итеп күрсә, икенчеләре инде азык зонасы турында хәбәрләшү ысулы дип тә саный. Орнитологлар исә күчмә кошларга хас бу күренешне, ерак араларга күчеп китү алдыннан, аларның социализацияләшүе (төркем белән эш итүгә җайлашуы) дип тә аңлата. Күренә ки, илаһият кануннарының кеше акылы колачлый алмаган яклары әле бихисап. Аларны аңлау өчен галимнәргә алга таба да нык тырышырга, бу өлкәдә азау ярырга туры киләчәк.

Ә югарыда телгә алынган уникаль күренешнең илаһи асылы кешеләрне социаль төркем буларак та кызыксындыра. Чөнки, тереклек дөньясының Аллаһ тарафыннан акыл биреп тә зурланган бердәнбер төре буларак, адәми затка аның серләренә төшенү инде үзенә йөкләнгән илаһи миссияне (Җир хуҗасы булу бурычын) тәгәл үтәү өчен дә кирәк. Ә акыл көчен дә эшкә җигеп ихтыяҗ килгәндә, әлеге күренешне ул, җәмгыяви яшәештә дә уңышлы куллана алыр иде. Кошлардан аермалы буларак (ә аларның реакциясе инстинктка гына корылган), адәми зат тормыш яңауларына җавапны, физик хәрәкәт белән генә түгел, ә яшәү рәвешен үзгәртү юлы белән дә бирә ала. Димәк, үз кавеменә хас әдәп вә әхлак кысаларында саклаган хәлдә, ул аны яңауларга илаһият кануннары нигезендә һәм тәңгәл җавап кайтарырлык итеп үзгәртергә, яшәү рәвешенә илаһи динамизм өстәргә тиеш була. Хәлбуки, бүгенге рухи деградация һәм глобаль кризис чорында бу феномен милләтләрнең үзоешу юлында илаһи мисал һәм алыштыргысыз гамәли үрнәк тә булып тора. Шуның белән бергә, андый үзоешу инде адәми затка метасәясәт (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте) югарылыгында да эш итү мөмкинлеге бирә.

Әзерлекләренә карап, җәмгыяви үзоешу дәрәҗәсе төрле халыкларда төрлечә була. Моңа кадәр аның югары формасы булып геосәяси дәрәҗәдәге үзоешу саналды. Бу яктан иң югары нәтиҗәләргә ирешкән милләт, мөгаен – яһүдиләрдер (хәер, моны инде дәлилләп торасы да юк кебек). Шул ук вакытта, бүгенге рухи деградация һәм глобаль кризисны, дөнья тотучыларның яңа тәртип урнаштыру ниятендә оештырган ясалма кыенлыклары дип кенә түгел, ә рухи халәт вә яшәү рәвешенең илаһият кануннарына җавап бирмәве нәтиҗәсе дип тә карарга кирәктер. Гомумән алганда, абсолют кыйммәтләр системасында җәмгыяви үзоешуның иң югары формасы булып аның илаһи нигездә оешканы (метасәяси үзоешу) санала. Тик әлегә андыйлар күренми. Хәлбуки, илаһи миссияле милләт буларак, татар бу эштә беренчеләрдән булырга да сәләтле.

Метасәяси үзоешу мөмкинлекләрен үз мисалыбызда ачыклау белән чикләник. Чөнки мурмурациядән аермалы буларак, илаһи миссияле татар милләте өчен ул инде югары аң (рух тәңгәллеге) нигезендә оешуны да аңлата. Татарның бүген бәйсез дәүләте булмавын һәм бөтен дөньяга сибелеп яшәвен дә исәпкә алсак, экстерриториаль яшәешле милләт өчен бу инде аеруча зур әһәмияткә ия. Димәк, тышкы яки эчке яңаулар хакында тулы мәгълүмат булганда (ә интернет чорында бу инде зур проблема түгел), әзерлекле татар кешесе, кайда һәм ничек яшәвенә карамастан, метасәяси планда дөрес реакцияне мизгел эчендә үзлегеннән ясый һәм яшәү рәвешен дә шуңа тәңгәл үзгәртә ала. Әлбәттә, моның өчен милли вә иҗтимагый аңның югары булуы лязем. Актив позицияле һәм әзерлекле милләттәшләр саны хәтта 3-5% тәшкил иткәндә дә, бу инде зур күрсәткеч булачак. Ә метасәяси үзоешу формасы андыйларның һәрдаим артып торуын да күздә тота

Фоат УРАЗАЙ.

«Бәллүр каләм – 2022»

«Пирамида» концертлар залында XXIV «Бәллүр каләм — 2022» журналистика һәм масса-медиа өлкәсендәге республика бәйгесе лауреатларын бүләкләделәр. Җиңүчеләрне һәм номинантларны котлап, Татарстанның халык артисты Зәйнәб Фәрхетдинова, «Казан» бию ансамбле һәм башка артистлар чыгыш ясады.

Номинацияләрдә җиңүчеләр исемлеге:

● «Журналистикага тугрылык» – Әскәр Сабиров («Татарстан» журналы), Инсаф Абдуллин («Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе).

● «Мультимедиа редакциясе» – «Ялкын» журналы, «Татарстан» ДТРКның мәгълүмати программалар хезмәте.

● «Иң яхшы район (шәһәр) редакциясе» – Балтач районының «Хезмәт» газетасы, «Казан утлары» журналы.

● «Һөнәрдә иң яхшысы» – Гөлназ Шәйхиева («Татарлар» газетасы), Михаил Любимов («Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе), Гөлнар Гарифуллина («Интертат» электрон газетасы).

● «Ел фоторепортеры» – Анна Арахамия («Сөембикә» журналы).

● «Ел телеоператоры» – Андрей Корсинский («Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе).

● «Эффектив матбугат хезмәте» – ТНГ-групп матбугат хезмәте (Бөгелмә).

● «Популяр блогер» – «ШАЯН ТВ».

● «Туган тел» – «Яңарыш» мәгълүмат-басма үзәге (Ижау).

● «Ел медиа-шәхесе» – Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Махсус номинацияләр:

● «Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын иң яхшы мәгълүмати яктырту» – «Ватаным Татарстан» газетасы, «Актаныш-информ» мәгълүмат үзәге.

● «Россия Федерациясендә Фән һәм технологияләр елын иң яхшы мәгълүмати яктырту» – «Геофизик Татарии» газетасы (Бөгелмә), «Татарстан -24» телеканалы.

● «Татарстан Республикасының милли проектларын яктырткан иң яхшы редакция» – «Нократ» разетасы редакциясе (Мамадыш районы), «Сарман» газетасы.

Гран-при КФУның Милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил Гарифуллинга бирелде. «Бу бүләккә миннән дә лаеклырак кешеләр бик күп. Мин моны бик яхшы беләм. Бу бүләкне журналистларны әзерләүче укытучыларга, остазларга ихтирам билгесе буларак кабул итәм. Ике дистә ел элек бу бүләкне минем остазым Флорид Әгъзамов алган булган. Мин дә бу уңышка ирешсәм, әмма остазымны уздым дип әйтә алмыйм. Шулай зурлаганыгыз өчен бик зур рәхмәт», – дип сөйләде ул сәхнәдән.

Васил Гарифуллинга төп бүләк — Lada Granta машинасы ачкычларын Татарстан премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева тапшырды.

Сагындырып искә төшә Әлмира апа

Танылган журналист, җәмәгать эшлеклесе, хокук яклаучы Әлмира Әдиатуллинаның арабыздан китүенә бер ел булды. Шушы көннәрдә Казанның «Ярдәм» мәчетендә аны Коръән сүрәләре укып искә алу мәҗлесе узды.

Паспорт өчен фотога яулыктан төшү хокукын яулау өчен, Татарстанның Югары суды аша узып, Мәскәүгә Россиянең Конституция судына (барлыгы алты мәхкәмә) барып җиткән Әлмира апаның халкыбыз өчен кылынган игелекләре бихисап. Ул Хәтер көннәрендә, ак яулыктан чыгыш ясап, милләт байрагын күтәреп йөргән чын көрәшче журналистыбыз, туры сүзле, кешегә дөрес итеп киңәш бирә ала торган олуг зат булып хәтерләрдә калды. Әлмира апаның җәмәгатьчелекнең игътибарын балаларыбызны әдәп-әхлаклы итеп үстерүгә юнәлтү һәм ул-кызларыбызны кечкенәдән дөрес итеп Коръән укырга күнектерү ниятеннән «Сөембикә эниләре һәм сеңелләре» Бөтенроссия конкурсларын уздырып йөрүләре дә бүгенгедәй күз алдында. Журналист һәм җәмәгать эшлеклесе гомеренең соңгы елларында «Ярдәм» мәчетендә хезмәт куйды.

«Ярдәм» мәчетендә үткән искә алу мәҗлесендә катнашучыларга зур бүләк тә әзерләнгән иде: Вәсилә Рәхимованың Әлмира Әдиатуллинага багышланган «Фидакарь мөслимә» дигән китабы тәкъдим ителде. Дүрт бүлектән торган 180 битле басмада көрәшче журналист турында тарихи-публицистик очерклар туплап бирелгән. «Йөрәк кушканча яшәү» дигән беренче бүлектә Әлмира апаның хезмәттәшләре, иҗтимагый хәрәкәттә аның белән бергәләп халыкка хезмәт иткән дин әһелләре, галимнәр, җәмәгать эше активистларының хатирәләре белән танышырга мөмкин.

Китапның «Чишмә башы» дигән өлешендә Әлмира Әдиатуллина кызы Миләүшәнең, бертуганнарының истәлекләре безгә аның гаиләдә үрнәк әни, әне-сеңелләренең кайгыртучан апалары булуын ачып бирә. Өченче бүлектә Әлмира апаның «Мөслимә» газетасы сәхифәләрендә халыкка әдәп-әхлак, милләт сагы турында әйткән фикерләре тупланган язмалар дөнья күргән. Басманың дүртенче өлешендә Әлмира апаның «Тынгысыз елларның дулкынлы язмалары» дигән соңгы китабыннан (Ә.Әдиатуллинаның өч китап әзерләп чыгаруы мәгълүм) республика җитәкчеләренә халык зарын ишеттереп язган мөрәҗәгатьләре, дәүләт органнары белән язышкан рәсми хатлары, документлар, истәлекле фоторәсемнәр бирелгән.

Әлмира апа турында басма «Ярдәм» хәйрия фонды җитәкчесе Илдар хәзрәт Баязитов, Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Мансур хәзрәт Җәләлетдинов булышлыгы белән нәшер ителгән. Мәҗлестә Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, «Ярдәм» мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов, Казан шәһәре мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, «Апанай» мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров, «Гадел» мәчете остазбикәсе Гөлфәния Җәләлиева, ветеран журналистлар, Әлмира ханымның бертуган энесе Робис ага хатирәләре белән уртаклашты.

Искә алу мәҗлесендә Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе, хәйрияче Фәрит Мифтахов ислам темаларын яктыртып язучы журналистлар - Мөслимә Шәфыйк, Вәсилә Рәхимова һәм Рәшит Минһаҗга Әлмира Әдиатуллина исемендәге беренче премияне тапшырды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотосы.

1 нче биттә – Мамадыш районында узган Кирмән җыенында Түбән Тәкәнеш авылыннан Сәйдәш Бикбов. Сөембикә Кашапова фотосы.

Карабашта Җәлил көне

Бөгелмә районының Карабаш бистәсендә Советлар Союзы Герое, шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләрен искә алуга багышланган традицион акция узды. «Эш күрсәткән ирне ил онытмас…» дигән чарада Бөгелмә районы башлыгы Линар Закиров, шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова, оныгы Татьяна Малышева, М.Җәлилнең музей-фатиры мөдире Нәзирә Фәттахова, шулай ук Әлмәт Татар дәүләт драма театры артистлары катнашты.

Акция митинг һәм карабашлылар-җәлилчеләргә багышланган стелага чәчәкләр кую белән башланды. Шуннан соң Карабаш бистәсе халкы һәм кунаклар белән очрашу оештырылды.

Чулпан Җәлилова билгеләп үткәнчә, аның әтисенең иҗаты кешеләрдә кайгыртучанлык һәм кешелеклелек сыйфатлары тәрбияли. «Бүгенге көндә бу бик тә кирәкле сыйфатлар. Әтиемне шулай искә алуны дәвам итәбез икән, без үз Ватаныбызның патриотлары булып калачакбыз», – диде ул.

Чулпан Җәлилова герой-җәлилчеләр һәйкәле янында имән үсентеләре утыртуда катнашты, бистә урамнарында йөрде. Карабаш – шагыйрьнең көрәштәше Гарәф Фәхретдиннең туган ягы, сугыштан соң ул шагыйрьнең әсирлектә, яшерен каршылык төркемендә эшчәнлеге турында китап язган. Әлмәт драма театры бу әсәр буенча спектакль куйды, ул Карабаш мәдәният йорты сәхнәсендә Җәлилнең кызы килгән көнне күрсәтелде. Мәдәният йорты сәхнәсендә шулай ук бу көнне шагыйрьнең шигырьләре яңгырады. Ә Муса Җәлилнең оныгы Елизавета скрипкада Рөстәм Яхинның әсәрен башкарды.

Очрашуда катнашучылар өчен Чулпан Җәлилованың легендар әтисенең авыр язмышы турында истәлекләрен һәм хикәяләр сөйләве иң кызыклы мизгелләр булды.

Карабаш авылы китапханәчесе «Герой-шагыйрь Муса Җәлил» дип исемләнгән күргәзмә турында сөйләде. Анда бөек шагыйрьнең иҗатына һәм тормышына багышланган тиңсез материаллар тәкъдим ителде.

Театрга 6 гектар мәйдан

Камал театрының яңа бинасын ачу аңа нигез салуның 120 еллыгына багышланырга мөмкин. Хәзер объект буенча проект-тикшерү эшләренә техник бирем әзерләнә. Бу хакта театр директоры Илфир Якупов хәбәр итте.

«Архитектура концепциясен эшләүгә халыкара конкурс җиңүчесе булган компания – «Ваухаус» консорциумы проект документациясен ясый. Аерым алганда, бинаның төп залларын җентекләп планлаштыралар. Анда 600 тамашачыга исәпләнгән зал һәм 200 урынлы универсаль зал, көнчыгыш, камера һәм тагын берничә репетиция залы, шулай ук техник биналар, складлар һәм грим бүлмәләре булачак», – дип сөйләде ул.

Агентлык әңгәмәдәше билгеләп үткәнчә, театр проектлаучылар белән даими киңәшмәләр үткәрә, анда проектның барлык нечкәлекләре турында фикер алышалар. «Эш, ниһаять, урыныннан кузгалды, киңәшмәләр атна саен уздырыла. Көзен төзелеш эшләре башланыр дип өметләнәбез», – диде театрның сәнгать җитәкчесе һәм баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев.

Иң оптимистик фаразлар буенча, Камал театры труппасы спектакльләрне 2026 елда, театрның 120 еллык юбилеена, яңа бинада уйный алачак.

Казанда Галиәсгар Камал исемендәге яңа театрны Түбән Кабан яры буенда төзиячәкләр. Участокның гомуми мәйданы 6,5 гектар тәшкил итәчәк. Дәүләт сатып алулары сайтында шундый тендер урнаштырылган.

Техник биремнәрдән күренгәнчә, подрядчы оешмага Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Түбән Кабан күле ярлары белән чикләнгән территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләргә кирәк. Бу эшне башкарып чыгу өчен агымдагы елның 20 декабренә кадәр вакыт билгеләнгән.

Себер татарлары мирасы



Себер татарларының «Тылсымлы ат» әкиятләр китабы нәшер ителде. Басмага Төмән һәм Омск өлкәләрендә язылган 30 әкият кертелгән. Гаҗәп иллюстрацияләрне Алябьев исемендәге сәнгать мәктәбе укытучысы Асия Закорюкирова ясаган.

Китапта бик сирәк очрый торган, билгесез диярлек әкиятләр җыелган. Ләкин бөтен илгә мәгълүм «Конек-горбунок» әкияте дә кертелгән. Солтан патша турындагы әкияткә охшаганы да бар.

Уттан калмый

Ульяновскиның Идел аръягы районында урнашкан татар утарында янгын чыккан. Бу хакта Ульяновск өлкәсе татар автономиясенең Идел аръягы районы советы җитәкчесе Рафаэль Нәҗметдинов хәбәр итте. «Төп фараз – ут төрткәннәр. Аны инде расладылар, диярлек, чөнки бу бинага ут та, су да кермәгән иде. Утарны халык белән күмәкләшеп, халык акчасына төзедек. Ул килгән кунакларны кабул итү өчен ашханә кебек урын булырга тиеш иде. Безнең музеебыз бар, бу бинаны аның дәвамы итеп кабул итәргә була. Ике ишек тә, дүрт тәрәзә генә куясы калган иде. Сентябрь аенда ачылыш булыр дип ниятләгән идек. Бик кызганыч, халыкның җыйган акчасы, җыйган әйберләре янды бит», – диде ул. Татар утары 1 нче номерлы мәхәллә карамагында булган. Рафаэль абый шулай ук мәхәллә рәисе вазифасын да үти. 2014 елда балалар бакчасының элеккеге бинасын ремонтлап, мәхәллә ачкан булганнар. Биш елдан соң мәхәллә бинасы янына авылдан бер йортны китереп, Татар мәдәнияте музей-йорты ачканнар.

Рафаэль әфәнде белән Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчелеге дә элемтәгә чыккан. «Мин әле конгресс съездында бу утар турында сөйләгән генә идем, алар хәзер фаҗига турында белә», – ди Р.Нәҗметдинов. Аның сүзләренчә, халык белән бу урында яңа бина торгызырга карар кылганнар: «Бик күп кеше ярдәм итәрбез, дип хәбәр салды. Шәһәр башлыгы иртән үк, бергә эшләрбез, дип шалтыратты. Губернатор янындагы кешеләр дә элемтәгә чыкты. Аллаһка шөкер, бөтен кеше ярдәм кулын суза. Христиан динендә булган кешеләр дә ярдәм итәргә әзер булуларын әйтте. Бөтендөнья татар конгрессы да булышачак», – диде ул.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.

Тугыз яңа мәктәп ачыла

1 сентябрьгә Татарстанда 7,3 мең урынлы тугыз яңа мәктәп үз ишекләрен ача. Алар Чаллы, Әлмәт, Саба, Яшел Үзән һәм Кукмарада укучыларны кабул итәчәк. Тагын ике мәктәпне Түбән Кама һәм Биектауда төзеп бетерәчәкләр. Россия Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова «Бердәм Россия» партиясенең Казандагы Иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә шул хакта хәбәр итте. Яңа уку елына кадәр Мамадыш һәм Тукай районнарында 340 урынлы тагын ике белем бирү учреждениесе сафка басачак.

«Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов мәктәпләр өчен капиталь ремонт үткәрелә торган эш төрләрен билгеләде, төзекләндерү эшләре шулай ук беренче сентябрьгә тәмамланырга тиеш. РФ Мәгариф министрлыгының бу принциплары федераль программаны эшләгәндә нигез итеп алынды», – дип аңлатты Ларионова.

Яңа уку елына Татарстанда 118 мәктәптә һәм уку йортларында 163 азыктөлек блогында капиталь ремонт ясала. «Бу актуаль, чөнки башлангыч мәктәп укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү, гомумән алганда, мәктәп укучыларын тукландыру – без соңгы елларда актив шөгыльләнә торган проблема», – диде ул. 118 уку йортының 66 сы федераль программа буенча яңартыла, бу программаны Татарстан башлаган иде.

● Израильдә Кояш энергиясендә эшли торган, автоматлаштырылган умарта ясалган. 24 ояны берләштергән бокс белән компьютер программасы идарә итә. Ясалма интеллект тәүлек әйләнәсе кортларның сәламәтлеген тикшерә, тиешле вакытта ашата, дәвалый да белә. Берәр проблема килеп чыкса, умартачыга хәбәр итә. Роботлаштырылган умартада җыелган беренче бал сатуга чыгарылган инде.

● Париждагы Эйфель манарасы күгәргән, косметик ремонт һәм буяп кую гына файдасыз икән. 1889 елда ачылганда, манара кургашлы сурик белән дүрт кат буялган. Хәзер бу матдә тыелган. 2024 елгы Олимпия уеннарына әзерлек кысаларында һәйкәлне 60 миллион еврога 20 нче тапкыр буярга җыеналар. Белгечләр әйтүенчә, иске буяу өстеннән кабат буяп кую коррозияне көчәйтәчәк кенә, шуңа манараны тулысынча сүтеп ремонтларга кирәк.

Дизайнер Илдар Гатауллинның татар милли коллекциясе тәкъдим ителгән чакта «Йөрүзән» җыры янгыравын башкорт галимнәре тәнкыйтьләп чыкты. Бу – татар һәм башкорт мирасын бүлешүгә тагын бер сәбәп булды.

Кем мирасы?

Гауга-низаг диеп атый алмыйм, шулай да Казанда дүрт көн гөрләп барган «Тормыш стиле – мәдәни код» II Этно-fashion фестивалендә катнашучыларда ризасызлык тудырган бер мизгелнең шаһиты булырга туры килде. Туй үпкәсез булмый дип, игътибар итми дә калырга булыр иде. Әмма проблема бар икән, аны уртага салып фикерләшү хәерлерәк. Чөнки проблема ут күршеләребез – башкорт кардәшләр белән мирас бүлешүгә барып тоташа.

Шуннан сораулар туды. «Йөрүзән» җыры кемнеке – татарныкымы, башкортныкымы? Татар хәситәсе белән башкорт хәситәсе нәрсәсе белән аерыла? Ниһаять, өченче сорау: ике халыкның милли киемнәрен «бер казанда» болгату халыкларны баетамы?

«Йөрүзән» җыры көенә татар киемнәре коллекциясен тәкъдим иту башкорт галимнәренең саруына тигән. Аларның «кәҗәләнүенә» Илдар үзе дә ризасызлык белдерде: әлеге галимнәр катнашкан «Заманча мәдәниятнең эпик константасы: милли эposларны саклау һәм популярлаштыру проблемалары» дип аталган халыкара конференция иде.

Илдар Гатауллин: Халык костюмнарын реконструкцияләгән татар киеме коллекциясен тәкъдим иттек. Бу чакта «Йөрүзән» җыры башкарылды. Җырны мин куймадым, ләкин сорау туды. Башкорт коллегалар аны «башкорт җыры» дип бара. Ә миңа аның татар җыры булуы турында мәгълүмат җибәрделәр. Минем үз коллекциямне «Йөрүзән» җыры белән чыгарырга хокукым юкмыни?

Кыргыз галиме, «Манас» милли академиясе президенты, филология фәннәре докторы Талантаалы Бакчиев: «Безнең казахлар белән шундый ук тенденция. Татар белән башкорт күрше булган кебек, без казахлар белән күрше. Безнең бер зирәк акыллы акыныбыз әйткән иде: язмышыбыз шулай – без күршеләр икән, бәлки, туганнардыр да әле, бер торыш белән генә чикләнергә ярамый. Сәнгать ул бер халыктан икенче халыкка, бер кавемнән икенче кавемгә күчә ала – ул шуның белән таныла. Әлбәттә, беренчел чыганак һәм – булса – автор билгеләнергә тиеш.

Мәсәлән, казахларның беркайчан да җәйге баш киеме булмаган, алар безнең калпакны кия, башкортлар да безнең калпакны кия. Димәк, безнең борынгы бабайлар күчеп йөргән, Башкортстанның ике-өч районында кыргыз кабиләсе бар, Татарстанда да бар... Шуңа минеке-синеке дип бүлешмик, ләкин беренче кайсы халыкта булуын белгеләп үтәргә кирәк...

Илдар Гатауллин: Без борынгы татар бизәнү әйберләрен дә халык алдына чыгардык. Алар – хәситә, күкрәк бәйләвечләре. Сез алай ярамавын әйттегез. Ни өчен?

Филология фәннәре кандидаты, драматург Шәүрә Шәкурова: Мин, ярамый, димәдем. Чөнки сез – башкорт мәдәнияте вәкиле – татар мәдәниятенә эшләргә килгәнсез икән, татар мәдәниятенең уникальлеген таратырга тиеш идегез. Ә сез җиңел юлдан киттегез – Салават батыр һәм аның Акбүзаты турында «Йөрүзән» җырын янгыратып калфаклы һәм хәситәле кызларны чыгарасыз. Сез эзләнмисез, җайлаштырасыз гына. Нишләп уникальлеген тапмыйсыз?

Бәхәсне модератор галимнәр Миләүшә Хәбетдинова һәм Дамир Исхаков туктатты. Әмма тема соңрак дәвам итте.

«Башкорт егетенең башкорт җыры белән хәситәле һәм калфаклы кызны татар коллекциясе дип чыгаруы – эшләнеп бетмәгән, дигән фикер тудырды. Без аңа коллекция күрсәткәннән соң да бу хакта әйттек. Ә ул үпкәләде, – дип аңлатты Шәүрә Шәкурова. – Илдар татар мәдәнияте өчен дә зур табыш булырга мөмкин. Сезгә эшли икән – эшләсен. Ләкин татарга эшли икән, татар мәдәниятен чыгарсын, башкортка эшли икән – башкортныкын. Икесен бергә кушып, ул мәдәниятләрне ярлыландыра гына бит».

Дөрес, соңрак Илдар үзен башкорт мәдәнияте вәкиле дип атауны кабул итмәде. «Мин – татар, телебез дә татарча. Ата-бабам Чакмагыш районының Ташкалмыш авылыннан. Тарихи чыганаклар буенча, ул авылга Казаннан килеп утырган кешеләр нигез салган. Мин инде өч ел Казанда яшим һәм эшлим, – диде дизайнер. – «Йөрүзән» җыры – миңа беренче тәнкыйть. Икенчесе – хәситә. «Ул татарныкы түгел», – диделәр. Күкрәк бәйләвече – гомумтөрки бизәнү әйбере. Ул типлары буенча бүленә: һәр халыкның күкрәк бәйләвече бер-берсенекеннән дизайны, бизәнү әйберләре составы һәм кую рәвеше белән аерыла. Казан хәситәләре кыйммәтле бизәнү әйберләрен күп кую белән үзенчәлекле. Байларның хәситәләрендә кыйммәтле ташлар күп булса, ярлыраклар тәңкәләр элгән. Музыка буенча белгеч булмасам да, хәситә буенча үземне яклыйсым килә.

Татар киеме коллекциясендә чын татар хәситәләре иде. Чөнки татар костюмнарына без генә реконструкция ясыйбыз. Без борынгы бизәнү әйберләрен җыеп яңартабыз, кием өлгеләрен төгәл кабатлыйбыз. Моңарчы беркем дә хәситәне иске бизәнү әйберләрен кулланып ясамаган.

Киемдә татар яки башкорт элементларына килгәндә, без бер милләт халкы җыелып яшәгән үзәк регионнарга йөз тотабыз. Андый регионнарда башка халыкның тәэсире азрак. Ә чиктә урнашкан районнарда мәдәниятләр тәэсире зуррак булганга, бәхәсләр дә туа».

– Сезне «башкорт мәдәнияте вәкиле» дип атадылар. Моңа ни дисез?

– Документлар буенча бабамның атасы «башкорт катламыннан» дип язылган. Мин һәрвакыт үземне «татар» дип хис иттем һәм, кемдер гаепләгәнчә, ике урындыкта утырырга җыенмыйм. Башкорт мәдәниятеннән башлаганмын икән, мин аны да белеп үстем, шунда тәрбияләндем. 2008 елдан башкорт костюмын реконструкцияләдем. Һәм башкорт костюмы коллекцияләребез бар. Әмма хәзер татар тематикасына басым ясыйм.

* * *

«Йөрүзән» җырын һәрчак, бүлешмичә генә, татары да, башкорты да җырлады. Ләкин татар милли киеме коллекциясен бәхәс тудырырга мөмкин булган җыр белән тәкъдим итү – оештыручыларның хатасы дип саныйм. Бу – fashion-показлар режиссерының уйлап бетермәве, «сукыр тавыкка – бар да бодай» дигәндәй, тоткан да куйган. Татар коллекциясе турында сүз бара икән, татарлыгы бернинди шик уятмый торган җыр куярга буладыр бит!

Ә хәситәгә килгәндә, монысы инде – белгечләр эше дә бит, кайда соң алар? Гомумән, бездә галимнәр белән дизайнерлар бер сүздә булып эшләми. Кыскасы, икенче сорауга җавап – бездә галим белән дизайнерның, ягъни, теория белән практиканың берләшә алмавында.

«Йөрүзән» – Марс Закиров шигыренә һәвәскәр композитор Венер Мөхәммәдиев көй язган җыр.

Бу җырны башкорт телендә Гали Хәмзин, Фидан Гафаров җырлый, Айдар Галимов та башкортча башкара. Татарча профессиональ башкаручылар да булгандыр, әмма мин продюсер Җәүдәт Гыйльманов таныткан Рузалия апа башкаруын гына яхшы хәтерлим. Аның «Йөрүзән» клибы да бар.

Көй авторы Венер Мөхәммәдиев тумышы белән Башкортстанның Зианчура районыннан, Нефтеюганск шәһәрендә яши. «Юкка үпкәләгән булып, Ятларга китәсең бит; Аны, мине, үзеңне дә Бәхетсез итәсең бит» дигән җыр юллары исегезгә төшсә – ул аныкы.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Атаның сәяси мизгелләре

ХӘТӘР ХӘБӘРЛӘР АРТА ТОРА

Украинада үткәрелә торган махсус хәрби операция башлануга инде ярты елга якын вакыт узды. Бу вакыт эчендә анда милләтчелек күренешләре тагы да көчәйде, ә милитаризация инде моңарчы күрелмәгән масштаблар да алды. Украина президенты В.Зеленский әле шушы көннәрдә генә дә Көнбатыш илләрен Россия ватандашлары өчен дәүләт чикләрен бер елга ябып торырга чакырган. Аныңча, махсус хәрби операция башлануы өчен җаваплылык Россия ватандашларының барысына да төшә. Шуңа күрә ул аларны, бу мәсьәләдә үз фәлсәфәләрен үзгәртмәнчегә кадәр, бөтен дөньядан изоляцияләргә өндәгән. Шундый ук фикерне Эстония премьеры да әйткән. Ул Европа Берлеге илләрен Россия ватандашларына туристлык визасы бирүне дә туктатып торырга чакырган. Элегрәк исә Россия ватандашларына виза бирүне туктатып торулары турында Латвия, Литва, Болгария, Бельгия, Мальта, Чехия, Словакия һ.б. белдергән иде.

Украинаның милитаризацияләшүе белән дә эшләр кискен тора. Бүген дөньяның күп кенә илләре аңа заманча сугыш кораллары белән ярдәм итә. Узган атнада АКШ Украинага хәрби ярдәменең 1 миллиард долларлык чираттагы траншын бүлеп бирде. Анда 155 миллиметр калибрлы туплар өчен 75 мең снаряд, заманча минометлар һәм алар өчен 20 мең мина, элек куелган NASAMS дигән зенит ракетасы комплекслары өчен ракеталар, шулай ук танкларга каршы кулдан ата торган «Javelin» реактив системалары өчен ракеталар һ.б. сугыш кораллары керә.

Хәтәр хәбәрләрдән игътибарны шулай ук Кырымдагы курортлардан ерак түгел генә урнашкан «Саки» дигән хәрби аэродромда бу атнада булган шартлаулар җәлеп итә. РФ саклану министрлыгы ул шартлауларны авиация өчен сугыш кирәк-яраклары детонация бирүе белән аңлатты. Башка вакыйгалардан АКШ президенты Джо Байденның Финляндия белән Швеция НАТОга керүе турындагы беркетмәне имзалавын, Россиянең АКШтагы илчесе А.Антоновның, Вашингтон Украинадагы кризисны тыныч юл белән җайга салуга ярдәм итәргә җыенмый, дип зарлануын, шулай ук Алманиядә экс-канцлер Г.Шредерны партиядәшләре СДП составыннан чыгармау турында карар кабул итүен (ә элегрәк аны, Мәскәү белән кулга-кул тотынып эш иткәне өчен, партиядән чыгарырга җыенганнар иде) санап үтәргә була. Соңгысында исә әлеге карарны, кемнең кем белән дуслашуы – һәр кешенең шәхси эше, дип аңлатканнар. Игътибарны шулай ук Запорожье өлкәсе башлыгы бу төбәкне Россиягә кушу буенча референдум үткәрү турында боерык имзалавы җәлеп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Кемнәр әйтер «балам» дип...

«Халык дошманы балалары» дип Себергә озатылганда Чәчкәгә – 8, сеңлесе Гөлкәйгә – 6, энекәшләре Вилгә нибары 2 яшь тулган була.

Өй түрендәге миләшне
Берәү дә әйтми балан дип.
Әнкәм дә юк, әткәм дә юк,
Кемнәр әйтер «балам» дип.

Шәхес культы елларында әти-әниләреннән мәҗбүри аерылган меңнәрчә ятим җырлагандыр мондый җырларны.

Әти-әниләреннән кала иң якын кешеләре – әби-бабаларыннан да аерып, аларны «кечкенә җинаятьчеләр» өчен махсус оештырылган колонияләрнең берсенә, Свердловск өлкәсендәге Ирбит (Эрбет) шәһәренә җибәрәләр. Вил (киләчәктә талантлы шагыйрь булып танылачак) Казандагы колониядә калдырыла. Бер мизгелгә генә үзеңне әлеге сабыйлар урынына куеп карасаң, җаннарны тетрәткән бу фаҗигане ачылыгын шунда ук аңлыйсың...

Бу балалар талантлы шәхесләр гаиләсендә туган һәм нәселдән килгән затлылыкны мирас итеп алган. Әтиләре Сәлах Садри улы Атнагулов – педагог, сәяси эшлекле, публицист, язучы. Милләт мәҗлесе депутаты (1917-1918), Үзәк татар-башкорт комиссариатында Хәрби коллегия әгъзасы (1919-1920), «Кызыл Армия», «Эшче» (Мәскәү), «Татарстан» газеталары мөхәррире, Гыйльми Үзәк рәисе (1927-1929), Башкортстан тарихына, татар теленә һәм орфографиясенә багышланган фәнни хезмәтләр, әдәби китаплар авторы. 1936 елны кулга алынганда, ул Казан педагогика институты доценты була.

Әниләре Зөһрә Сөләйман кызы Мостафина башта атаклы Фатиха Аитова мәктәбендә, соңрак гимназиядә, икенче баскыч совет мәктәбендә белем алган. Политехника институтының икътисад факультетын тәмамлаган. ВКП(б) ҮК каршындагы коммунистик оешмалар бүлеге нәшриятында эшләгән.

1926 елда «Азат хатын» журналы чыга башлагач, Зөһрә ханым аның җаваплы секретаре була. Татиздат юлламасы белән аспирантурага хәзерлек курсларында да укый әле. Сәлах абыйның да, Зөһрә апаның да тавышлары бик матур булган, халык җырлары белән бергә, алар төрле арияләр, романслар да оста башкарган. Музыкага мәхәббәт әти-әнисеннән Чәчкә апага да күчкән.

Киләчәккә матур өметләр белән канатланып яшәгән тормыш җимерелә. 1936 елның 1 сентябрендә (олы кызлары Чәчкәнең 1 нче сыйныфка укырга кергән елы) – Сәлахны, ә 1937 елда Зөһрәне кулга алалар. Колониягә озатылганчы, балалар Зөһрә апаның әти-әнисе янында кала. Әбиләре аларны үз янында гына яшереп калырга бик тырыша да, тик һаман кайларда гына яшереп бетерәсең соң?

Чәчкә апаның күңелендә әти-әнисе хакындагы истәлекләр байтак. «Әтиемә ял эләксә, безнең белән бергәләп урамда йөрергә, төрле әкиятләр сөйләргә ярата иде. Безнең өчен матур-матур хикәяләр

● Сәлах Атнагулов һәм кызы Чәчкә.

яза, җырларга өйрәтә». «Шулай бервакыт, - дип сөйли ул, - әти белән Казанка буйлап «Троицкий урманы» дип йөртелгән урманга хәтле бардык. Алда тимерчыбык белән уратып алынган койма, эчтәрәк шыксыз бер йорт күренә. «Бу нинди йорт?» – дип сорагач, әтием: «Яшь җинаятьчеләр тотыла монда», – дип аңлатты. Мин бик курыктым, тизрәк китүебезне үтендем. Язмыш шаяруы дими ни дисең, 1937 елның 12 сентябрендә үзебез шул йортка эләктек... Бу вакытта анда шулай ук әти-әниләре кулга алынган 12 яшькәчә балалар тотыла иде. Монда китерелгәч, шактый гына танышларымны да күрдем.

Көндезләрен безне чәнечкеле чыбык белән уратылган ишегалдына йөрергә чыгаралар иде. Бер чыгуыбызда исемнәребез белән дәшкән тавышка койма янына бардык һәм ярыктан әбиебезне күреп алдык! Ул шундый ерак җиргә җәяүләп безне күрергә дип килгән икән, бичара. Ә бераздан безне Ирбит каласына озаттылар».

Ирбитта туганнар аерылыша. Дөресрәге, аларны аералар – икесен ике балалар йортына урнаштыралар. Чәчкә апа үзе эләккән балалар йортының директорын рәхмәт хисе белән искә ала. Балаларга рәхимле була ул кеше. Чәчкәнең музыкага сәләтен күреп, хәтта музыка укытучысына дәрескә йөрергә дә куша. Бер елдан соң кызларның Зөһрә апаның әтисе Сөләйман абзый эзләп таба һәм Казанга алып кайта. «Ул чакта бабайның өстенә кигән киемнәрен күреп, аны бик кызганганым истә, – дип сөйли Чәчкә ханым. –Аларның үз гаиләләрендә дә кулга алынучылар күп булган. Бөтен мөлкәтләре тартып алынган, тормыш итәргә җай да калмаган». И дөнья! Сәлах Атнагуловның архивтагы шәхси эшендә гаиләсеннән тартып алынган әйберләр исемлеге саклана. Өй җиһазлары, савыт-саба, кием-салым, бай китапханә тартып алынганга исем китмәде. Әмма «детские чулки – 1 штук» дигән язуны күргәч, тетрәндем. Бик озак тынычлана алмадым: бер сыңар оекны балалардан талап, оялмыйча шуны исемлеккә кертеп язып утырырга кемнәрнең, ничекләр кулы күтәрелде икән?

Чәчкә Сөләйман бабасы фамилиясен ала (соңрак балаларның өчесе дә Мостафин фамилиясендә йөри). Тик кара сакал бер иярсә, артыннан каламыни?! 1940 елда – бабалары, 1943 елда әбиләре вафат була. Балалар әниләренең бертуган сеңлесе Хәдичә апалары кулында кала. Апаларына еш кына эш буенча командировкага китәргә туры килә. Шуңа күрә күп вакыт балалар өйдә үзләре генә дә тора.

Аларның тормышы никадәр авыр булуын күзаллау кыен түгел. Унынчы сыйныфта укыган Чәчкәнең мәктәпкә йөрергә юньле киеме дә булмый. «1946 елны әни лагерьдан телогрейка киеп кайткан иде. Мәктәпкә шуны киеп йөрдем. Телогрейка эченнән кияргә кофтам юк иде. Яхшы укыгач, мәктәптә математика түгәрәгә алып бара идем. Беркөнне түгәрәк җитәкчеләренә директорга керергә куштылар. Өске киемемне класста салып калдырырга кирәк иде. Телогрейканы сала алмагач, кермәдем инде. Гарьлегемнән бик каты еладым шул чакта», – ди Чәчкә апа. Ул елларда, бик-бик авыр сәгатьләрдә өметсезлектән, күңел төшенкелегеннән ниләр коткарып калды икән аны?

Мәктәптә «отлично» билгеләренә генә укый Чәчкә. «Математикага сәләт әтидән күчкәндер», – ди ул тыйнак кына. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлагач, университетка керә. Яхшы укыган кызны комсорг итеп сайламакчы булалар. Тик ярамый – «дошман баласы». Бишенче курста укыганда университетның математик анализ кафедрасы мөдире, профессор, атаклы галим Гагаев Борис Михайлович аны: «Аспирантурага бары үземә киләсең», – дип чакыра. Университет Советы ризалык бирми – әлеге дә баягы, «дошман баласы». N номерлы предприятие вәкилләре эшкә чакыргач, Чәчкә: «Миңа ярамый», – дип үзе баш тарта.

Татарстанның Куйбышев районы үзәгендәге педучилищега укытучы булып урнаша ул. Физика, математика, методика, немец теле укыта. Биредә Чәчкә дүрт ел эшли. Шул еллар буе училище директоры Насыйров Гата Сиражетдин улы аны аспирантурага керергә өнди. Әмма Чәчкә аспирантурага имтиханнарны педучилище ябылып, Казанга кире кайткач – 1955 елны гына тапшыра.

Аспирантура тәмамлау белән, Алабуга педагогика институтына эшкә китә. Биредә математика кафедрасында өлкән укытучы, физика-математика факультеты деканы, фән һәм укыту буенча директор урынбасары вазифаларын башкара. 1963 елдан Казанга кайтып, дәүләт педагогика институтының алгебра һәм геометрия кафедрасында эшли һәм 1984 елда ялга китә. Чәчкә Мостафинаның математика буенча дистәләрчә фәнни хезмәтләр авторы икәнен әйтеп китү дә урынлы булыр.

Ул гаилә архивын күз карасы кебек саклап тота, барлый, мәгълүматлар өсти. Әтисе хакында язылганнарны бөртекләп җыя, төрле кешеләрнең истәлекләреннән эзләп табып, тулы бер образын тудырырга тырыша. Әтисенең ниндидер могҗиза белән исән калган хезмәтләрен китап итеп бастырып чыгарырга хыяллана – аларны латиннан кириллицага күчерә.

Гаилә фотоларын караганда, аннан әнисе Зөһрә хакында сорашам. Утызынчы елларда татар кызлары аспирантурага керә алмаган. Керергә теләүчеләр күп булса да, аларга гел киртә салып торганнар. Ә Зөһрә апа – кергән.

– Әнием төрмәдән кайткач, үз эченә бикләнебрәк яшәде, күп нәрсәләрне сөйләмәскә тырышты, белеме буенча эшкә дә урнаша алмады. Безнең янда сәясәт турында ялгыш бер сүз әйтү юк. Бик якын дуслары белән генә аралаша иде. Элегрәк ул дуслыкка бәя биреп бетерә алмаганмын, ахры. Дуслары Гөлчирә апа Гафурова («Азат хатын» журналы редакторы), Хәрирә апа Биктаһирова (Гомәр Гали хатыны), Мөхтәрәмә апа Рәхмәтуллина (пединститутның элеккеге укытучысы) – барысы да әнием кебек хәсрәт дәрьясын кичкән кешеләр булган. Ирен, биш баласын югалткан Зәйнәп апа Хәсәни дә әниемнең дусты иде.

Чәчкә апа башта сеңлесе Гөлкәйне, соңрак энесе Вилне дә соңгы юлга озатты. Гөлкәй бигрәк кыска гомерле була – улы Алик әнисеннән дүрт кенә яшьлек булып кала. Аны үз баласы кебек күреп, Чәчкә апа үстерде һәм ни кызганыч, соңгы юлга да озатты.

Әнисенә бирелгән кечкенә генә фатирда яши Чәчкә апа. Аллага шөкер, зиһененә, акылына күз тимәсен. Укучыларга әле дә математика серләрен өйрәтә ул. Илдәге, дөньядагы хәлләр белән танышып бара, үткәннәрнең кабатланмавын теләп яши. Элекке студентлары белән дә бүгенгәчә аралашып тора. Чәчкә Сәлах кызына районнардан гына түгел, Владивосток, Рязань кебек ерак шәһәрләрдән дә хатлар, тәбрикләүләр җибәрәләр. Казанга килеп чыксалар, янына күрешергә керәләр. Педагог өчен бик зур шатлык бит бу.

– Бүгенге яшьләр татарның никадәр талантлы шәхесләре булганын белсен һәм алар кичергән авырлыкларның сәбәбен йөрәкләре белән аңласын иде...

Чәчкә апаның сүзләрендә моң, күзләрендә тагын яшь...

Тәэминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

Төнге сулар ага, төнге сулар,
Килер бер көн, Вакыт чаңы сугар...

(Танылган шагыйрь һәм тәнкыйтьче Наис Гамбәрнең туууына 75 ел)

Наис ГАМБӘР

КАЙТСАМ...

Кайтамын да... китә алмый ятам,
Көннәр, төннәр ятам интегеп;
Бураннары чыкса – бишмәтем юк,
Яңгырлары яуса – итегем.

Мин гел шулай: кайтсам – китмәс өчен
Бер-бер хәйлә табам, алдашам;
(Йөрәгемдә – утлар, мин су эчәм
Атлар белән агач ялгаштан.)

«Акыллылар» әйтәдер дә (бәлкем?) –
Йөри шунда тик эт сугарып;
Этем түгел, атым сугарулы, –
Кайту белән ташлыйм тугарып.

Тугарылып ташлыйм кайту белән, –
Камыт суккан төшләр ял алсын!
Тик син генә, Ыгым, мәңге тынмас
Яраларны җөйли аласын.

Суын җылы синең, тының җылы –
Синдә генә басам сусынны.
Атлар ялгашыннан сулар эчәм –
Җирсү, сусау әллә шушымы?!

Җиккән атлар тора өй каршымда,
Син сорама: «Тагын кай таба?»
Кайтмам диеп китәмен дә, Мөслим,
Әфсеннәрең тартып кайтара.

ОЗАТУ

Авылда – көз... Дөнья сулып калган.
Кошлар – китә... Бу бер төш кебек.
Ятам кырда – очып барган җирдән
Егылып төшкән бала кош кебек.

Уйга талып, таулар үткелендә
Асылынып торды күк болыт;
Тынып калды урман...
Кырлар тынды –
Кошлар очты ул көн күк тулып.

Бөтерелеп, бәргәләнеп алар
Урадылар кырлар түреннән;
(Илаһи моң - кошлар өне иңә
Бар хәяткә күкләр төбеннән.)

Саргылт монар – ерак атауларда,
Җете алтын – агач башлары...
(Мин нигәдер, кошлар киткән саен,
Моңсуырак була башладым.)

Нилектән бу? Нидән бу сискәнү? –
Җанда үкси киткән кош өне.
Көзләр керер-кермәс үксеп ятам,
Нишләрмен соң ялгыз, кыш көне.

Күтәрелде кошлар иле белән,
Кубарылды кошлар ил белән;
Яфраклар тама шыбыр-шыбыр
Кошлар очып үткән җил белән.

БОЛГАР ТАШЛАРЫНА

XVIII йөздә Болгар кабер ташлары
Успение чиркәве нигезенә салына.
Газетадан

Хак Тәгаләм!
Хак сүз!
Тел иңдер дә Болгар ташларына, –
Баш орыйм бер кабер ташларына, –
Тыңлап торыйм... Юкса ничә еллар
Сүз табалмыйм сөйли башларыма.

Чал тарихның тимер капкаларын
Ач та (ташлап нахак япмаларын!)
Ташка сүз бир... Хак Тәгаләм, бер сүз –
Соңгы сүзен үксеп ятканнарның.

Сөйләсеннәр яуда җиңелгәннәр,
Болгар туфрагына күмелгәннәр;
Җимергәннәр генә теллемени,
Хаклымыни «аксак тимерләннәр»?!

Юкса Иблис-кәлтә һаман алдый,
Коерыгын өзеп ялгый-ялгый;
Ялгыша ул: «Имеш, тарих – тузан,
Ташлар – үле, ташлар сөйли алмый».

Ләкин...
Килә дә көн – актарыла сулар,
Өскә калка Бөек Болгар, Сувар;
Тирәннәрдән калка язулы таш –
Тамгалы таш...
(Дөнья шундый чуар!)
Язулы таш – Болгар илчеседер,
Алласыдыр Болгар ташларының;
һәм ул хәтерлидер кара көнен –
Гарасатның ничек башлануын.

Безгә килеп җиткән бер догадыр
Ташка суеп язылган бу сүзләр;
Ташлар елый белми...
(Нык булырга кирәк!
Таштай нык булырга!!!) Яшьле – күзләр...

Кеше гомере Җирдә мизгел генә,
Халык гомере дә акмый тигез генә, –
Ташка күчә дә җан,
Сөйли үз телендә,
Салсалар да чиркәү нигезенә!

КЫЛГАННАР ЙӨГЕРӘ...

Дала буйлап кылганнар йөгерә...
Ә. Еники

Кылганнар йөгерә, кылганнар...
Дулкыннар йөгерә сөрлегеп.
(Акъәби йөридер кырларда,
Ак мамык шәленә төренеп.)
Кылганнар йөгерә сөрлегеп.

Хәтер – җил; мәңгелек җил-давыл, –
Актара учаклар кузын;
Шәфәкъләр – кып-кызыл, кан кебек;
Дала – киң; көн – кыска; юл – озын...
Җил тузгый учаклар кузын.

Офыкта – чатырлар; яна ут, –
Учак та җилпенә, тынгысыз;
Таң белән – сәфәргә, сәфәргә!
Хыял – ук; хис-хәнҗәр – кынысыз.
Чатырлар каршында яна ут.

Акъәби торгандыр сәхәргә,
Җилләрдән көткәндер хәбәр-өн, –
Кылганлы кырлардан Ак атта
Бер кайтыр Ил кичкән хәләлең.
Акъәби көткәндер хәбәр-өн.

«Ир-егет җанында ат ята» –
Акъәби сүзе бу колакта...
Кайсыбыз менәчәк толпарлар
Кешниләр тибенеп улакка?!

«Ир-егет җанында ат ята».
Кылганнар йөгерә, кылганнар...
Кырлардан йөгерә сөрлегеп;
Акъәби учагы сүнгәнче
Булырмы сәхәргә өлгереп?!
Дулкыннар йөгерә сөрлегеп.
Кылганнар йөгерә...
Йөгерә...

ТӨНГЕ СУЛАР

Төнге сулар ага, төнге сулар...
Көзге сулар шундый ямансулар, –
Таллар боек, түбән иелгәннәр,
Инде сап-сарыдан киенгәннәр.
Төнге сулар ага, төнге сулар...

Сулар өсте тулы яфрак ага,
Яфракларны дулкын ярга кага;
Ярда кала читкә кагылганнар,
Бер кояшка гына табынганнар.
Сулар өсте тулып яфрак ага.

Айның сузылып төшкән ак җепләрен
Чайкый, юа Ыкның дулкыннары;
Кеше дә бит җирдә яфрак кына, –
һәр суның бар яшерен упкыннары.
Чайкый, юа Ыкның дулкыннары.

Төнге сулар ага, төнге сулар...
Килер бер көн, Вакыт чаңы сугар, –
Күкрәк елгасыннан аккан еллар
Кайтмас, кайтмас... Тынгы бирми шулар.
Төнге сулар ага, төнге сулар...

* * *

Теләсәң дә булмый – онытып булмый,
Минем кулдан килми, нишлим соң?!
Ирексездән синең эзне эзлим,
Туфрагына бассам Мөслимнең.

Менә монда,
Ык ярында учак яктык,
Уйнап кына, кызык өченгә;
Сизмичә дә калдык – ике юләр! –
Торып калдык
Дөрләп янган учак эчендә.

Мәңгелек ут ялмап алды безне,
Ялкынланып яндык учакта;
Һич тә шикләнмичә, тик бер көнгә
Кайтып килер идем ул чакка.

Син дә шулай кабат-кабат урап
Кайтасыңдыр ерак үткәнгә;
Учаклардан җылы алгалап кит,
Юлда, арып, хәлең киткәндә.

Үз-үземне генә алдыйм, ахры, –
Бер янганнар янмый!
Асылда без хәзер икенче:
Күмерләнеп ялгыз утырып калган,
Яшен суккан агач шикелле.

Әнә яшьләр – үсентеләр үсә,
Алар янсын, алар көйсеннәр;
Алар да бер сөю төмен тойсын:
«Сөю – сәгадәт ул!» – дисеннәр.
Ә без?!

Бик еракта, Ыкның аръягында
Учак яна. Уты сүлпән инде, курыкма;
Күзларын җил кузгаткач кына,
Шәүләләре уйный офыкта.

СОҢГЫ ЧАБЫШ

...Утлап йөри тышауланган атлар.
Соңгы чабышкадыр?! –
Иярләрен барлый ят җайдаклар.

...Өзелделәр тимер өзәңгеләр.
Ничә тапкыр аңа
Өзекләре белән кизәнделәр.

...Уңлы-суллы уйнап торды камчы.
Агып төште күзе –
Соңгы тере күзе – утлы тамчы.

...Бәйгеләрдә туза икән йөрәк.
Көчкә басып тора,
Аумас өчен, җиргә башын терәп.

...Бик еракта тайлар куя кешнәп.
Тик ул ята инде,
Телен аркылыга тешләп.

* * *

Китүдән дә кайту авырырак
Бу дөньяның чиксезлегендә;
Яшәү белән Үлем арасында
Яши кеше – үз читлегендә.
Мәңгелеккә! диеп килгән идем,
Узсам – узганмындыр бер саплам;
Сәхәрдә дә бер сүз, ахшамда да:
«Югалтырлык түгел, югалтмам».
Гомер җебе кыска – бер саплам.

* * *

Еракларданкилгән тавыш сыман
Уяна да хәтер... Бөтерелеп,
Бетеренеп – кечерәеп алам;
Тоныгая истә калган төсең,
Кайчандыр үз, изге якын кешем! –
Син барыбер миңа сабый бала.
...Еракларданкилгән тавыш сыман.

Агачларны үлән кебек кенә
Ерып чыгарсың күк үткәннәрдән, –
Пәрәвезләр сарыр иңнәреңне.
Ташландык бер йортның каршысында
Бүкәннәргә утырып көткән мәлдә
Җилләр җилфердәтә җиңнәремне.
...Агачлар да үлән кебек кенә.

Бер көнен дә калдырмыйча яшәп
Уза гомер – ага гына, чәчрәп,
Улаклардан аккан су сыман.
Сөю – дәрья, ярларына тулмый,
Аккан суга кабат кереп булмый, –
Ярда калам... Бәхил шушыннан.
...Бер көнен дә калдырмыйча яшәп.

Әлсерәтте еллар, әлсерәтте...
Яшьлегемнең соңгы тәэссораты
Карап тора агач артыннан.
Мин әлегә туган туфрагымда;
Гомеремнең сыңар яфрагын да
Бирмәс идем көмеш-алтынга...
...Әлсерәтте еллар, әлсерәтте.

Тып-тып гына август җиле исә,
Еракларданкилгән тавыш сыман.

Укытучыларның кәгазь эше кимерме?

Укытучылар кәгазь боткасына баткан, аларның укытырга вакыты да калмый дигән фикер еш әйтелә. Укытучы укытудан тыш күпме кәгазь тутырырга тиеш? Федераль порталда укытучылар тутырырга тиешле кәгазьләр исемлеге чыкты. Ул җәмәгатьчелек фикерен җыю максатыннан эшләнде. Башта исемлек 11 пункттан тора иде, аннары 9 га калды. 15 июльдә норматив хокукый актлар проектлары федераль порталында яңа проект өстәлде, әлеге яңа исемлектә 5 пункт. Закон проектына карата үз фикереңне норматив хокукый актлар проектларының федераль порталында калдыру мөмкин. Проектның тулы тексты белән дә шунда ук танышып була.

Укытучылар тутырырга тиешле документлар:

1. уку предметының, уку курсының (шул исәптән дәрестән тыш эшчәнлек), уку модуленең эш программасы;
2. өлгерешне исәпкә алу журналы;
3. дәрестән тыш эшчәнлек журналы (дәрестән тыш эшчәнлекне башкаручы педагогик хезмәткәрләр өчен);
4. тәрбия эше планы (сыйныф җитәкчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләр өчен);
5. укучының характеристикасы (соратып алган очракта).

Бу – укытучыларның фикерләрен җыйганнан соң төзелгән исемлек. Чагыштыру өчен – башта чыккан исемлек шушындый иде:

1. уку предметының, уку курсының (шул исәптән дәрестән тыш эшчәнлек), уку модуленең эш программасы, аның үтәлеше турында хисапларны да кертеп;
2. өлгерешне исәпкә алу журналы, аның үтәлеше турында хисапны да кертеп;
3. дәрестән тыш эшчәнлек журналы (дәрестән тыш эшчәнлекне башкаручы педагогик хезмәткәрләр өчен);
4. индивидуаль уку планы, өйдән һәм медицина оешмаларында укучылар белән эш алып бару журналы (медицина оешмаларында балаларны укыту оештыра торган мәктәпләр өчен);
5. тәрбия эше планы (сыйныф җитәкчелеге функцияләрен, мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча педагогик эшчәнлек алып баручы педагогик хезмәткәрләр өчен);
6. ата-аналар җыелышыннан беркетмә (сыйныф җитәкчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләр өчен);
7.укучыларның шәхси эшләре (карталары), укучыларның портфолиолары, сыйныфның социаль паспорты (сыйныф җитәкчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләр өчен);
8. баланың килгән яки килмәгән көннәрен исәпкә алу журналы (мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре өчен);
9. 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы «Балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 5 маддәсендә күрсәтелгән затларга карата индивидуаль профилактика эшен үткәрүне исәпкә алу материаллары;
10. укучының характеристикасы (соратып алган очракта);
11. төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һәм әлеге оешмаларның территориясеннән читтә шәхес формалаштыру эшчәнлеген алып бару турындагы документлар (документлар оешманың локаль норматив актларында каралган). Әлеге эшчәнлек оешмаларда укучыларының гомуми культурасын формалаштыруга, аларның физик, интеллектуаль, әхлакый, эстетик һәм шәхси сыйфатларын, индивидуаль сәләтләрен, уку эшчәнлегендә уңай мотивация һәм осталыкларын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрү максатында була ала.

Фикерләр кабул итеп бетерелгәч, нәтиҗә ясалып, боерык 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә. Закон проектының максаты – укытучыларга бюрократик йөкләнешне киметү диелгән.

11 пунктлы исемлек чыккач, кешеләр үз фикерләрен «Вконтакте» социаль челтәрендәге укытучыларның төрле төркемнәрендә калдырган.

«Профсоюз «Учитель»» төркемендәге комментарийлар:

«Унберенче пунктта тагын 150 төрле отчёт язылачак, чөнки монда төгәл аңлатмалар юк», «Бу документларны киметү дип аталамы инде?», «Сорарга да оялам, ә нәрсә киметтеләр соң?» «ВПР (Бөтенроссия тикшерү эшләре) нәтиҗәләре буенча таблицалар тутыру ничек? Аллә аны укытучылар тутырмаячакмы? Могҗиза...»

«Укытучы хезмәтен җиңеләйтергә телибез дисәләр дә, бу - эшнең тагын да артачагын аңлата. 24 ел мәктәптә эшләп, мин бу системаны аңлап кына калмадым, ә бернichә кат моңа инандым», - дип яза «Белгородский институт развития образования» төркемендә бер ханым.

Таныш укытучылардан да аларның һөнәрендәге кәгазь эше турында сораштым. Бөтенесе дә гаиләләре йоклап беткәч, төнлә кәгазь эшләре белән утырганын сөйли.

«Бик күп социаль яклау өлкәсе хезмәткәрләре эшләрен мәктәпләр башкара. Мәсәлән, сыйныф җитәкчеләре елына ике тапкыр, балаларның яшәү урынының төзеклеген тикшереп, акт яза. Һәрбер баланың ничегрәк яшәгәнен язасы. Мәктәп почтасына килгән көндәлек хатны карасаң, анда бөтенесенә хисап кирәк. Һәрберсенә фото беркетеп куясы. Җинаять кодексында гаепсезлек презумпциясе дигән нәрсә бар, ягъни син үзеңнең гаепсез икәнеңне дәлилләмисең, ә синең гаепле икәнеңне дәлилилер. Шундый нәрсәне укытучы эшчәнлегенә дә кертсәсе иде. Син әйбәт укытуыңны дәлилләр өчен көннәр буе документлар җыеп йөргәнче, синең әйбәт укытмаганыңны бүтәннәр килеп, нәрсә дә булса табып дәлилләсә, яхшырак түгелме икән», – диде бер таныш укытучы.

Тагын бер авыл укытучысы аларга әти-әниләргә шалтыратып, гаилә хәлләрен сорашып, документ тутырырга кирәклеген әйтте. «Без отчёт җибәрү өчен кайсыларының тормышлары җитешсез, кем күп гаиләле икәнен белешеп шалтыратабыз. Ул мәгълүматны авыл советыннан да ала алалар бит инде, юк – укытучыга кушалар. Сезнең тормышыгыз җитешме, акчагыз җитәме, әз алмыйсызмы дип сорап утыруы да читен», – ди ул.

Филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты Миләүшә Хәбетдинова да укытучыларга бик күп башка өлкәгә караган эшләр кушылуы турында сөйләде һәм бу оптимизацияләштерүнең тискәре йогынтысы икәнен аңлатты.

Шушы биш документны гына сорасалар, укытучы өчен сөенергә була, ләкин мин моңа ышанмыйм. Чөнки безнең дәүләт укытучылардан статинформация җыярга өйрәнгән. Министрлыкларда бүлекләрне оптимизацияләштерү, эш тәртибен үзгәртү нәтиҗәсендә туган проблема бу. «Бер тәрәзә» аркылы эш итәргә тиеш түгел, дип язсалар да, төрле чиновниклар укытучы өстенә кирәкмәгән эш өеп тора. Мәгариф министрлыгы, укытучыны якламыйча, үзе дә документлар белән «футбол» уйнарга ризалык күрсәтә. Төрле оешмалар грант алып проект эшлиләр, ә балаларны теркәргә укытучыларны җигәләр, әлбәттә, административ ресурс кулланып. Ел буе күпме тестирование, соцопрос – барысы да укытучы өстенә төшә. Ул көне буе төрле оешмалардан төшкән планнар, белешмәләр, отчетлар тутырырга мәҗбүр. Яңа закон ярдәм итәр дип ышанмыйм.

Укытучыларга хөрмәт юк. Быел Казанга ике халыкара олимпиада медале кайтты. 131 лицей укучылары математика һәм химиядән халыкара олимпиадада җиңде. Бөтен шәһәрне аларның портреты белән тутырырга кирәк. Башта лицей директоры Хәбибуллина Әлфия Блигвардовна Булат Курамшинны әзерләде [Булат Курамшин – 2016 елда халыкара олимпиадада алтын медаль яулады], ә ул хәзер мәктәптә укытучы

булып эшли, һәм шушы җиңүче малайны әзерләде. Ник без бөтен мәгълүмат каналларын Әлфия Близвардовна, Булат Курамшин, Никита Перов яки математика укытучысы Руслан Сергеевич Ефремов һәм Галия Шәрәфетдинова портретлары белән тутырмыйбыз? Иң элек укытучыга мөнәсәбәтне үзгәртергә, хөрмәт уятырга кирәк, –ди Миләүшә Хәбетдинова.

Укытучылар әзерләргә тиешле документлар исемлеге турында Түбән Кама мәктәбендә эшләгән укытучы фикерен сораштым. Укытучы ханым 37 ел мәктәптә эшләгән, бер ел элек эшеннән киткән. Ул исемен язмауны сорады.

– Андый документлар күп булды инде, Россиядән шундый-шундый документлар булырга тиеш дип килә, тик ул безгә килеп җиткәнче тугыз булмый, кырык тугызга әйләнә. Регионнар өсти, муниципалитет өсти, шулай итеп укытучы кәгазьгә бата. Балалар белән эшләгәнебез юк, без кәгазь белән шулхәтле күп эшлибез. Әле безне төрле җирләргә кертеп сертификатлар алдырталар, кемгә кирәктер ул кәгазь?! Аңа керергә, теркәлергә кирәк, сорауларына җавап бирергә. Шундый әйберләр бетерә укытучыны, мин шуңа эштән киттем. Туеп киттем, Укытучы бит укытырга тиеш. Киттем, чөнки ул инде сәламәтлеккә дә бәрә башлады. Хәзер мәктәпләрдә эшләү шундый авыр. Шул кәгазь эше булмаса эшләр идек дип, мәктәптән киткән укытучы күп булды.

Рәсми документлардан тыш, укытучылар гел бәйгеләрдә катнашып, шулар буенча отчетлар язып тора. Шулай кушалар.

Бәйгеләргә карап, мәктәпләр рейтингы ясала. Бәйгеләрдә катнашучылар булмаса, башыңа сугалар. Укытучы ел ахырында бөтен үзенең конференцияләрдән килгән рәхмәт хатларының копиясен чыгартып тапшыра. Бездән хисап бирдертәләр. Ул бит дөрес әйбер түгел, шуңа күрә укытучы укытмыйча кәгазь җыеп утыра. Тегендә-монда катнашып, вакытын әрәм итеп.

Ул конференциядә ярты елга утызлап бала катнаштырырга кирәк. Укытучы үзе түгел бит, балаларны әзерләргә кирәк. Кәгазь алып, син үзеңне кеше икәнеңне дәлилләп утырырга тиеш.

Мин директор урынбасары булып та эшләдем. Өстән «Эшләмисез», дип килгәч, мин укытучыларга «Әйдәгез, менә монысын эшләп карыйк инде», – дип әйтергә тиеш булам. Ул бәйгеләрнең күбесе әле – акчалы. Нигә без шул кәгазь өчен 600, 800, 1000 сум акча түләп, әйбәт укытучы икәнне дәлилләргә тиеш?!

Әле кеше китертеп курслар үткәрәләр, алары да акчалы. Килеп утырасың, акчаңны түлисең, тыңлыйсыңмы, тыңламыйсыңмы – синең кулыңда кәгазь. О-о, шәп булды! Җан әрнүе! Мәктәптән киткәч, бу әйбер турында уйлыйсы да килми иде, менә хәзер тагын нервлана башладым, – ди әңгәмәдәшем.

Укытучылар көнендә лицей укытучысыннан «Укытучылык эшендә иң авыры нәрсә?» дип сораган идем.

– Кәгазь эше. Аның кирәклесе генә булсын иде. Мәсәлән, журнал тутыру, тематик план язу. Бик күп кирәкмәгән отчетлар яздыралар. Гомер буе түрәләргә үзеңнең укыта алганыңны, «дөя» булмавыңны дәлилләргә кирәк. Менә күз алдыңа китер – аш пешергән саен сиңа тозны күпме, ни өчен салганыңны, аның кайсы тәшкә файдасы һәм зыяны барлыгын, итне күпме салганыңны, ә аннан артык салсаң нәрсә булачагын язып барырга кушалар, ди. Синең шуннан соң ашарга пешерәсең килер идеме? Һәр кушылган эшне моның балалар белемен арттырудагы роле нинди икән дип уйлыйм. Күп очракта аның ролен ноль процентка тиңлим, – дип җавап бирде ул.

Казандагы «СОлНЦе» мәктәбенең директоры Павел Шмаков белән дә закон проекты турында сөйләштем. П.Шмаков әлеге закон проектының җәй көне кабул ителүен һәм фикер алышуга тапшырылуын начар дип бәяләде – хәзер бөтен укытучы ялда. Ул әлеге исемлек белән кәгазь эшен киметү максатына ирешеп булмаячак дип уйлый.

– Укытучылар эшкә 15-16 августларда чыгачак, алар эшкә килгәч аңларга да өлгермәячәк, ә законнарны инде үтәргә кирәк булачак.

Мин аңлыйм, әгәр дә гадәттән тыш ситуация булса, су басу, янгын, монда аңлашыла, карарны тиз кабул итәсе, ә башка мәсьәләләрдә халык белән киңәшләшергә кирәк. Хәзер педагогикада гадәттән тыш хәлләр, куркыныч нәрсәләр юк, мәгарифтә тыныч ситуация. Гел җәй көне, июль-августта тиз-тиз нәрсәдер алмаштыра башлаганда, эшләр хөрти, – ди П.Шмаков.

Мәктәп директорыннан укытучыларның төрле бәйгеләрдә катнашуына, шуның буенча хисап тапшыруга карата фикерен дә сораштым.

– Минемчә, бәйгеләрдә катнашу – яхшы нәрсә, ә менә нинди документлар тутырырга мәҗбүр иткәндә, әлбәттә, начар. Ул документлар бәйгесеме, әллә укытучыларныкымы? Укытучылар ачык дәресләр күрсәткән очраклар була, бу – кызыклы гамәл. Ә укытучылар үзләре «Менә нинди яхшы мин», – дип документлар әзерләп, аннары нинди абзый ул документларны карап чыгып, «Менә бу укытучы яхшы, ә монысы начар», – дип утырса, анысы инде бөтенләй дөрес түгел, – ди ул.

Гөлия ХӘСБИУЛЛИНА.

intertat.tatar/

Хатирәләрдә - гомер агышлары...

Мамадыш, Саба якларында туып-үсеп, бар гомерен кешелеккә хезмәт итүгә багышлаган Илгиз ага Габдуллин язмышы ихлас ихтирамга лаек.

Әтисе Габдулла Бикмөхәммәт улы 1918 елны Саба районының Иске Икшермә авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Әтисенең бабаларыннан калган кәсебе – каен тузыннан дегет ясап сату була, шунлыктан Үзәкәй Бикмөхәммәт гаиләсен яшь совет хөкүмәте хәерче һәм ярлы булмаган өчен өнәп бетерми. 1936 елда Лубян урман хуҗалыгы техникумына укырга кергәндә документларын бераз үзгәртергә кирәк була, әмма ике ай укуга, укучы иптәшләре әләкләве нәтиҗәсендә «кулак малае» исеме тагып, уку йортыннан куалар... Гыйлемгә тартылган егетне бу кимсетү туктатмый, яңа документлар ясатып, Мамадыш педагогика техникумына укырга керә, укытучылар җитмәгәнлектән, ул чорларда укучыларны читтән торып укуга күчереп, укытучылар итеп мәктәпләргә җибәрәләр. Шул вакытта Габдулла булачак тормыш иптәше – Югары Ушма кызы Зәйтүнә Хафизова (1920-1998) белән таныша. Уку чорында алар районыбызның төрле мәктәпләрендә укытып, 1938 елда гаилә кора. Яшь гаиләне Кече Кирмән авылына эшкә җибәрәләр, шунда беренче уллары Венер туа, тик озак яшәми – каты авырудан үлеп китә. Бер елдан Габдулла белән Зәйтүнә Арташ авылына юллана, анда икенче балалары Илгиз (1942 ел) туа. Бу гаиләне яңадан икенче авылга – Яңа Комазан башлангыч мәктәбенә җитәкче итеп җибәрәләр. Гаилә башлыгының күптәнге теләге – үз якларына, Сабага кайтып төпләнү булса да, аларга ниятләрен тормышка ашыру бары күп еллардан соң гына насыйп була. Ул районда да гаиләгә Явлаштау, Сатыш, Мәртен авыллары мәктәпләрендә эшләргә туры килә.

Ниһаять, гаилә 1962 елда Иске Икшермәгә – Габдулла агайның бабалары нигезенә кайтып төпләнә; хуҗалык ызаннарын кире кайтару, кредитка йорт төзү, мәктәптә эш урыны табу җиңелләрдән булмый. Әмма тырышлыклары, уллары булышлыгы белән төп нигезгә яшәү яме кертәләр. Тормышта яшәү өчен, «кеше» булып калу өчен ачлык, хәерчелекнең үзәгеннән узмаган булса, балалары яшәүдә, укуда, олы мәхәббәттә зур уңышка ирешә алыр иде микән дигән сорау туа. Әйе, гаилә зурая, исән калган балаларның сигезе дә югары белем ала. Алар химиклар, укытучылар, врачлар булып тормышта үз урыннарын табып, халкыбызга игелекле хезмәт итә. Һәр гаиләдә юл ярып баручы, башкаларын үз канаты астына җыеп, әйдәп баручы була. Монда андый кеше – олы абыйлары Илгиз Габдулла улы. Мондый гаилә балалары арасында бер-береңне зурлау, хөрмәтләү, әти-әнигә булган кадер хөрмәт, туган-үскән җиргә мәхәббәт бермә-бер көчле, ягымлырак була. Бу хакыйкать.

Илгиз Габдулла улының биографиясен ачыклап язу таләп ителмәсә дә, аерым мизгел-хатирәләргә тукталасы килә. Өлгергәнлек аттестатын Саба урта мәктәбеннән ала, берничә ай укытучы булып эшләп, дүрт ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1969 елда Казан дәүләт педагогика институтының тарих бүлеген тәмамлый. Укыганда Казахстанда чирәм җирләрне үзләштерүдә отряд командиры, студсовет рәисе, институтның 5 нче санлы уку бинасы комитеты җитәкчесе булган өметле яшь белгечне 1974 елда институт ректорының административ-хуҗалык эшләре буенча урынбасары итеп билгелиләр. Проректор И.Габдуллин югары уку йортының, укыту-материаль базасын, хезмәткәрләрнең һәм студентларның яшәү-көнкүреш якларын яхшырту өчен фидакяр хезмәт куя. Шушы тынгысыз хезмәтендә 35 елдан артык эшли. Хезмәт биографиясен студентларның Универсиада авылы биләмәләрендә җитәкче эштә эшләп тәмамлады.

Һәр җирдә, илдә югары уку йортларының алтын баганасы булып дәүләт университетлары һәм педагогика институтлары санала. Бөтен гомерен институтта проректор вазифасын намуслы башкарган итагатьле, игелекле бу абзый күп меңнәрчә студентларга «икенче» эти булган шәхесебезгә якын көннәрдә 80 яшь тула. Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлаган студентлар арасында күңелләрендә яшьлек хисләре ялкынланып янган вакытта Илгиз Габдулла улын искә алып һәм сагынып сөйләгән егетләр-кызлар да күп булгандыр. Без, Мамадыш районында яшәүче якташлары да, изге эшләрен, үзен дә сагынабыз.

Хәлим СӘЛӘХОВ,
Мамадыш шәһәренең мактаулы гражданы.
Арташ авылы.

Фотода И.Габдуллин универсиадада катнашучы чит ил спортчылары белән.

Идегәй мирзаның шанлы көннәре

(Дәвамы. Башы 29, 30 нчы сандарда).

Ул гомере буе хакимияткә омтылды, инде аның иң югары баскычына күтәрелгәч кенә кулыннан ычкындырсынмы? Кичә олуг кенәзнең Тимер Котлыкка «угыл» булырга тәкъдим итүен белгәнгә, бөек бәкләрбәк сүзне нәкъ шуннан башлады:

– Әйе, ханны үзеңнең «угылың» дип атарга синең хакың бар, чөнки син аннан өлкән. Әмма мин дә бит синнән өлкәнрәк, ә син миннән яшьрәк. Шулай булгач, мин дә сиңа «ата» тиешле, ә син миңа «угыл» булырга тиешсең. Кенәзлегеңә кергән барлык җирләрдән ел саен миңа ясак түләп торырсың. Тагын шуны бел: суктырган акчаларыңа исемемне дә төшерерсең!

Бөек бәкләрбәк олуг кенәз Витовт алдына кичә кенәз Витовт Тимер Котлык ханга куйган таләпләрне китерә дә куя. Кенәз Витовт өчен бу аның яңагына сугу белән бер була, ул бик нык гарьләнә. Аны, бөек Литва кенәзен, кемдер үзенең «угылы» дип атый, үзенә буйсынган хаким сыйфатында күрә һәм моны ул кемнән ишетә... Күптән түгел Туктамыш хан хезмәтендә йөрүчедән!

Кенәз Витовтның гарьләнүдән хәтта тыны кысыла, йөзе кызарып чыга. Ул, ярсыган йөрәген тыя алмыйча, атын кисәк бора да сафларга тезелгән гаскәренә таба чаба. Килеп җитү белән һөҗүмгә әзерләнергә боера.

6

Елганың бу ярында җәелеп яткан болында татар гаскәре тора. Каршы якта – дошман. Тимер көбәләргә төренгән, кылыч-сөңгеләре тырпаешкан, үлемгә сусаган ике зур яу җаннарга шом сала. Ике биниһая көч бер-берсен бугазларга, күп каннар коярга әзерләнә.

Идегәй мирза ияр өстеннән гаскәрне барлый. Җиңел, вак бөҗралы көбә күлмәктән, кояшта ялтырап торган затлы очлымнан булгангамы, ул бүген яшәреп, ыспайланып киткәндәй күренә. Хәрәкәтләрендә тәвәккәллек һәм үз-үзенә ышану. Ул гаскәр кулларының ничек урнашуын, боерыкларның төгәл үтәлүен күзәтә, ара-тирә өстәмә боерыклар биргәли. Менә маңгайга ук җәя, кылычлар белән генә коралланган җиңел атлылар кулы килеп баса. Алар артында урта кул, ике якта, пар канатлар кебек, сул һәм уң куллар урын ала. Һәр кулның башкаларыннан аерылып торган үз әләме җилферди. Орыш барышында сугышчылар, кояшка карап көн вакытын билгеләгәндәй, үз әләмнәрен гел күз уңында тотарга тырышалар, шулай гомуми хәлне белеп торалар. Ә уртада иң зурысы һәм затлысы – Тимер Котлык хан тугы һәм байрагы җилферди. Идегәй мирзаның сыналган, күп орышларда катнашкан үз төмәне елга борылышындагы таллык артына постырмага куелган – алар орышка иң хәтәр вакытта, хәлиткеч мизгелдә кертеләчәк, дошман һич көтмәгәндә китереп сугарга, аны сытып үтәргә әзер торачак. Сафларга тезелгән гаскәр, һавада ялтыраган сөңге очлары, дәртле җилфердәгән әләмнәр бөек бәкләрбәк Идегәй мирза күңелендә горурлык хисе уята. Бу – аның үз гаскәре, бәкләрбәкнең һәр сүзен үтәргә атлыгып торучы гаскәр. «Шушындый көч-куәт була торып, солых төзергәме?» – дип уйлап куя ул, тик уен уйлап бетерә алмый – вакыты ул түгел...

Аннан ул дошман ягына борыла. Кенәз Витовт уртага көньяк рус кенәзлекләреннән тупланган полклар белән немец рыцарьларын куйган. Соңгыларының ак җирлеккә кара тәре сугылган зур байраклары әллә каян күренеп тора. Ян-якта Туктамыш хан төмәннәре белән Литва атлылары урнашкан. Еракта, кенәз Витовтның үз әләме җилфердәгән җирдә, Польша һәм Литва рыцарьлары тора. Күп кавемнәр берләшүеннән барлыкка килгән шушы коточкыч зур гаскәр алдында, авызларын татарларга ыржайтып, җиңел туплар урнашкан, туплар арасына озын мылтык – аркебуздан атучылар белән арбалетчылар баскан. Болары кенәз Витовтның горурлыгы – әлегә татарда булмаган корал белән эш итүчеләр.

Менә ике якта да дабылбайлар дөпелди, быргылар кычкырырга тотына. Башта, ташкындай җәелә барып, татарның җиңел атлылары кузгала. Меңләгән уклар дошман өстенә оча. Сай сулы тар елганы җиңел генә кичеп, татарлар алгы сызыктагы Литва полкын сытып үтәм генә дигәндә, дошман туплары, аркебузчылар телгә килә, һөҗүм итүчеләр өстенә ут бөрки, аларга арбалетчылар кушыла. Татар атлылары, сөртенеп куйгандай, тизлеген югалта, байтак яугирен калдырып, дуга сыман хәрәкәт белән уңга борыла, дошман сафларына туктаусыз ук яудыра-яудыра, елгага әйләнеп кайта. Аннан кире борыла, тагын бер һөҗүм ясый.

Атлылар һөҗүмне төгәлләп тә өлгерми, аларны арттан Туктамыш хан яугирләре бастыра, эзәрлекләргә керешә, бу исә Алтын Урда атлыларын ахыр чиктә бүленергә, канатларда торучы кулларга килеп сыенырга мәҗбүр итә. Туктамыш хан һөҗүменнән соң дошман явының төп көчләре хәрәкәткә килә. Рус, Литва полклары, су чәчрәтеп, сикереп дигәндәй, елганы кичә. Аларны татар төмәннәре каршылый. Ике як та үзенчә сөрән сала, тамак ертылганчы акыра, үз-үзен дәртләндереп, алга ашкына. Аннан ике гайрәтле гаскәр йөзгә-йөз бәрелешә. Шул мизгелдә йөзләгән сөңгеләрнең сынуы, тимер туннарның чатнавы, көбәләрнең тишелүе, яраланган меңнәрчә ат һәм адәмнәрнең җан өзгеч аваз белән кычкыруыннан тирә-юнь гөрселдәп, иңрәп китә, гүя табигать үзе, бу мәхшәрдән таң калып, тетрәнеп куя. Шулай барысы буталыша, аяусыз орыш – адәмнәрнең бер-берсен кисүе, чабуы, үтәли тишүе, ерткычларча бугазлавы башлана. Куллар өстендәге туг-байракларга карап кына кайсының кайда, ни хәлдә икәнен чамаларга мөмкин.

Атлылар гел хәрәкәттә булып, орышны бер ябырылып, бер дуга ясап артка чигенеп алып бара. Берәүләре дошманны күкрәк белән каршыласа, икенчеләре яннан китереп суга, өченчеләре яңа һөҗүм өчен көч туплый, сафларын тәртипкә китерә. Бу хәрәкәтләрнең барысы да дошманның сафларын бүлгәләү, хәлен алу яисә чигенергә, хәтта качарга мәҗбүр итү өчен башкарыла. Әмма ике якның берсе дә әлегә максатына ирешә алмый – өстенлек әле бер, әле икенче якка күчә. Бер көч каршы торучы икенче көчне ни җиңә, ни буйсындыра алмыйча азаплана. Бер якның ярсуы икенче якның ярсуына килеп бәрелә, шулай тигезләнә бара. Дошманның туры кылычын татарның кәкре кылычы, сөңгене калкан каршылый, сөрәнгә сөрән авазы җавап бирә.

...Аяусыз орыш инде берничә сәгать дәвам итә. Сугыш кырын тузан каплый, шуннан ярсу авазлар, атлар пошкыруы, акыру-бакыру, тимер чыңы яңгырап тора. Кайнап торган адәмнәр дәрьясыннан ара-тирә атлар килеп чыга, кайберләре җайдаксыз, кайберләре яраланып ияр өстенә капланган хуҗаларын мәхшәр эченнән йолып ала. Дәһшәтле, исәпсез корбаннар таләп итүче орыш тегермәне буталышып беткән ике яуны үз ташында тарттыра да тарттыра. Яңадан-яңа корбаннар сорый.

Идегәй мирза тәбәнәк калкулык өстеннән сугыш кырын күзәтә. Ара-тирә ул янына берәр бәкне яки әмирне чакырып ала да аның бүлекчәсен орышка кертә – алар хәл эчендә торып калучыларга ярдәмгә ташлана. Әмма төп көчне – үз төмәнен ул әлегә саклап килә, аны орышка кертми тора.

Хан тугы җилфердәгән урта кулның хәле бигрәк тә авыр. Тимер Котлык хан кулы күпмедер вакыт литва-рус дружинникларының кысрыклавын кире кагып торса да, аның да акрынлап хәле бетә, ул да бирешә, артка чигенә башлый. Ярдәм сорап берничә тапкыр Идегәй мирзага чапкын җибәрә, тик бәкләрбәк бер үк сүзне кабатлый:

– Орышыгыз, Аллаһы сезне ярдәменнән ташламас!

Шулай хәлсезләнә барган урта кулга тагын да көчәнергә, соңгы көчне туплап орышырга гына кала.

Урта кулның мескен хәлен каршы яктан кенәз Витовт та күреп алды һәм, хан байрагын кулга төшерү өчен, ул анда үзенең соңгы резервын – Польша, Литва, Ливон рыцарьларыннан торган сайланма полкларны ташлады. Менә алар, байракларын җилфердәтеп, сөрән салып, татар гаскәренең үзәгенә бәреп керде, канатлардагы полклар да шунда ыргылды.

Шулай урта кул коточкыч яра алды, хәл эчендә калды. Йөзләрчә яугир һәлак булды, калганнары үлем ярсуы белән орышны дәвам итте. Әмма көч инде төкәнеп килә иде, чигенә башладылар. Менә-менә сафлары өзелеп китәчәк, чылбыр аерым бөҗраларга таралачак...

Әмма Идегәй мирзаның урта кулга ярдәм итмәвендә сугышны алып баруның төп хәйләсе ята иде. Кенәз Витовт, татарларның хәле төкәнде дип уйлап, урта кул өстенә соңгы көчен ташлады. Кенәз Витовтның атлылары татарлар белән буталышып орыша башлау белән Идегәй мирза алар өстенә үзенең тәҗрибәле баһадирлардан торган төмәнен ыргытты. Сөңге белән коралланган, тимер туннарга төренгән бу атлыларның тиңе юк иде. Алар сугышка бик сирәк керә, әмма аны очлап куя беләләр. Менә алар, ач бүреләр кебек, кенәз Витовт рыцарьларын ботарларга тотынды.

Авыр коралланган татар атлыларының һөҗүме шулкадәр көтелмәгәндә булды, алар дошман полкларын сытып узды, исән калганнарын таратып бетерде. Аннан дошманның артына төшә башладылар. Шул вакыт кенәз Витовт рыцарьлары каушап калды, чолганыштан чыгып өлгерү өчен чигенү ягын карады. Бу сафларның буталуына, максаттан тайпылуга китерде. Рыцарьларның бер өлеше, татарларны туктатырга тырышып караса да, күңелләренә хәвеф инде кереп өлгергән, анда курку тамыр җәйгән иде. Ул һаман үсә, арта барды, сафларны бүлгәли, өзә, тарката торды.

Шул вакыт ярдәм килүдән рухланган Тимер Котлык хан төмәннәре дә яңабаштан эшкә кереште. Аларның дәррәү күтәрелеп орышка ташлануы дошман сафларын тагын да бүлгәләде. Шулай дошман гаскәре идарәсез калды, анда тыеп-туктатып булмаслык буталыш башланды. Күңеленә җан саклау уе килеп кергән, шул уй барысын да күмеп киткән гаскәрне инде бернинди әмер-фәрман да туктата алмый иде. Коралларын, олауларын ташлап, яралыларын сугыш кырында калдырып, дошман качарга тотынды. Сугыш кырын беренчеләрдән булып Туктамыш хан ташлап китте, чөнки Идегәй мирзаның кем икәнен, ничек орышуын ул бик әйбәт белә иде. Аннан яраннары белән кенәз Витовт үзе дә табан ялтыратты. Татарлар дошманның артыннан бастырып бара, качучыларны рәхимсез турый, әсир итә торды. Эш барысына да җитте, эзәрлекләү озак дәвам итте...

Солтан ШӘМСИ

(Дәвамы киләсе санда).

Шомлы еллар кайтавазы...

(Ахыры. Башы 30 нчы санда).

Моны дәлилли торган бер тарихи документ сакланган. Ул – 1934 елның 11 апрелендә ТАССР Арча районы Сикертән авыл Советы тарафыннан бирелгән 108 нче номерлы белешмә. Бу язуның аерым хуҗалык алып баручы Гөберчәк мулласының малае Мәһдиев Габдерәшиткә бирелүе раслана». Әлеге белешмәдәге нибары ике сүз, ягъни Мәһдиевнең атасы мулла булуы һәм аның аерым хуҗалык алып баруын приговор дип санарга була. Ул елларда мондый белешмә тотып кая гына барып керсәң дә, үзеңә рәхим-шәфкать көтмә. Казандагы кайсы гына уку йортына, һөнәр мәктәбенә барып карасалар да, ата белән улны кире борганнар.

Казанда Тукай һәм Сәйдәш урамнары чатында биш-дүрт катлы түгәрәкләнеп килгән бер бина бар. Анда элек һөнәр мәктәбе булган. Бабам этине ияртеп шунда да сугылган, ләкин биредәге мохит, Казан шпаналары вә малай-шалайларның тәртипсезлеген күргәч, алар чыгып китү ягын караган.

14–15 яше тулыр-тулмас, русча бер авыз сүз белмәгән авыл малаена Казан төрмәләреннән этисен эзләп йөрергә туры килә. Сөнгатулла абзыйның исән-имин булуын белергә һәм өйдән әнисе биреп җибәргән ризыкны тапшыру йөкләнгән була аңа. Байтак каңгырып йөргәч, малай авылга кайтып егыла. Берничә айдан гаилә башлыгын азат итәләр. Вакытлыча «кара эшкә» яллапып күпмедер акча юнәтеп, гаиләсен, кече туганнарын ризык белән тәэмин итүгә керешә ул. Акча эшләү юллары да чамалы. Шуларның берсе – урманнан чыршы ботакларын җыеп калага алып барып сату. Кәсеп итүнең бу ысулы «өлкән агайның» дини бәйрәмнәре раштуа, хач ману, пасха көннәренә туры килгән. Урман каравылчысыннан җәберләнүләр, чи ылыс тутырылган капчыкның авырлыгы, тимер юл станциясенә менеп ул капчыкны вагонда яшерү, билет тикшерүче ревизорларның җикеренүләрен һәм кыерсытуларын сөйләп тә, язып та бетерерлек түгел. Бервакыт аны билетсыз йөрисең, житмәсә, багажың да зур икән, дип штрафка тартмакчы булганнар, үсмер югалып калмаган: «Билет алырга акчам булса, мин болай интегеп тә йөрмәс идем, әнә, ылыс тулы капчыклар, алып калыгыз, үзегезгә булсын!» – дип вагоннан төшеп калган.

Сөнгатулла бабайны 1938 елда яңадан кулга алгач, тормыш арбасы Рәбига абыстай белән Габдерәшит җилкәсенә төшә. Салым, төрле займнар түләү – болар барысы да язмыш сынавына әверелә. Алар үз вакытында түләнмәгән өчен егет җәмәгать эшләренә – тимер юл төзелешенә һәм башка төрле мәҗбүри хезмәткә тартыла.

Авылдашлары белән уртакка мал суеп, кала базарына алып барып сату белән кәсеп итеп тә карыйлар. Закон буенча алыш-биреш, спекуляция белән көрәш барган чор, авыл сәвите һәм куштаннар моның белән катгый көрәш алып бара. Капчык төбенә итне салып өстенә вак-төяк тутырып юлга чыкканда бер күршеләре, фәлән абзыйга кертеп бирерсең, дип чемодан белән товар биргән үсмергә, әлбәттә инде, кызыксындыру чарасы да булгандыр. Базарга барып, төенчекләрне чишеп сату итә башлаганнар. Әти, чемоданны күтәреп, теге абзыйның эзләргә киткән, шунда аны милиция эләктерә. Ә чемодан тулы дефицит товар – тәмәке икән, хезмәт көненә бирелгән булган да хуҗасы тартмагач, җыеп барган. Тентү үткәрелә, каян алдың, кемгә илтәсең, дип допрос ясала, милиция бүлегенә алып китәләр. Ырып-ерып йөргесез халык арасыннан барганда эти, бәхетенә, артка кала һәм качып эзен югалта. Авылдашлары сату иткән урынга барып, берсе белән бүреген алмаштыра һәм, үзе алып килгән итне сатып бетерергә кушып, кич Вахитов станциясендә очрашырга сүз куешып, базардан тая. Аллаһның рәхмәте, шулай итеп кулга алынудан, зинданга утыртылудан котыла.

● Сулда – Габдерәшит һәм Сөнгатулла Мәһдиевләр.

Әлбәттә инде, «мулла малае» булуы аркасында, яше тулуга да карамастан, аны армиягә алмыйлар. Бу хакта ачынып сөйләгәннәре хәтердә:

– Безнең буынны паспорт бирмичә интектерделәр, гаиләбезне колхозга алмаганга күрә, 1936 елда Казанга киттем. Вак-төяк эшләргә урнашу өчен «хокуксыз мулла малае» дигән белешмә тоттырдылар. Утыз сигезенче елда армиягә алынырга тиеш идем. Яшем җитсә дә, хокуксыз, дип, мине һаман кичектерә килделәр. Ниһаять, 1941 елның маенда безнең ишеләргә дә чират җитте. Хокуксызларның наборы икән бу. Шунда сөенгәнемне күрсәгез икән: мин дә кеше рәтендә, янәсе!

Сугыш башлана, «халык дошманы» малае дип армиягә алынмаган Рәшитне Эшче крестьян Кызыл Армия сафларына алалар. Ул, сапер-минер булып фронт юллары үтеп, исән-сау кайта. Ә менә оборона корылмалары төзүдә катнашкан Рәкига сеңлесе, үпкәсенә салкын тидереп, 1946 елда вафат була.

Дәһшәтле шәхес культы елларында Рәбига абыстай ире Сөнгатулла хәзрәттән тыш җиде туганын югалткан. Әлбәттә, аларның күбесе гыйлем ияләре, игелек кылучы руханилар булган. Аларның рухына багышлап Коръән-Шәриф укыр идең, догалар кылыр идең, кая җирләнгәннәре дә, каберләре дә билгесез шул.

Шуны истә тотып, Саба районы Түбән Симет авылында, әбиемнең туган нигезендә истәлек билгесе куелды. Бу билгедә Мөхәммәтсафа хәзрәт Яхинның Фәйзрахман (1875–1933), Габдрахман (1881–1944), Габделшәфыйк (1883–1933), Габдерәүф (1885–1945) исемле уллары һәм кызы – Бибирәбига (1891–1971) абыстайның исемнәре язылган. Бу җаваплы эшне шушы авылда гомер итүче мәрхәмәтле затлар, туганнарыбыз башкарган. Монда кардәшебез, шушы авылның имамы Габделшәфыйк Мөхәммәтсафа улы Яхинның оныты Шәймөхәммәт хәзрәт Җиһангировның исемен дә атап үтәргә кирәк. Нәкъ менә Шәймөхәммәт ага бу эштә башлап, оештырып йөргән. Аллаһның рәхмәте яусын аларның барысына да!

Рөстәм МӘҺДИЕВ.

(“Туган җир” журналыннан).

●Җиңү бәйрәме көнне фронтовиклар очрашуында. Рөстәм Мәһдиев этисе Габдерәшит белән Мәскәү өлкәсе Истра районы Снегири авылында.

Зөфәр Низами эше.

Ришат Сәлахетдинов эше.

ТАТАР ШӘМАИЛЕНӘ

Сабан туйлары гөрләп узган вакытта милли мәдәниятнең чын асылын юкка чыгара торган бер аяныч вакыйганы халык сизми дә калды... Әмма сүзне шатлыклы хәбәрдән башлыйк әле.

Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музееның заманча сәнгать галереясында «Шәмаил-арт» халыкара күргәзмәсе ачылды. Зур дәрәҗәдә, киң мәйданда уза торган олуг проектны республикабызның Мәдәният министрлыгы, сынлы сәнгать музее, Татарстан каллиграфларының «Әлиф» берләшмәсе һәм Мәскәүдәге Ш.Мәрҗани фонды оештырган, һәм анда Татарстан, Башкортстан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбургтан 32 рәссамның 200 дән артык эше тәкъдим ителә. Заманча сәнгать галереясының өч каты тулысы белән каллиграфлар иҗатына бирелгән. Шуңа өстәп аерым залда рәссам Ринат Миңнебаевның Мәрҗани фондында сакланган «Ибн Фазланның Итил елгасына сәяхәте» буенча эшләнгән иҗат әсәрләрен, XX гасыр башы басма шәмаилләрне, Санкт-Петербургтан тарих фәннәре кандидаты антрополог Игорь Панковның «Татар намазлыклары» проектын, музеебыз фондыннан милли мәдәнияткә караган экспонатларны күрергә мөмкин. Каллиграфиябез тарихында беренче тапкыр күргәзмәгә аудиогид эшләнгән, саллы буклет нәшер ителгән. Тамашачыларның исәбе-саны юк. Фотографлар чылт-чылт фотога төшерә, каләм әһелләре әңгәмә алып калырга ашыга. Радио, телевидение журналистлары оештыручылар артыннан «ау» оештырып, кайсын, ничек эләктерергә белмичә аптырый. Бу ыгы-зыгыда иҗат эшләрен иркенләп карап булмаса да, күңел мәтәлчек ата. Каллиграфия сәнгатебез шушындый зур дәрәҗәгә җитсен әле!

XVI гасырда Казан алынгач, архитектура һәм башка затлы сәнгатьләр кебек каллиграфия дә юкка чыгарылганын беләбез. Әмма XIX-XX гасырлар чигендә ул яңадан халыкка кайта башлый. 1843 елда Казан университетында Гали Мәхмүдов каллиграфия курслары ача. Беренче типографияләр ачылып, басма шәмаилләр күренә башлый. Басма шәмаилләргә сорау шулкадәр зур булган ки, танылган тюрколог Николай Катанов истәлекләренә караганда, бер басуда 10 меңнән 48 меңгә кадәр шәмаилләр нәшер итә торган булганнар. Әмма 1928-1931 елларда гарәп графикасын латинныкына, аннары кириллицага алмаштыру аркасында, шәмаилләребез кабат юкка чыга яза. Төгәлрәк әйткәндә, каллиграфия сәнгате Казаннан авылларга күченә һәм халык сәнгате буларак кына яши. 1990 елларда шәмаилгә кабат якты көн туа. Әмма ул елларда гарәп телен белүчеләр бик сирәк була. Беренчеләрдән булып гарәп телен өйрәнеп, Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укыган тәүге профессиональ рәссамыбыз Бакый ага Урманчедан дәресләр алып, каллиграфияне рәссам, галим Нәҗип Нәккаш торгыза башлый. Нәҗип аганың Татар гуманитар институтында оештырган каллиграфия дәресләрендә белем алып, шәмаил сәнгатенә яңа буын рәссамнар килә. Бүген бездә утызлап профессиональ шәмаил остасы бар. Белгечләр каллиграфия белән шөгыльләнүчеләрне өч төргә бүлә. Берәүләр Нәҗип Нәккаш кебек традицион рухта иҗат итә. Тагын бер төркем гарәпчә матур язуның бөтен кануннарына туры китереп яза. Андыйларга Россия Ислам университеты каршында каллиграфия үзәген җитәкләүче, матур язуга Төркиядә өйрәнеп кайткан Рамил Насыйбуллов та керә. Рамилнең бер шәкерте Артур Писаренкога быел Болгарда ислам кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан изге Коръән китабын күчереп язуда катнашу хокукы бирүләре Казанда һәм республикабызда профессиональ каллиграфиянең нинди югарылыкка җитүен күрсәтә. Тагын бер зур төркем рәссамнар гарәп хәрефләреннән этәрелеп заманча картиналар иҗат итә. Аларның кайбер хезмәтләрендә гарәп каллиграфиясенең дини төсмерен югалта баруы һәм гарәп графикасына нигезләнгән дөньяви сәнгать барлыкка килүе ап-ачык күренә. Өч төр рәссамнарның да иҗатын үз эченә алган күргәзмә 25 сентябрьгә кадәр эшләячәк.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Шәмсутов турында аерым әйтеп үтәсе килә. Каллиграфия сәнгатебезнең шушы дәрәҗәгә җитүе аның оештыручы буларак тырышлыгына барып тоташа. Рөстәмнең милли үзаңы Мәскәүдә архитектура институтында укыган елларда көчәя. Дипломлы архитектор, Казанга кайткач, университетның татар филологиясе факультетына укырга керә, аны тәмамлагач, татар шәмаилләрен энәсеннән җебенә кадәр өйрәнеп диссертация яклый. Мәчетләр проектлаган, эчке бизәлеш эскизларын иҗат иткән архитектор, рәссам буларак, Рөстәм каллиграфия сәнгатенең дәрәҗәсен күтәрү кирәклеген аңлап, 2004 елда Татарстан каллиграфларының «Әлиф» ассоциациясен оештыра. Артистка тамашачы кирәк булган кебек, шәмаил иҗат итүче осталарыбызга да үз тамашачысын табу, бер-берсе белән аралашу мәслихәт. Шуннан алар бергәләп күргәзмәләр оештыра башлый, хәтта Мәскәүнең Шәрык музеена кадәр барып җитәләр. Казанда зурдан кубып беренче халыкара күргәзмәне оештыргач, батыраеп Кувәйтка баралар. Әмма Р.Шәмсутов моның белән генә дә канәгатьләнәсе килмичә, Казанның нәкъ үзәгендә Кремльдәге Кол Шәриф музеенда татар шәмаиле галереясы ачып җибәрә. 2010 елда була бу шатлыклы хәл. Татарстанда беренче шәмаил галереясын зур өметләр баглап гамәлгә куялар. Татар халкы нинди михнәтләр күргән булса, шәмаил сәнгате дә шундый ук кысу-җәберләүләргә дучар ителде. Әмма ул бервакытта да халык күңеленнән китмәде. Авылларда һәр өйдә шәмаилнең урыны һәрвакыт түрдән булды. Казан үзәгендә галерея ачу шәмаил сәнгатенең түр урынын рәсмиләштерүгә тиң иде. Яшь буын рәссамнар беренче тапкыр шушында шәмаилләрен күрсәтеп, канатланып кайтып китте. Өлкән буын осталарыбыз эшләрен дәвам итәрдәй яшьләрне күреп сөенде. Никадәр яшь иҗатчы галерея аркылы шәмаил сәнгатенә, каллиграфиягә аяк басты. Бүген Р.Шәмсутов галереясының кыйммәте аерата зур булып күренә, чөнки күптән түгел татар шәмаиле галереясын Кол Шәриф мәчетеннән сөреп чыгардылар. Галереяга рәссамнар гына түгел,

● Чулпан Шәрифуллина эше.

● Айзат Минһаҗев эше.

● Ришат Сәлахетдинов эше.

УРЫН БАРМЫ?

төркем-төркем туристлар килә, теләгән һәркем бушлай татар шәмаил сәнгате белән танышып чыгарга мөмкин иде. Коммерсант җитәкчеләребез шундый төшемле урынны татар шәмаиле өчен артык күрә башлаган, мөгаен. Шәмаил сәнгать әсәре генә түгел ләбаса, ул – милли, дини яшәешебезнең бер чагылышы, символы. Фарсычадан «шәмаил» сүзе «изге сурәт» дип тәрҗемә ителә. Изге ядкәребезгә кизәнү бит бу! Мәдәният министрлыгына яклау сорап барырлар иде дә Кремль министрлыкка буйсынмый. Мәдәниятчеләр карамагында булмаса да, Кремль Татарстан җирендә, дәүләтендә урнашмыймыни? Дин әһелләре галерея язмышына битараф түгел, шулай да мәсьәлә әлегә хәл ителмәгән килеш кала бирә.

Галереяның чынлыкта иҗат лабораториясе вазифасы үтәгәнен һичкем колагына да элми. Биредә шәмаил, гарәп каллиграфиясе генә күрсәтелеп калмады, татар тормышы өчен зур әһәмияткә ия башка байтак чаралар үткәрелде. Татар тәлинкәсенә багышланган арт-проектта, мәсәлән, милли тәлинкә тирәсендә тикшеренү булды, осталык дәресләре үткәреп, үзбәк, Кырым татарларыныкы үрнәгендә керамикада милли бизәлеш мәсьәләсенә ачыклык кертергә омтылдылар. Татар орнаменты ничек бар шулай калырга тиешме, әллә аңа заманча сулыш өрү кирәкме, дигән темага түгәрәк өстәлләр, күргәзмәләр үткәреп, милли бизәк мәсьәләсе дә энә күзеннән тикшерелде. Тугра сәнгате шәмаилгә бик якын. Аны ничек игътибардан читтә калдырсыннар?! Танылган осталарыбыз килеп, биредә теләгән һәркемне тугра язарга өйрәтте. Нәҗип Нәккашның шәкерте Әлфия Исхакова исә туристларны тугра сәнгате белән таныштырды. Бүген Англиядәге Джек, Франциядә Луи, Мисырда Амон, Грузиядә Софико, Үзбәкстанда Алишер тугралары диварга элеп хушланалар икән, бу шатлык хисен аларга татар шәмаиле галереясы һәм шәмаил остасы Әлфия Исхакова бүләк итте. Үз исеме һәркемгә кадерле. Туграны кадерле урында саклаулары табигый. Казан, татар иле, татар халкы турында хәтер дә кадерләп сакланачак, димәк.

Бүген шәҗәрә бәйрәмнәре гөрләп үтә икән, бу мәсьәләгә дә татар шәмаиле галереясының зур хезмәте салынган. Хәер, шәҗәрә агачына балта чабу галереяны япканчы шактый алда, милли архивны шәһәр үзәгеннән Столбище бистәсенә сөргәч башланды. Меңләгән шәҗәрә төзегән галимебез Нәҗип Нәккаш бу хакта бик ачынып сөйләде. Архивны ерак җиргә күчергәндә, байтак хезмәткәрләре эштән киткән. Архивта исә теләгән һәркем эшли алмый. Аның өчен җаваплылык хисе өстенә телләр белү дә, гарәпчә укый алу да, үз эшеңә фанатларча бирелү, күңел ачуга корылган дөньяда архивларның әһәмиятен аңлау кирәк. Бүген бу сыйфатларны бик сирәк кешедә очратырга мөмкин. Архивка бер бардың да бөтен мәсьәләне хәл итеп кайттың түгел. Шәҗәрә төзү өчен айлар, еллар кирәк. Ерак юл исә чыгым, вакыт сорый. Менә шулай итеп шәҗәрә агачының тамыры корытыла да инде.

Диния нәзарәте белән берлектә шәмаил галереясында үткәрелгән «Минем гаиләм шәмаиле» Бөтенроссия проектына да тукталмыйча мөмкин түгел. Әгәр дә бу чара оештырылмаса, без бүген Питрәч районы Шәле авылында гомер кичергән Габделхак хәзрәт Бикморатов турында белмәгән булыр идек. «Шәмаил-арт» күргәзмәсендә аның җиде шәмаилен күрергә мөмкин. Хәзрәт иллеләп изге сурәт ясаган. Дәһри, акчасыз заманнардан фермадан пыяла ватыклары ташыган, битум кисәкләрен бензинда эретеп кара буяу ясаган. Гадәттә авылда шәмаилләр авторларының исемнәре сакланмаган. Габделхак хәзрәт – бүген бердәнбер исеме билгеле һәм шундый күләмдә шәмаилләр иҗат иткән автор. Бабасының иҗат эшләрен күргәзмәгә яшь дизайнер Илдар Тажи китереп биргән. «Минем гаиләм шәмаиле» проекты никадәр гаиләләрнең тарихын өйрәнергә этәргеч булды, туганлык җепләрен ныгытты, халык сәнгатен барларга нинди зур мөмкинлек бирде!

Татар шәмаиле галереясы музей түгел, фәнни-иҗат лабораториясе булган икән бит. Биредә теләгән һәркемгә дини китаплар сатып алырга мөмкин иде. Читтән килүчеләр ислам дине турында борчыган һәр соравына җавап таба алды. Профессиональ югарылыкта зәвыклы итеп эшләнгән традицион татар шәмаиле сатыла торган бердәнбер урын иде ул. Мәчет янындагы яки сувенир

● Луиза Фәсхетдинова эше.

кибетләрендәге кытайлар аннан-моннан әвәләгән шәмаилләрне күргән саен җан әрни. Чын татар шәмаиленең хасиятен бетерер ник саталар шуларны?!.

Үз баласыдай якын күргән галереяны япсалар да, Р.Шәмсутов бу зур күләмле күргәзмәне ахырынача әзерләп чыкты. Сентябрь ахырында аны ябарлар. Аннары татар шәмаиле һәм шәмаил осталары кемгә кирәк булыр?

Татар шәмаиле галереясы – халкыбызның милли китапханә, Камал театры, милли архив, «Казан» милли мәдәният үзәге кебек үк соңгы бастионнарның берседер...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● Рөстәм Мөхәммәтҗанов эше.

● Ришат Сәлахетдинов эше.

● Ришат Сәлахетдинов шәмаиленең урта өлеше.

Казанда дүрт көн дәвамында Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды узды. Аның эшендә 35 чит илдән, Россиянең 77 төбәгеннән һәм Татарстан район-шәһәрләреннән килгән 1500 делегат һәм шәрәфле кунак катнашты. Беренче көнне делегатлар һәм кунаклар «Печән базары» заманча татар дизайны һәм татар шәһәр мәдәнияте фестивалендә катнашса, икенче көннең программасында Изге Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгы буенча экскурсия каралган иде. Эшлекле җыеннар «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә ике көн барды. Беренчесендә бирedә Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура утырышы узды һәм делегатлар, секцияләргә бүленеп, җиде дискуссия мәйданчыгында фикер алышты. Съездның пленар утырышы «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгенең И.Шакиров исемендәге концерт залында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашында узды.

Халкыбыз язмышы –

БЕЗ ӘЛЕ КАЯ БАРАБЫЗ?

Съездның дискуссия мәйданчыкларында, тәгаен алганда, «Милли мирас. Татар мәдәнияте: бүгенгесе һәм киләчәге» секциясендә һәм пленар утырышта күтәрелгән төп мәсьәләләрнең берсе татар телен саклап калу турында иде. Соңгы елларда татар мәктәпләре күзгә күренеп кимеде, чеп-чи татарлар яшәгән районнарда да рус телендә белем бирә торган мәктәпләр пәйда булды. Педагогика фәннәре докторы, Россия Мәгариф академиясенең әгъза-корреспонденты Фарис Харисов искәртеп үткәнчә, 1990-2005 елларда милли җанлы шәхесләребез ярдәме белән Казанда гына да 40 татар гимназиясе ачылды, рус мәктәпләрендә татар класслары эшләде, шул чорда күп кенә милли җанлы һәм үз туган телен яхшы белгән белгечләр тәрбияләнеп өлгерде. Тора-бара бу ирешкәннәр барысы да әкренләп бетүгә таба юнәлеш алды. Татар телле гимназияләрне русча белем бирә торган мәктәпкә әйләндерү бик җитез эшләнде, моның өчен аның директорын гына алыштыру да җитә иде. Камәрия Хәмидуллина кебек фидакярләр исә татар мәктәпләрен, уку йортларында милли мохитне саклап калу өчен тырышты. Хәзер Казанда чын татар телле берничә гимназия (2 нче,1 нче гимназия, Г.Ибраһимов исемендәге 4 нче гимназия) генә калды. Әлбәттә, татар телендә укытуны беркем дә тыймады. Әйтик, 2018 елның 5 августында кабул ителгән 317 федераль закон – бик тә үзенчәлекле кануннарның берсе. Аның 14-16 пунктларында ата-аналарга туган тел кысаларында үз телләрен сайлау хокукы турында язылган. Шуның нигезендә, тиешле гаризалар булганда, төркемнәр төзелә. Әмма ата-аналар гариза язган очракта да, баласы 8 нче сыйныфка җиткәннән соң, икенче төрле яза башлый. Нәтиҗәдә быел Балтач районы Норма урта мәктәбе укучысы Әдилә Шәйхетдинова – татар теленнән бердәм республика имтиханын биргән бердәнбер бала булды.

Әмма бу хәл Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгында эшләүчеләрне артык борчымый кебек. Министр урынбасары Минзәлия Закированың съезд ачылышында сөйләгән чыгышындагы битарафлык һәм тынычлык, бер генә проблема да күтәрелмәү шактый гаҗәпләндерде. М.Закирова, Татарстанда гына түгел, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә милли мәгариф үсешенә шартлар тудыру анда яшәүче һәр гаиләгә, һәр балага җиткерү – Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының төп эш юнәлеше булуын искәртте анысы, әмма нәтиҗә генә тәгаенләнмәде. Агымдагы елның 26-27 июнь көннәрендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия съезды узуын, анда күп мәсьәләләр күтәрелүен, төбәкара хезмәттәшлекне үстерү үзәккә куелуын әйтте. «Мәктәпләрдә туган телне өйрәтү һәм саклау максатыннан республикабыз җитәкчелеге, депутатлар корпусы тарафыннан федераль үзәк, Россия Мәгариф министрлыгы белән очрашулар да үз нәтиҗәсен бирә. Уку планнарында дәресләр саны сакланачак. Бүгенге көндә РФнең 28 төбәгендә 1000 нән артык этномәдәни мәктәп татар телен укыта. Телне, мәдәниятне өйрәнү буенча милли татар үзәкләре, иҗтимагый оешмалар, якшәмбе мәктәпләре уңышлы эшләп килә», – дип санады урынбасар. Бу әлегә кадәр алып барылган эшләр икәнлеген, аларның нәтиҗәсе – бер баланың татар теленнән имтихан сайлавын залдагы һәркем аңлый иде кебек. М.Закирова моннан тыш ерак чит илләрдә, Япония, Франция, Кыргызстан, Канадада онлайн татар мәктәпләре, тел курслары эшләвен дә искәртте. Соңгы өч елда Ульян өлкәсендә балалар бакчасы ачу, Төмән өлкәсе, Пермь крае, Мордовия Республикасында яңа мәктәпләр сафка басуы, Түбән Новгород өлкәсендә татар кабинеты ачылу, әлбәттә, шәптер. Чыгышта Самара өлкәсенең «Яктылык» мәктәбенең 25 еллыгын зурлап үткәрү төбәк җитәкчелегенең милли мәсьәләгә мөнәсәбәте күрсәткече икәнлеген дә әйтеп узылды. Самара шәһәренең 7 нче, Чиләбе өлкәсенең Кунашак районы, Мордовиянең Аксюн авылы мәктәпләрендә татар теле укытыла башлау мактауга лаек.

Бер караганда барысы да ал да гөл кебек. Татар теле һәм әдәбиятыннан заман таләпләренә туры китереп, практик юнәлештәге программа эшләнгән, алар барысы да федераль реестрга кертелгән. Төбәкләрдәге милли компонентлы мәктәпләр федераль исемлектәге дәреслекләр белән тәэмин ителә. Әмма татар телен саклау, мәктәпләрдә ана телебез дәресләрен кертү дә милли үзаңы югары булган фидакярләр, директорлар, укытучылар кулында. Бөтендөнья конгрессының телебезне, милли мәдәниятебезне саклап калу юнәлешендә зур эшләр башында торуын күрәбез. Алар милли җанлы милләттәшләребез аша әһәмиятле эш алып бара. Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Илгиз Халиков та бүгенге көндә Конгрессның Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, төбәкләрне аларның гаризасы нигезендә дәреслекләр белән тәэмин итүен дә искә төшерде. Моннан тыш Конгресс икенче ел рәттән төбәкләр өчен 20 шәр татар теле укытучысы әзерләү әмәлен күрә. Татар телен укытуда төбәкләр Самара өлкәсен үрнәк итәргә мөмкин. Андагы мәктәптә туган тел итеп татарчаны сайлаулары турында 90 ата-ана гариза язган. «Үзебездән башлыйк. Инглиз телен өйрәнә торган мәктәптә татар теленә игътибар бирелә икән, икеләтә рәхмәт. Татар милли мәктәпләрен саклап калу безнең кулда», – диде И.Халиков.

Секция утырышында төбәкләрдән килгән берничә чыгыш ясаучы шулай ук милли мәдәниятебезне саклауда «Ак калфак» бөтендөнья татар хатын-кызларының нәтиҗәле эшчәнлек алып баруы турында искәртте. «Милли мирас. Татар мәдәнияте: бүгенгесе һәм киләчәге» секциясе модераторы, галимә Фәнзилә Җәүһәрова да Мордовия Республикасында авылларда татар мәктәбен саклап калуга багышланган утырышлар узуын, хәтта Төмән өлкәсендәге бер мәктәптә мәктәп директорының татар теле укытучысын, рус теленә кагылмыйча, бөтенләй башка бер фәннән белем бирүче итеп тарификацияләп, балаларга татар теле укыттыруының шаһите булуын әйтте. Шушы шартларда без телибезме, теләмибезме үзебезнең телебезне саклау технологияләрен һәм мөмкинлекләрен хәл итү әлеге дә баягы үз субъектыңда милли үзаңлы татарларыбыз кулында. «Беренче сыйныфка кергән бала «Әлифба»ны өйрәнмәсә, аңа икенче сыйныфта ул кирәк булмый. Бала ике түгел, өч-дүрт телне эләктереп алырга сәләтле. Шуның эчендә татар-төрки тел булса, аңа никадәр дөнья ачыла. Ата-аналарның баласының туган теле итеп татар телен сайлавына өметләнергә кирәк», – диде Ф.Җәүһәрова.

Язучы Ринат Мөхәммәдиев – үз вакытында РФнең телләр турында законын съезд трибунасыннан кабул иттергән кешеләрнең берсе. Ул законда милли телләрне кысу, аларны кимсетү турында ялгыш та сүз әйтелмәвен искәртә. Бу законга хәзер дә төрле формада төзәтмәләр кертелә. РФнең телләр турындагы законында, инглиз телле махсус мәктәпләр турында сүз булмаса да, һәр шәһәрдә, районда дистәләгән инглиз мәктәпләре эшләп килә. «Хәзер исә ата-ананың яисә баланың теләге белән татар теле дәресләрен үткәрергә мөмкин дип дигән шартлар куябыз. Ә милли традицияләрнең нигезе – ана теле. Туган телдән башка тәрбияләнгән кеше ул башка кыйблага карый, әйтик, Англиягә, Франциягә карый. Кызганыч ки, инглиз телендәге махсус мәктәпләрне тәмамлаган егет-кызларның берсе дә үзенең киләчәген Россия белән

үзебезнең кулларда

бәйләп күзалламый», – диде Р.Мөхәммәдиев.

Әдип шулай ук залдагыларның игътибарын бүгенге көндә татар телевизион спектакльләрендә сөйләшүләрнең 30-40 проценты рус телендә булуына юнәлтте. Тамаша татар гаиләсендә бара. Әмма татар артистлары русча сөйләшә, мәктәп яшендәге бала, яшь кыз, өйгә кайтып, әбисенә русча дәшә, нәтиҗәдә яшьләр шулай сөйләшергә тиеш кебек фикер килеп туа.

Пленар утырышта Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь һәм драматург Ркаил Зәйдулланың милли мәгариф темасы калку күтәрелгән чыгышы депутатларның иң көчле алкышларына ия булды. Ул халкыбызның инде яртысыннан күбрәге татарчасын югалтуын, белгәннәренең дә теле ярым-йорты гына булуын ассызыклап һәм моның сәбәпләрен дә күрсәтеп үтте. «Чөнки безнең милли мәгарифебез юк кимәлендә, милли мәктәпләр челтәре тар-мар ителде, Бердәм дәүләт имтиханын үз телеңдә бирү мөмкинлеге юк. Ә Федераль дәүләт стандартлары торган саен «камилләшә» бара, инде милли телләргә мәктәпләрдән бөтенләй куып чыгарылу яный», – диде рәис. Ул шулай ук туган телләр рәтенә рус телен кертеп, ата-аналарга аны сайлау хокукы биреп, бик мәкерле эшләүләрен, хәзер күп баланың ата-анасы гына түгел, әби-бабасы да татарча белмәвен дә искәртте. «Алар туган тел дигәндә нинди телне сайласын?! Болар дәүләт тарафыннан ничә дистә еллар дәвам иткән ассимиляция сәясәте корбаннары. Татар теле һәм әдәбияты 10-11 сыйныфларда бөтенләй укытылмый. Димәк, безнең балалар әлеге фәннәр буенча урта белем дә ала алмый», – диде Р.Зәйдулла.

Әлбәттә, Татарстан җитәкчеләре дә, республикадан читтә тупланып яшәгән татарларның кайбер лидерлары да бу турыда уйлана, мөмкинлектән чыгып конкрет гамәлләр кылырга тырыша. Беренче Президентыбыз М.Шәймиев башлангычында полилингваль мәктәпләр булдыру бу юлда зур эш.

Казахстан татарлары һәм башкортлары конгрессы рәисе урынбасары Гриф Хәйруллин татар халкы өчен алып барылган эшләрнең нигезендә милли үзаң торырга тиешлеген билгеләп үтте. «Бу – үз халкыңны югары күтәрү, телен, тарихын, милли үзенчәлекләрен ихтирам итү һәм киләсе буыннарга җиткерү», – диде ул. Ул шулай ук булдыра алып та башкарылмаган эшләребезгә, үз вакытында мөмкинлекләрдән файдаланмавыбызга тукталды. Гөрләтеп татарча укыта торган татар мәктәпләре челтәрен булдырмавыбыз, татар телендә белем бирә торган университет ача алмавыбыз, әлбәттә, безне бизәми. Гриф ага Хәйруллин татар һәм башка милләт кешеләре белән гаилә коргач туган балаларның күбесе татар телен белмәвенә игътибарны юнәлтте. «Баланы мәктәптә дә татар телендә укытмагач, аңа зурайгач та үз туган телендә белем бирмәгәч, ул кем була?.. Төрле киртәләр бар, без - читтәге татарлар Татарстан җитәкчелегенә, татар конгрессына таянабыз. Конгресс дөньядагы татарларны барлап, күтәреп йөри. Сабантуйлар, форумнар оештыра. Без бу эштә актив катнашырга тиеш, бу – безнең бурыч», – ди ул.

МИЛЛӘТ ЮККА ЧЫГА АЛМЫЙ

Татарстан вице-премьеры, Милли шура рәисе, Россия төбәкләрендәге милләттәшләребез белән еш аралашып торучы Васил Шәйхразиев чыгышында халкыбызның матур киләчәгенә ышанычы яңгырады. Ул милләттәшләребезнең һәрвакыт ата-бабалардан килгән рухи бердәмлек көченә тоеп яшәвен белдерде.

«Без үз киләчәгебезне сувенир халык булуда күрмибез. Дәүләт токтан милләт тиз генә юкка чыга алмый. Без ата-бабаларыбызның бөек казанышлары рухына төрелгән газиз җиребездә дөньяга килү, яшәү һәм үз халкыбызга файда китерү бәхетенә ия. Алга таба да тарихыбызны үзебезгә язарга, үз киләчәгебезне үзебезгә төзергә телибез», – диде В.Шәйхразиев.

Ул шулай ук Татарстанны киләчәккә омтыла торган республика дип атады. Ул бирedә яшәү һәм эшләү уңайлы булуын билгеләп үтте. Милли шура рәисе дин һәм милләт аерылгысыз булуын, кайбер төбәкләрдә татар милли оешмаларын дин әһелләре җитәкләвен искәртеп, конгресста дин әһелләре белән эшләү бүлеген булдыруны тәкъдим итте. В.Шәйхразиев шулай ук халкыбызга бик күп асыл сыйфатлар ислам дине аша керүен искә төшереп, Г.Баруди, Р.Фәхретдин, Ш.Мәрҗани кебек олуг шәхесләребезне атап үтте, төбәкләрдәге йөзләгән мәдрәсәләрнең татар милли үзаңын үстерүдә мөһим урын алып торуын әйтте. Меңнәрчә еллар халкыбыз ислам цивилизациясендә яшәп, татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты ислам кыйммәтләре белән үрелеп барган.

ШӘХЕСЛӘР – МИЛЛӘТ ГОРУРЛЫГЫ

Секция һәм пленар утырышларда шәхесләребез, аларның исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе дә күтәрелде. Әйтик, «Тарихи шәхесләр һәм хәзерге заман татар дәүләт эшлеклеләре: милли горурлык тәрбияләү мәсьәләләре» секциясе модераторы, тарихчы-галим Дамир Исхаков, күп төбәкләрдә күренекле, халкыбызга күп игелекләр кылган шәхесләребез булуын әйтеп, аларны барлау, өйрәнү, бу кешеләргә багышланган аерым китаплар булдыру кирәклеген белдерде. Аннары галим Сөембикә шәхесенә бәяне бик уйлап бирергә тиешлегебезне искәртте. Соңгы елларда Садри Максуди, Йосыф Акчура кебек мәшһүр затларыбыз да игътибардан читтә калды. Алар турында сөйләү дә юк, Мирсәет Солтангалиев тә онытылып бара. Казанда аңа һәйкәл дә юк. Утырышта да Казанда тарихи шәхесләргә багышлап конференцияләр үткәрү, һәйкәл кую кирәк дигән фикер кабат-кабат әйтелгән. Д.Исхаков моннан тыш, Казанда Сөембикәгә һәйкәл торгыза алмыйбыз икән, ханбикәнең исемен бер үзәк урамга бирергә кирәклеген ассызыклады. Төбәкләрдәге атаклы татарларның тормышын һәм эшчәнлеген шунда булган музейларда яктырту мәслихәт. Бу уңайдан Милли шура рәисе В.Шәйхразиев та бүгенге каһарманнарыбызны да онытмау, аларны үрнәк итәргә кирәклеген әйтеп узды. «Татар төбәк тарихын һәм татар тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү мәсьәләләре» секциясе модераторы, тарихчы галим Альберт Борһанов утырышта катнашучыларны мәктәпләрдә Татарстан һәм төбәк тарихын укыту мәсьәләсе начар торуы борчуын әйтте. Ул шулай ук урамнарга иске исемнәрен кайтару кирәк, дип исәпли. Милли шура рәисе В.Шәйхразиев, Илһам Шакиров бакыйлыкка күчкәч, аның исемен мәңгеләштерү максатыннан, ике елга бер тапкыр аның исемендәге республика премиясен бирә башлауны искә төшереп, делегатларны бәйгедә катнашырга өндәде. Үзбәкстан вәкиле Рим Гыйниятуллин, Казанда 700 урам булуын, анда Кирпичная, Силикатная кебекләре дә хәтсез икәнлеген әйтеп, үзәктәге Бауман урамы булуын, кем икәнен беркем белмәвен искәртте. «Шул урамга Минтимер Шәймиев исеме куелсын, дип үтенеп сорыйм», – диде ул.

ТАТАРЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРҮ ҖИҢЕЛ БУЛМАДЫ

Республиканың беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиев конгрессның 30 еллыгы белән тәбрикләде. «30 ел элек үз тарихыбызда беренче тапкыр тарихи ватаныбызга җыелган идек. Ул чакта рухи бердәмлегебезне раслау бик мөһим иде. Беренче корылтай Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитетын оештырып, үз бурычын үтәде. Аның беренче җитәкчесе Индус Таһиров безнең өметләрне аклады. Халкыбыз тарихын барыбыздан да яхшырак белә торган күренекле галим милләт каршында җаваплылык тоеп эшләде. Моңарчы күрелмәгән гаять житди гамәлне башлап җибәрү, җайга салуны гыйлемле, булдыклы, көчле кеше генә башкара ала иде. Татарларны берләштерү җиңел булмады. Индус Таһиров, боларны ерып чыгып, вазифасын лаеклы үтәде. Барыбыз исеменнән дә рәхмәт сиңа», – диде Минтимер ага. Ул шулай ук Индус Таһировның эшен Ринат Закиров, хәзер инде Васил Шәйхразиев, Данис Шакиров уңышлы дәвам иткәнен ассызыклады. Беренче Президент шулай ук Идел Болгарстанында җәйге каникуллар чорында, Россия төбәкләреннән дә балаларны чакырып, лагерьлар оештырырга, аларны Идел Болгарстаны тарихы, исламны рәсми кабул ителүнең 1100 еллыгы белән таныштырырга тәкъдим итте.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әле башкарасы эшләр бихисап булуын искәртте. Ул Милли шура рәисе итеп янә сайланган В.Шәйхразиевка да бу хакта белдерде. «Васил Газизовичны мактадылар, әмма биредән «без булдырабыз» дигән хыяллар белән генә китәргә тиеш түгел. Телебез, динебез, гореф-гадәтләребезне саклап калу юлында алып барган хезмәтегез өчен рәхмәт. Глобальләшү чорында үзебезне ничек саклап калырга икәнлекне күрәбез. Телебез, гаилә, динебез бергә барырга тиеш. Мәчетләр намаз укыр өчен генә түгел, гореф-гадәтләрне саклау урыны да булырга тиеш», – диде Р.Миңнеханов.

* * *

Съездда Милли шура, аның рәисе һәм аның урынбасарлары сайланды. Алдынгы милләттәшләребез Президент кулыннан дәүләт бүләкләре алды, резолюция кабул ителде. Утырыш «Туган тел» гимнын күмәк башкару белән тәмамланды. Пленар утырыш съезд исеменә килгән сәламләүләр, Татар конгрессын 30 еллыгы белән котлауларны уку белән үрелеп барды. Барлыгы 46 өлкә җитәкчелегеннән тәбрикләүләр килгән. Алар арасында Россия Президенты В.Путин, Тышкы эшләр министры С.Лавров, Мәскәү мэры С.Собянин котлаулары бар иде.

Сөембикә КАШАПОВА.

Рәссам, график, театр декораторы Павел Беньковның "Татар кызы" ("Мәхкүм кәләш") исемле тиңсез эше 1924-1928 елларда иҗат ителгән.

Морза кызы

Булачак рәссам 1879 елда туа. Аның тормыш шартлары рәссам булып китүне күздә тотмый, чөнки әти-әнисе нибары тире эшкәртү остаханәсе тота. Әмма бала алты яшеннән рәсемнәр ясый башлый. Аның әти-әнисе уларының рәссамлык юлыннан китәргә теләвенә каршы була. Ләкин Павел – нык холыклы, үзсүзле 15 яшьлек үсмер – әти-әнисе рөхсәтеннән башка гына, Казанда яңа гына ачылган сынлы сәнгать мәктәбенә укырга керә һәм анда 1895-1901 елларда белем ала. Павелның әти-әнисе Пермьдә яши һәм уларына гомумән булышмыйлар. 1901 елда Павел Беньков Россия Император сынлы сәнгать академиясе карамагындагы Югары сынлы сәнгать училищесына имтиханнарсыз гына кабул ителә. Кала музейларына йөри, Репин дәресләренә дә җитешә. Яшь чагыннан ук сәяхәт итәргә ярата. 1900 елларда Уралда яшәүче вогул (манси) халкы тормышы белән таныша. Академия стипендиаты буларак, Франциягә сәфәр кыла һәм 1905 елда Париждагы Жюлиан шәхси мәктәбендә бер елга якын дәресләр ала. 1906, 1908 елларда – Италияне, 1908 елда Испанияне күрә. 1909 елда Академия карары буенча рәссам исеменә лаек була. Шул елларда балерина Тарасевичка өйләнә, әмма тиздән гаиләсе таркала.

1909-1918 елларда һәм 1922-1929 елларда Казан сынлы сәнгать мәктәбендә укыта, шәхси дәресләр дә бирә. Бирәдә мәшһүр рәссам Н.Фешин белән бергәләп хезмәт куя. Алар мәктәптә дә, Югары сынлы сәнгать училищесында да бергә укыйлар ич. Холыклары буенча Н.Фешин – йомык, ә П.Беньков, киресенчә, бик аралашучан. Студентлар арасында икесенең дә абруйлары зур. Билгеле, Н.Фешинның таланты югарырак, әмма П.Беньков та аннан калышырга уйламый. Соңрак АКШтагы Н.Фешин ир туганы Павелга хатлар язып, якын дустының хәл-әхвәлен сорап торачак, тик алар инде башка беркайчан да күрешмәячәк. 1911 елда рәссам О.Траубенберг белән гаилә кора һәм 7 ай буе Италия буенча сәяхәт итә. 1912 елда кызлары Наталия дөньяга килә. Киләчәктә ул профессор, фәннәр докторы, геофизика фәне буенча абруйлы галим булып танылачак, язмышын тулысынча фәнгә багышлаячак.

I Бөтендөнья сугышы башланганда оста Италиядә сәяхәттә була һәм зур урау юллар аша Россиягә кайта. Ул инкыйлабка кадәр пейзажлар, портретлар яза, Идел күренешләрен, Казан утарларын, дачаларны сурәтли. 1911-1916 елларда үз әсәрләре белән Казан, Петроград, Римдагы күргәзмәләрдә дә катнаша. 1913-1918 елларда Казан опера театрында хезмәт куя. Инкыйлаб китергән ачлык, җимереклек, эпидемияләрне, болганышны кабул итәлмичә, 1919 елны чигенүче Колчак гаскәрләре артыннан Себергә юл ала. Себер "аклар" кулында булганда, 1919-1920 елларда Омск һәм Иркутск театрларында декоратор булып эшли. Колчак гаскәре тар-мар ителгәч, 1921 елда яңа Казанга кайта. Сынлы сәнгать мәктәбе инде "Казан югары дәүләт сәнгати-техник остаханәләре" дип үзгәртелгән. Шунда укыта башлый. 1923-1925 елларда – Казанның Рус драма театры һәм 1926-1927 елларда Татар академия дәүләт театры белән хезмәттәшлек итә. Берничә татар спектакленең сәхнә бизәлешен үти. Аның декорацияләрен тамашачылар кул чабып алкышлый. 1920 елларда татар мәдәниятенә карата игътибарын көчәйтеп, "Йөк ташучы татар" портреты, "Җеп җегерләүче татар хатын-кызы", "Бәйрәмчә милли киемле татар хатын-кызы", "Артистка Баева портреты" һ.б. әсәрләр иҗат итә.



●Павел Беньков портреты. 1923 ел. Николай Фешин эше.

●Т.А.Попова портреты. 1910 ел. Павел Беньков эше.

●Языково утары. 1914-1916 еллар. Павел Беньков эше.

●Бохарадагы базар. 1929 ел. Павел Беньков эше.

П.Беньков 1922 елда – Революцион Россия рәссамнары ассоциациясенә, 1923 елда Татар ассоциациясенә кабул ителә. Шул елларда ассоциация карары буенча Уралга сәяхәт кыла. 1926 елда Г.Ибраһимов портретын сурәтли. Б.Урманче аңлатмасы буенча, ул – Г.Ибраһимовның дөньяда могҗизаи рәвештә сакланып кала алган иң яхшы портреты. Урманче үзе үк аңа шушы язучы портретын язарга киңәш иткән була. Бу елларда рәссам үз әсәрләрен фотога төшерми, каталог төземи, шунлыктан сәнгать белгечләренә аның әлеге чордагы хезмәтләрен тәгаенләү авыр.

1928 елда ул беренче тапкыр Бохарага сәфәр кыла. Бу аның һөнәри һәм шәхси кризис вакыты белән туры килә. Чөнки аның улы Виктор 1926 елда, 17 яшендә вафат була. Рәссам Рус драма театрында декорацияләрне театр җитәкчелеге теләгәнчә эшләүдән баш тартып, алар белән ачуланыша һәм театрдан китә. Бохараны бер күрүдә ошата, биредә – кояшлы табигать, кәрван-сарайлар, ризык муллыгы, борынгы мәчетләр, Урта Азия халкы... Ул гади һәм гадәти күренешләрне дә тирәнтен һәм нәфис итеп ясаячак әле! Ләкин шул ук вакытта биредәге рәссамнар тарафыннан тәнкыйть сүзләрен дә күп ишетәчәк. Имеш, ул дөрес ясамый.

1929-1930 елларда П.Беньков янә Бохараны, аннары Хиваны, Сәмәркандны күрә. 1930 елда Казаннан Бохарага бөтенләйгә күченә. Ул үлгәнче шунда яшәячәген аңлагандыр, мөгаен. 1931 елдан башлап оста – Сәмәрканд сынлы сәнгать училищесының әйдәп баручы укытучысы, Үзбәкстанның һөнәри сынлы сәнгате үсешенә нигез салачак талантлы рәссамнар буынын тәрбияләүчеләрнең берсе...

Рәссам Казанда ясаган берничә картинасын гына үзе белән ала. Шулар арасыннан "Татар кызы" ("Мәхкүм кәләш") портреты – үзбәк хатын-кызларына күрсәтеп, аларны да рәсем итеп ясарга үгетләү өчен.

1932-1933 елларда ул Үзбәкстан Рәссамнар берлеген оештыруда катнаша. 1939 елда Үзбәкстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеменә лаек була. Вафаты алдыннан, 1949 ел башында СССР Сынлы сәнгать академиясенә мактаулы кандидат итеп тә тәкъдим ителә. Төрле елларда Мәскәү, Казан, Ташкент, Сәмәркандта шәхси күргәзмәләрен оештыра. Сәнгати реализм һәм импрессионизм ысулларын кулланып, совет кончыгышын, җирле хатын-кызлар хезмәтен, базарларны, ишегалларын сурәтли. Пейзаж жанрын да онытмый, берникадәр портретлар да яза. Рәссам сыйфатлы үзбәк халатлары гына киеп, ат җигелгән тарантаска гына утырып йөри. Тик йөрәк чире аның иҗади эшчәнлеген тарайта. Бөек Ватан сугышы башлангач, Сәмәркандка күп рәссамнар эвакуацияләнә. 61 яшьлек П.Беньков Сәмәркандта агитация плакатлары яза, Мәскәү, Ленинград, Киев, Харьков сәнгать институтлары бирегә күчкәнгә күрә, башка иҗатчылар, һөнәри рәссамнар белән дә аралаша. Рәссам 1949 елның гыйнварында, 69 яшендә Сәмәркандта вафат була. Ул укыткан училище, каланың

Хәлимә

●«Татар кызы» («Мәхкүм кәләш»). 1924-1928 еллар. Павел Беньков эше.

● Дус кызлар. Павел Беньков эше.

бер урамы рәссам исеме белән атала (1991 елда аның исемен училищедан алып ташлыйлар)...

“Татар кызы” (“Мәхкүм кәләш”) портреты (120х100 см) бүгенге көндә Ташкентта, Үзбәкстан сәнгатенең дәүләт музеенда саклана. П.Беньковка әлеге портрет өчен Хәлимә Терегулова модель була.

Хәлимә Ибраһим кызы Терегулова исә 1905 елда Казанда алдынгы карашлы мәгърифәтче гаиләсендә туа. Киләчәктә ул музыка тарихчысы, педагог булачак. 1930-1938 елларда 1 нче балалар музыка мәктәбендә укыта. 1938 елда Мәскәүдәге П.Чайковский исемендәге дәүләт консерваториясенең тарих-теория факультетын тәмамлый һәм 1938-1944 елларда Казан музыка училищесында белем бирә. 1945-1969 елларда Казан консерваториясендә Көнбатыш Европа музыкасы тарихын укыта. Ул – татар хатын-кызлары арасында иң беренче музыка белгече. Дистәләрчә фәнни хезмәт язган чын пропагандиста. Аның фәнни эшләренең берсе “XVI гасырдан алып 1917 елның октябренә кадәрге татар музыкасы мәдәнияте буенча очерклар” дип атала. Хәлимә ханым, СССР Композиторлар берлеге әгъзасы буларак, күп хезмәттәше белән аралаша. Аның үз укучылары арасында да танылган иҗатчылар, композиторлар бар.

Сәмәркандтагы рәссамның әлеге портретны һәрчак күз уңында гына тотканлыгы мәгълүм. Чөнки аның никадәр яхшы килеп чыгуын үзе дә аңлагандыр. Портретны күрүчеләр бу әсәрне мактамыйча калмаган. Хәтта XXI гасырда да әлеге портретка сокланып, фотокүчермәсен интернет сәхифәләренә куеп, әлеге образны сурәтләүдә өлге булган татар кызының язмышын белергә теләүчеләр җитәрлек. Ә аның язмышы, сәләтле рәссам язмышы кебек үк, шулай ук җитди сәнгатькә багышланган бит.

Портрет иҗат ителгән чакта Хәлимә кәләш булмаган. Әмма ул кигән кием – бик затлы, Казан татарларының милли костюмы. Хәлимәнең башында – әнисенең купшы калфагы. Моңсу йөзле килеп чыксын өчен, рәссам матур кызны озак итеп ясаган. Билгеле, Хәлимә мольберт алдында бик талчыккан йөз белән дә утырган.

П.Беньков Терегуловлар гаиләсендә еш булган. Алар белән дус булуның да файдасы тигән. Чөнки П.Беньковка Үзбәкстанга күчергә нәкъ менә Терегуловлар киңәш иткән, анда аларның туганнары гомер кичергән һәм бу яклардагы вакыйгалардан хәбәрдар булган...

Булачак модель белән рәссам 1924 елның көзендә танышкан. Хәлимә Терегулова – морза Ибраһим Вәлиулла улы һәм Бибигайшә Мөхәммәтгали кызы Терегуловлар гаиләсендә туган бишенче кыз бала. Аның апалары – Әминә, Мәдинә, Рабига һәм Фатыйма. Әтиләре Ибраһим башкаланың ветеринария институтында укыган, студент вакытында ук Касыймия, Апанай мәдрәсәләрендә – рус теле дәресләрен, мәдрәсә каршындагы мәктәптә табигать белеме, ботаника дәресләрен алып барган, Казан университетының тарих факультетында ирекле тыңлаучы булган. Морза рус, немец, француз телләрен яхшы белгән. 1878-1912 елларда Варшава ветеринария институтына эшкә чакырылса да, чит дәүләткә китәргә теләмәгән. Ул - Казан татар укытучылар мәктәбенә нигез салучылардан. Шунда белем дә биргән. Татар театры оешуын бик хуплаган, башка калаларда да татар мәктәпләре ачуда актив катнашкан, бихисап китаплар тәрҗемә иткән. Ибраһим морза – “Шәрык клубы”н оештыручыларның, анда ачык лекцияләр уку инициаторларының берсе. Ул әлеге клубның идарә рәисе дә булып санала. Аның җәмәгате, галим Мөхәммәтгали Мәхмүтов кызы Бибигайшә (Гайшәбикә) ханым 1868 елда туып, 1940 елда вафат була. Морза исә 1852 елда туган, гомере ахырында, 1920 елда Сәмәрканд педагогика институтының биология кафедрасы профессоры итеп билгеләнгән, әмма 1921 елның ноябрендә шул калада җан тәслим кылган.

1924 елда Хәлимәгә – нибары 19 яшь. Аның озын гомерле апасы Фатыйма портретның ничек язылуын бик яхшы хәтерләгән. Ул: “Әлеге портретта – минем сеңлем!” – дип искә алырга яраткан. Хәлимә Ибраһим кызына, үз истәлекләре буенча, рәссам каршында 6-8 тапкыр озаклап утырып торырга туры килгән. Рәссам баштарак тыгыз толымнарга – чулпылар, нәфис йөзле кызның кулына беләзек өстәргә дә уйлаган, тик соңрак уеннан кире кайткан. Гомумән, Павел Петрович Хәлимәне әнисе Гайшәбикә белән бергәләп сурәтләргә дә ниятләгән, әмма Гайшәбикә ханым чирләп тору сәбәпле, бу теләге тормышка ашмый калган.

Хәлимә Терегулова, гаилә корып, җәмәгате Әхмәт Булатов белән Гали исемле бердәнбер улын үстергән. Гали Булатов – Казан дәүләт төзелеш һәм архитектура институтында да укыган, рәссам һөнәрен сайлаган булган.

Хәлимә ханым 2000 елның 13 ноябрендә, 95 яшендә, Казанда дөнья куйган. Аны һәркем татар хатын-кызларына хас тыйнак, тырыш, зыялы һәм мөлаем ханым буларак хәтерли. Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе укытучыларының берсе: “Хәлимә ханымның оныгының кызлары - Яна һәм Ада Булатовалар хәзерге көндә консерватория карамагындагы урта махсус музыка мәктәбендә белем ала”, – диде.

Морза кызы Хәлимә Терегулованың: “Әгәр берәр рәссам Ташкенттагы шул портрет күчермәсен ясап бирсә, бик шат булыр идем”, – дигән сүзләрен дә онытмыйлар. Тик шедеврның күчермәсен ясарлык рәссам табылмаган. Андый әсәрләрне кабатлау бик авыр!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

13 август (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 20.26 сәгатьтә калка, 6.56 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.14 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Меңьяфрак шифасы (1)

Ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәтеннән интеккәндә, 3 аш кашыгы вакланган меңьяфрак үләнен 1 стакан суда кайнатып чыгаралар, ярты сәгать төнәткәч, сөзәләр, көненә 2-3 тапкыр, ашарга 15 минут кала, 2-3 аш кашыгы эчәләр.

14 август (якшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 20.36 сәгатьтә калка, 8.25 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.10 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Меңьяфрак шифасы (2)

Ашказаны җәрәхәте көчәйгәндә, вакланган меңьяфрак, бака яфрагы, ромашка, сары мәтрүшкә, саз кипкәрен тигез микъдарда кушып, шушы катнашманың 3 аш кашыгын 2 стакан кайнар суга салалар, 5 минут кайнаткач, ярты сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, яртышар стакан эчәләр. Дәва курсы – 1 ай.

15 август (дүшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 20.44 сәгатьтә калка, 9.51 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.06 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Меңьяфрак шифасы (3)

Кислоталылыгы югары булган гастритны дәвалау өчен, 3 өлеш меңьяфрак үләнен 1 өлеш канлы үлән белән кушалар, шуның 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суга салып, сүрән утта 5 минут пешерәләр, 1 сәгать төнәткәч, сөзәләр. Көненә 3-4 тапкыр, ашарга 15 минут кала, 2-3 аш кашыгы эчәләр. Дәва курсы – 3 атна, аннары 1 атна ял итеп, тагын дәваланырга кирәк.

16 август (сишәмбе). ***Мөхәррәм аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 20.52 сәгатьтә калка, 11.14 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.01 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама кырын

Карабодай кесәле

Карабодай ярмасын каһвәтарткычта тарттыралар да (йә иттарткычтан чыгаралар), 3 аш кашыгы онны 1 стакан салкын суга салып болгаталар, кайнап торган 1 литр суга кушалар, болгата-болгата 10 минут пешерәләр. Бераз суынгач, 1 аш кашыгы бал һәм 1 уч вакланган әстерхан чикләвеге кушалар, иртән һәм кичен яртышар стакан эчәләр. Болай дәвалану югары кан басымын төшерә.

17 август (чәршәмбе). ***Мөхәррәм аеның 19 нчы көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 21.01 сәгатьтә калка, 12.36 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 14.57 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Аскаридага каршы

Анарны икегә бүлеп, яртысын 1 стакан кайнар суга салалар, 5 минут кайнатып, 2 сәгать төнәтәләр дә, эчтәге суалчаннарны чыгару өчен, көненә 3-4 тапкыр берничәшәр йотым кабалар. Шул рәвешле 2 анардан ясалган 4 стакан төнәтмәне эчеп бетергәндә, бөтен суалчан чыгып кача. Әмма дәваланырга 1 көн кала кишер согы эчәргә, кишер ашарга кирәк. Мәсәлән, 2 тапкыр 1 әр стакан сок эчәргә, 3-5 кишер ашарга. Кишерне груша белән алыштырсаң да ярый. Ашарга яртысәгать кала ярты стакан тозлы кәбестә суы эчәргә киңәш ителә.

18 август (пәнҗешәмбе). ***Мөхәррәм аеның 20 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 21.12 сәгатьтә калка, 13.57 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 14.53 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

19 август (җомга). ***Мөхәррәм аеның 21 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 21.28 сәгатьтә калка, 15.15 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.48 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Маринадланган помидор

3 литрлы банкага: кирәк кадәр помидор, 1 татлы борыч, 3-4 бүлем сарымсак, 8-10 сабак петрушка, 3 аш кашыгы шикәр, 1 әр аш кашыгы тоз һәм серкә кирәк. Банканы стерильләгәч, төбенә сарымсак, петрушка, дүрткә бүленгән борыч салып, помидорларны тутыралар, кайнар су коеп, 5 минут тоткач, суын кире кәстрүлгә бушатып, шикәр, тоз салып, кайнатып чыгаралар, сүндергәч, серкә һәм 3 аспирин төймәсе салып болгаталар да, банкадагы помидорлар өстенә коеп, тимер капкач белән каплыйлар, калын тукымага төреп суыталар.

Ризаэддин ФӘХРЕДДИН

Әхлак гыйлеме

ВАТАН ҺӘМ МИЛЛӘТ

Күге астында яшәгән, һаваларын иснәп, суларын эчкән вә икмәкләрен ашаган Ватаныгызны сөегез, моның исемен бөек итәр өчен тырышыгыз!

Ватан – адәмнәрнең хөрмәте вә һәркем алдында изге итәчәк бер мактанычы булыр. Шуның өчен, Ватан тугрысында малыгызны кызганмагыз, көчләрегезне аямагыз. Ватан хакында болай фидакяр булмаган кеше анда яшәргә лаек түгелдер.

Ата вә анагызны, якын кардәшләрегезне ничек сөйсәгез – милләтегезне шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга зур табыш дип санагыз. «Милләт» вә «тәрәккыят», ягъни «алга китү»не мәсхәрә итүчеләрнең сүзләрен ишетмәгез, алар – хисләрдән мәхрүм калган мескеннәр вә бичаралардыр. Бәлки аларның үзләрен кызганыгыз вә мондый хәлдә ким калулары өчен хәлләренә мәрхәмәт итегез.

Милләт вә Ватан өчен хезмәт итү насыйп булса, аның бәрабәренә рәхмәт вә бүләк көтмәгез. Бүләк көтү шулай торсын; фараз итик, ягъни күз алдына китерик: милләт сезгә җәфа итсен, сез һич үпкәләмәгез, өстегезгә бурыч булган хезмәтләрдән һаман кире тормагыз.

«Шәһәрләр вә кавемнәр һәр-никадәр миңа җәфа итсәләр дә, минем күземдә генә хөрмәтлеләрдер» дигән гарәп шигырен укыгыз вә моның белән хәтерегезне юатыгыз.

Дин, гыйлем тарату, мәктәпләр вә яхшы эшләр өчен, вә һәрни рәвешчә булса да халыкка ярдәм бирү өчен тырышлык сарыф итү – иң гүзәл гайрәттер, моның җәзасы да – гүзәл җәза булачактыр. Шуның өчен изге вә диндарлык эшләренә, милләт вә дин файдаларына ярдәм бирүне зур табыш санагыз, күңелегез белән сөя-сөя ярдәм бирегез, милләтегезгә гыйлем вә мәгърифәт таратыгыз, araларына дуслык вә мәхәббәт орлыклары чәчегез, дошманлык вә гөнаһ эшләргә ярдәм итешүдән сакланыгыз. Хосусан, милләт зарарына бер хәреф тә сөйләмәгез вә бер нокта да язмагыз.

Милләт файдасына хезмәт итүчеләрне, үзләре белән бер җиргә килеп сөйләшмәстән элек, белер-белмәс, фәкать күкрәгегез тарлык бәласе сәбәпле, төрле-төрле яла ягулар белән каралту теләгенә төшмәгез, кешенең зарарына хөкем итәргә ашыкмагыз, бер кешегә гаеп ташлау вә яла ягуны шәм сүндерү кебек җиңел санамагыз, үз фикерегезнең тугры икәнлеге белән хөкем итмәстән элек, шөбһәгезне гакыл әһелләренә җиткерегез, аларның фикерләрен алыгыз, ихтимал ки үз фикерегез ялгыш булыр.

МӨГАМӘЛӘ ӘДӘПЛӘРЕ

Мөгамәләләрдә әдәпле вә сак булу холкың ризалыгына сәбәп булганы хәлдә, һичбер акча сарыфына да ихтыяҗ булмаячактыр. Мөгамәлә әгәр дә әдәпле булса, иң мөшкел максатлар хасил булыр, бикле ишекләр ачылыр, йомшак сүзләр күңелләрне рәхәтләндерер, ихлас сүз олы бүләкләрдән артык шатлык китерер, ачык йөз вә катлаусызлык, дуслык вә мәхәббәткә дәлил булыр. Шуның өчен, теләсә кем булсагыз булыгыз, адәм балалары белән әдәпле мөгамәлә итегез. Йомшак вә мөлаем сүзле, ихласлы булыгыз.

Күңелсез яки ачулы вакытыгызда халык белән сөйләшмичә, бәлки ачу кызуы сүрелгәнгә кадәр сабыр итегез, адәмнәрнең кимчелекләрен гафу итегез, һәр эштә фикерле вә игътибарлы булыгыз, бу – тәрбияле булу билгеседер.

Адәмнәргә катнашмыйча бер читтә тормагыз вә яки кем очрады исә аңа катышып, дуслык күрсәтмәгез, бәлки һәр эштә гаделлек белән хөр фикерле, дөрес сүзле, баһадир, эчегез вә тышыгыз бер рәвешле булыгыз.

Кешеләрнең усал мөгамәләләренә каршы яхшылык итегез вә яхшы мөгамәләләренә каршы тагын да артык яхшылык итегез, башкаларга күрсәтәчәк мөгамәләгез – алардан күрергә телә-гән мөгамәләләрдән, һәрхәлдә, артык дәрәҗәдә булуына игътибар итегез.

Үзегездән кечкенәләрне түбән күрмәгез, гакылыгыз вә байлыгыгыз белән горурланмагыз, бәлки үз мәртәбәгезне вә башкаларның мәртәбәләрен дә яхшы белеп, һәркемнең үзенә яраклы булган мөгамәләсен күрсәтегез. Бер бөек затның «барча яхшы – без яман» дигән сүзеннән гыйбрәт алыгыз.

Халыктан күркәм мөгамәлә күрергә өметегез булса, үзегез дә аларга яхшы мөгамәлә күрсәтегез. Алардан хөрмәт күрергә теләсәгез, үзегез дә аларга хөрмәт күрсәтегез. «Халыкның дошман булуында хәстәрем юк», – димичә, бәлки дуслыкларны эшкә җигәргә тырышыгыз.

Гакыл әһелләренең күңелләрен үзегезгә каратачак сурәттә булыгыз, максатларыгызны катылык вә куркыту белән түгел, бәлки мәхәббәт белән хасил иттерәчәк бер дәрәҗәдә булырга гайрәт итегез. Халыкларга мәхәббәтле булуыгыз сәбәпле, һичбер камиллегегез югалмас.

Халыкларга күркәм караштa булыгыз, яхшы эшләрне сөйләгез, яман эшләрне яшерегез, әмма үлекләрне исә изгелектән башка нәрсә белән искә алмагыз. Адәмнәр белән мөгамәләгез шундый булсын ки: дөньяда торган вакытыгызда сезне сөйсеннәр, вафат булганыгыздан соң юксынсыннар вә кайгырып еласыннар.

Халыкларга ярдәм бирү фәкать кирәкле вакытларына гына махсус булып, башка вакытта һичкем-һичкем өстенә салынып торуы, ни гакылча, ни шәригатьчә дөрес түгелдер. Шуңа нигезләнеп, адәмнәр өстенә салынмагыз, аларның малларына өметләнмәгез, бәлки үз ризыгыгызны үзегез эзләгез, үзегез өчен үзегез йөрегез!

Ант итүләрегезне саклагыз, вәгъдәләрегезне җиренә җиткереп, дусларыгызга тугрылыклы булыгыз, халыкларның кайгы вә шатлыкларын уртаклашыгыз. Үзегез сөймәгән нәрсәләрне аларга да сөйдермәгез, әгәр дә мөгамәләгез бу нигезгә нигезләнер булса, арада бердәмлек нык булыр, дуслык таралыр.

Халык файдасы вә хак җирләргә ярдәм юлында үткән вакытларны әрәм ителгән вакыт дип санамагыз. Чөнки башкаларны сөю вә аларга ярдәм бирү вә аларның житешмәгән җирләрен житештерү – бөеклек вә адәмчелек билгеседер.

ҖӘМГЫЯТЬ ХАКЫНДА

Гәүдәгездә булган әгъзалар, бер-беренә мохтаҗ булараk вә барлык әгъзалар берлектә сәламәт булулары хәлдә, камил бер кеше булуы кебек, бу дөньяда торган вакытларында, хәтта җәннәткә кергәннәрендә дә барлык адәм балалары тереклек итү тугрысында бер-беренә мохтаҗ булып торалар.

Кешеләрнең бергә җыелулары да кирәкләре табылыр вә хаклары да үтәлер, нәселләре сәламәт калыр. Вә мондый бергә җыелуда әдәп, кагыйдә вә канупнар булып, боларны олылау тиешле була. Шуның өчен бер-берегезне һәрвакыт хөрмәт итегез. Мөгамәләләрегездә инсафлы булыгыз, җыелу кагыйдәләрен җиренә җиткерегез, үз файдагыз өчен башкаларны җәберләмәгез, эшләрегездә тотрыклы булыгыз.

Бергә җыелудан максат – бер кешегә эшләве мөмкин булмаганны эшләү тугрысында ярдәм итешү вә тиешле киңәшләрне бирешү, милләт вә Ватан хезмәтләрен уртаклашудыр.

Шуның өчен мондый сәгатьләрдә ярдәм бирүне вә мондый эшләргә катышуны җаныгызга ярдәм дип белегез, адәм баласы берьялгызы аз булган хәлдә, кардәш вә дуслары белән күптер. Әгәр дә мондый сәгатьләрдә, җәмәгатькә хезмәтегез булмаса, барлыгыгызга нисбәт белән юклыгыгыз тагын артыктыр.

Шәригать боерган өлешләрне дин вә милләт файдасы өчен сарыф иткән затлар, гүя ахирәттә алу шарты белән, Аллаһы Тәгаләгә бурыч бирү кебек булырлар. Шуны исәпләп сез дә, әгәр дә малыгызда мондый чыгачак кисәкләр булса, дин вә милләтне ныгытачак җирләргә сарыф итегез, дөньяда шөкер вә рәхмәт ишетерсез вә ахирәттә бурычыгызны тәмам, бәлки артыгы белән кайтарып алырсыз.

Мөселман кешенең теленнән, кулыннан мөселманнар сәламәт торырлар. Дингә өндәгән мөбарәк, ягъни яхшы сүз – хәтерләрендәдер. Шуның өчен телегез, кулыгыз вә барлык гамәлегез белән мөселманнарны рәнҗетмәгез, юлга чыгудан элек юлдаш табыгыз, йорт алудан элек күрше алыгыз, кеше күлдерәчәк сүзне сөйләмәгез, кул астыгызда булганнарның холык вә фигыльләрен саклагыз.

Кояшлы Резеда

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Резеда Галимова үзенең бәллүр лирик сопраносы, эчке дөньясыннан бөркелгән яктылыгы белән сәхнәне яктыртып торуы белән истә кала һәм аны беркайчан да онытмыйсың, нинди генә чарада, концертта аның чыгышын күзәтсәң дә, кабат шул бәхет сирпеп торган кечкенә кояш белән очрашкандай буласың. Каян килә бу җырчыга шулкадәр гармония, нәзакәтлелек, үз бәянне белү катыш дөньяга сабыйларча гашыйклык?

Тамырлары белән Резеда милләткә Сания Гыйффәт, Гөлсем Камалова кебек затлы ханымнар үстергән Чистай төбәгенә тоташа – әти-әнисе шушы як авылларында туып-үскән. Чистайда алар үз көчләре белән ике йорт салып чыкканнар. Түбән Кама төзелеше башлангач, яшь гаилә нефтехимия төзелешенә күчеп килә, гаиләдә өч бала тәгәрәшеп үсә. Резеда – абый һәм апасының яраткан сеңелкәше, төпчек. Түбән Камада күпмедер эшләгәч, гаиләгә дүрт бүлмәле фатир да бирәләр. Укырга керүгә үк, Резеда музыка мәктәбенә дә йөри башлый. Гадәти торак йортның беренче катында, 4 бүлмәле фатирда урнашкан музыка мәктәбендә ул фортепиано классы буенча укый. Күршеләре аның кечкенәдән җырлавын ишетеп, әти-әнисенә бу хакта әйтеп гаҗәпләндерәләр. Чөнки көне-төне эштә булган ата-ана кызларының җырларга яратканын белми дә йөргәннәр ләбаса. Телевизордан оркестр уйный башласа, кызчык бөтенләй дөньясын оныта… Музыка мәктәбен тәмамлагач, ул Түбән Камадагы музыка училищесына укырга керә. Анда керү бик җиңел түгел, музыка мәктәбеннән соң бер ел буе репетиторларга йөреп әзерләнә кыз. Училищены укып бетереп эшли башлый һәм… шул ук уку йортына вокал буенча кабат укырга керә.

Училищедагы вокал педагогы Вадим Петрович Шургалин аңа «тавышың матур, вокал буенча укырга кирәк» дип гел киңәш бирә торган булган. Кыз башта «укуымны дәвам итәргә вакытым юк» дип каршы килсә дә (музыка мәктәбендә фортепиано дәресләре алып бара), педагог барыбер вакытны җайлый һәм Резеда иртәнге сигезгә вокал дәресләренә йөри башлый. Иртәнге сәгатьләрдә вокал белән шөгыльләнү җиңел түгел, чөнки әле тавыш ярылары уянмаган була. Шуңа күрә дә вокалистлар гадәттә унда, унбердә генә көйли-җырлый башлый. Ләкин Резеданың эш сәгате башланганчы гына вакыты бар... Табигатьтән килгән тырышлыгы, сәләте ярдәме белән авырлыкларга сер бирми: училищены икенче тапкырында өч ел эчендә тәмам итә. Белемгә юл, осталыкны чарлау моның белән генә бетми әле. Күпләр тиз генә сәхнәгә чыгып, акча эшләп калырга омтылган бер чорда Резеда эстрада ягына борылып та карамыйча, укуын дәвам итәргә Мәскәүгә китеп бара. 1992-1998 елларда ул Гнесиннар музыка академиясендә белем ала.

«Вокал буенча мин шулкадәр яратып укыдым. Гел җырлыйсы, яңа әсәрләр өйрәнәсе килә иде. Укытучым бик яхшы, аннан бәхет нуры бөркелеп тора иде. Барлык педагогларым да шундый булды. Алар дөрес, яхшы күңелле, җитди кешеләр иде, беркайчан алардан артык сүз ишетмәсәң, шулкадәр ипле сөйләшәләр, һәрвакыт "Сез" дип мөрәҗәгать итәләр. Алар безнең тәрбиягә нигез салдылар. Вадим Петрович минем алга таба укырга теләвемне хуплады. Ике вариант бар иде: йә Казан, йә Мәскәү. Аның бер укучысы Гнесинкада укый, мин дә Мәскәүне сайларга булдым», – дип искә ала җырчы гомеренең бу кадерле чорын. Гнесиннар академиясенә керүе бик авыр була. Вокал буенча өч имтихан тапшырмыйча торып, анда хәтта документларыңны да кире боралар. Шул имтиханнар аша үтә алсаң гына, документларыңны кабул итәләр. Һәр имтиханга унга якын әсәр әзерлисең, концертмейстер бирәләр, аның белән кабатлыйсың. Ул имтиханнарны үткәч, аннары сольфеджио, гармония һ.б. предметларны тапшырасың. Барысын да үтеп, укырга кабул ителә ул. Резеда читтән торып укый, аңа педагог итеп Оболенская Елена Борисовнаны билгелиләр. Шәкерте аны бик яхшы укытучы буларак зурлап искә ала.

Түбән Камада яшәп, эшләп, киявгә чыгарга да өлгерә, бала туа, аннары җырчы гаиләсе белән Казанга күчәргә дигән фикергә килә. Башкала үзенең кайнап торган мәдәни тормышы, мөмкинлекләре белән кызыктыра. Яшь җырчы филармониягә эшкә урнашырга китә. Анда исә комиссия җыялар, барлык сәнгать җитәкчеләре, дирижерлар каршында имтихан тотарга туры килә. Унлап әсәр башкарганнан соң, Резеданы кабул итәләр. Бу 1997 ел. Эшли-эшли Гнесиннар уку йортын тәмамлый. Филармониянең камера бүлегендә бераз эшләгәч, андагы Халык уен кораллары оркестры җитәкчесе Анатолий Шутиков Резеданы оркестрга солист итеп чакыра. Риза була җырчы, чөнки бу коллектив аның рухына да, башкарган әсәрләренә дә, эчке дөньясына да туры килә. Шул ук елның җәендә ул оркестр белән бергә Германиягә гастрольгә чыгып китә. Бу аның тормышындагы беренче гастрольләр була һәм искиткеч тәэсирләр калдыра! Гастрольләр – артист өчен бәхеткә ишек ачылу кебек бит ул. Нинди юлдагы уңайсызлыклар гына бу бәхеткә күләгә төшерә алмый. Анда һәр артистны аерым гаиләләргә урнаштыралар. Шәһәрнең төрле урыннарында, мәйданнарында чыгышлар ясыйлар. Хәтта чиркәүдә дә җырларга туры килә.

Моннан соң да аңа төрле чит илләрдә Татарстанны танытkан чараларда күп чыгыш ясарга насыйп булды. Җырчы анда үз милли музыкабызның матурлыгын күрсәтергә тырыша. Минтимер Шәймиевнең эш делегациясе составында Һиндстанга бару хәтерендә уелып кала. Илчелектәге дипломатлар, кунаклар каршында чыгыш ясый алар. Ике концерт биргәннән соң, артистларны дөньяның хәзерге могҗизаларыннан берсе булган Тадж-Махал сараена алып баралар…

Резеда Галимова – Илһам Шакиров исемендәге олы бүләкне беренчеләрдән булып алган җырчы. Аңа бөек җырчы белән озак еллар бер коллективта эшләү бәхете насыйп була, бу бүләк шуңа да аеруча кадерле.

– Илһам абыйны күреп белүем белән бик горурланам мин. Аның белән беренче тапкыр 1995 елда «Татар моңы» конкурсында очраштым, ул жюри рәисе иде. Аннары Филармониягә эшкә килгәч, озак еллар аралаштык, Илһам абый анда сәнгать җитәкчесе иде. Ул күп сүзле түгел, ләкин иң кирәк сүзне әйтә иде. Һәрвакыт бик тотнаклы, дөрес кеше. Гомумән, алар буыны кешеләре барысы да: Илһам ага, Әлфия апа, Хәмдүнә Тимергалиева ниндидер аралашу культурасына ия иде. Алар арасында һәрчак үзеңне рәхәт хис итәсең. Илһам абый бервакыт ниндидер концертның репетициясеннән соң мине туктатты да: «Син хәзер бик дөрес җырладың. Менә шушы дәрәҗәңне онытма һәм һәрвакыт шулай җырларга тырыш», – диде. Ул бик игътибарлы иде һәм янымнан битараф кына узып китмичә, үз бәясен белдерде, киңәшен бирде, – дип җылылык белән искә ала җырчы остазларын. – Әлфия апа белән Казахстанга, Үзбәкстанга бергә барырга насыйп булды. Ул шулхәтле яхшы юлдаш, аның белән бик җайлы иде. Урынын белеп кенә сөйләшә. Кирәк җирдә шаян сүзен таба. Хәмдүнә апа да шундый җайлы-рәхәт кеше. Тиз генә чәен дә оештыра, чакырып табынга да утырта, югыйсә мин аннан яшьрәк бит, үзем оештырырга тиеш. Аның булдыклылыгы, үткерлеге бүген нык җитми...

Резеданың репертуарын татар музыка хәзинәсенең җәүһәре булып торган җырлар тәшкил итә. Р.Яхин, М.Мозаффаров әсәрләрен кайсы ил сәхнәсендә җырласаң да, йөзгә кызыллык килерлек түгел. Ә хәзерге яшь композиторлар иҗатына ничек карый икән җырчы?

– Яшьләргә яңа җыр сорап мөрәҗәгать итсәң, алар еш кына «ә син шигырен тап, аннары көй язармын», диләр. Классик җырларны мин текстларында гармония, мәгънә, кешенең тирән кичерешләре булган өчен яратам. Аларны җырлавы рәхәт. Хәзерге текстлар артык гади, тозсыз. Андый ярлы текстлы әсәрләрне җырлавы кызык түгел. Бик сайлап кына алам җырларны. Эльмира Галимова әсәрләрен җырлыйм. С.Сөләйманова, Зөлфәт, Г.Зәйнашева шигырьләренә язылган җырларны яратып башкарам. «Безнең җыр» проектында язылган җырларны да тыңладым. Анда яхшы җырлар да бар, тик аларны яхшы вокал белән халыкка җиткерергә дә кирәк. Гомумән алганда, анда пессимистик рухтагы әсәрләр күпчелек иде. Әсәрләрдә ниндидер эчке сагыш, өметсезлекме сизелеп тора. Әйтерсең лә инде яшәләсе гомер яшәлгән… Яхшы музыка тусын өчен, яхшы текстлар, мәгънәле шигырьләр таба белергә кирәктер. Әйтик, Әхмәт Ерикәй, Гөлшат Зәйнашева кебек шагыйрьләрнең әсәрләре җырлап тора бит. Менә шундый шигырьләргә язылган җырларны башкарырга мин һәрчак әзер…

Эльмира СИРАҖИ.

Аукцион әкәмәтләре

Аукционнарда сатылган сәнгать әсәрләренең күпчелеге киң җәмәгатьчелек өчен бөтенләйгә юкка чыга, дип әйтергә дә була. Гоген, Матисс, Пикассо картиналары ясалма климатлы махсус складларга җибәрелә һәм анда кыйммәтле шәраблар, алтын коелмалары белән бергә бәясе елдан-ел үсә торган банк кертеме сыйфатында саклана. Мондый саклагычлар Люксембургта, Сингапурда һәм Швейцариядә урнашкан. Женевада гына да 1,2 миллион данә зиннәтле сәнгать әсәре яшерелгән. Аларның хуҗалары, үз илләренә алып кергәндә салым түләмәс өчен, мондый "кертем"нәрен читтә саклауны мәгъкульрәк күрә. Картиналар өчен акчаны оффшор компанияләре, траст фондлары күчерә. 150 миллиардер сәнгать әсәрләрен даими сатып ала һәм аларны салымсыз зоналарга яшерә. Язучы һәм сәнгать белгече Дон Томпсонның бер китабында аукционнарның акча капчыкларын ничек итеп үз ятьмәләренә эләктерүе сурәтләнә. Бай клиентларны махсус кабинетларга башкалар күрмәслек итеп урнаштыралар. Мәсәлән, 2014 елда "Кристис" аукционы Нью-Йоркка 18 кытайны алып килгән, алар ике көндә француз импрессионистларының барлыгы 236 миллион долларлык картинасын сатып алган. Кытай миллиардеры Лиу Иджан аукционга Модильяни картинасы өчен 170 миллион доллар түләгән. "Кристис" һәм "Сотбис" кебек данлыклы аукционнарда берничә кичтә 1,5 миллиард долларлык әйбер сатарга мөмкиннәр. Анда эшләүчеләр үзенең өлешен ала, әмма клиент өчен картинаны табучы бәйсез хосусый консультантлар иң күп акча эшли – аларга сатып алучы да, сатучы да алдан килешенгән бәяне түли.

("Bloomberg").

Үзеңә аталган тавык

Бары файдалы ризык кына ашатылган, экологик чиста тавыклы буласыгыз киләме? Алайса Кытайга рәхим итегез! Органик фермерлык биредә инде шактый вакыттан бирле популяр. Иген һәм терлекне болай үстергәндә ясалма ашамлык һәм пестицидлар кулланылмый, хайван азыгына шикле өстәмәләр кушылмый. ZhongAn Technology компаниясендә оештырылган GoGo Chicken хезмәте фермерларга үзләре үстергән тавык турында белешмәне блокчейн (блоклар чылбыры) принцибында эшли торган мәгълүмат базасына язып барырга мөмкинлек бирә. Моның өчен тавыкның тәпиенә кечкенә генә җайланма беркетелә, ул аның яшәү урынын, адымнар санын күрсәтә. Базага кошның кайчан һәм нәрсә белән туклануы да кертелә. Смартфоныңдагы кушымта буенча сатып алучы үзе сайлаган тавыкны фермада чакта ук күзәтә ала. Компания инде 100 мең тавыкка шундый җайланма куйган һәм аларның санын өч елда 23 миллионга җиткерүне планлаштыра.

("The Local").

Йоклый алмасаң, чия аша!

Йокысызлык интектергәндә, организмга бик авыр. Әмма йоклата торган дарулар эчмичә генә дә дәваланып була икән. Моның өчен туклану рационын үзгәртү зарур. Мәсәлән, төче чия һәм чиядәге мелатонин рәхәтләнеп йокыга китүгә булыша. Ясмин дөгесенең гликемик индексы югары булганга, глюкоза канга әкренләп кереп тора, бу исә андагы ике химик матдә – триптофан белән серотонин микъдарын арттыра, алар исә изрәтеп йоклата. Банан В6 витаминына бай, ул исә тәүлек ритмнарын җайга сала торган мелатонин җитештерү өчен кирәк. Ачы шоколадтагы серотонин йокыны китерә. Әстерхан чикләвеге дә мелатонин һәм триптофанга бай. Организмга магний җитешмәгәндә дә йокысызлык интектерергә мөмкин, моннан бадәм чикләвеге ашап котылып була. Ромашка чәендәге глицин нервлар һәм мускуллар киеренкелеген баса. Кәбестә кальцийга бай, әлеге матдә исә баш миенә триптофан эшләп чыгаруда булыша.

("МедНовости").

Искиткеч хәтерле кеше

1886 елда Торжок шәһәрендә туган Соломон Шерешевскийның әтисе китап кибете хуҗасы, әнисе, укымаган булса да, күп белүче, зыялы ханым була. Аның күпсанлы бертуганнары барысы да гади кеше, башкалардан берничек тә аерылып тормый. Башлангыч мәктәпне тәмамлаган Соломонның музыкага сәләте ачыклана, ул музыка училищесына керә, скрипкада уйный. Әмма каты авырудан соң колагы начар ишетә башлый, ул музыкант булудан өметен өзә. Мәскәү газеталарының берсенә репортер булып урнаша. Газета мөхәррире беренче булып аның искиткеч хәтерен искәрә һәм белгечләргә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә. Шерешевскийның хәтерен 1926 елда психолог А.Лурия һәм галим-физиолог, академик Л.Орбели өйрәнә башлый, һәм ул 30 ел буе күзәтелә. Соломон циркка мнемонист булып урнаша, тамашачыларны феноменаль хәтере белән шаккатыра. Бер тапкыр хәтерләгән сүз, гыйбарә, саннарны ул 15-25 елдан соң да онытмый. Шерешевский гаять күп санлы таблицалар, искиткеч катлаулы формулаларны, чит телдәге бик озын текстларны бик җиңел хәтерендә калдыра, аңламаган

нәрсәне җиңелрәк тә ятлый. Соломон күрү хәтеренең үзенчәлекле төре – эйдетизмга ия була. Фән аның хәтеренең нигә шундый шәп булуын күпьеллык тикшеренүләрдән соң да аңлатып бирә алмый.

("Bibliotekar.ru").



Шайтан манарасы

Дэвилс-Тауэр, яки Шайтан манарасы – АКШның Вайоминг штатындагы кыя – кешеләрне әсирләккә ала, кире җибәрмәве дә ихтимал... Моннан 65 миллион еллар элек барлыкка килгән бу кыя Хеопс пирамидасыннан да зуррак булганлыктан, аны шайтан төзегән, дип уйлаганнар, атамасы да шуннан алынган. Тау элек-электән җирле халыкның табыну урыны һәм курку чыганагы булган. Кыя буйлап өскә үрмәләү бик катлаулы булганлыктан, анда нибары ике генә кеше менә алган: XIX гасырда билгесез бер ир-ат һәм 1938 елда профессиональ альпинист Джек Дюранс. 1941 елда тәҗрибәле парашютчы Джордж Хопкинс тау түбәсенә менгән өченче кеше булып танылырга тели, әмма моның бөтен хәвефен бәяләп бетерми. Ул парашюты белән манара башына уңышлы килеп кунаклый, тик аска төшә алмыйча, кыяның әсиренә әйләнә. Бу хакта хәбәр бөтен Америкага таралгач, тау битендә меңнәрчә кеше җыела. Шайтан манарасындагы Джордж телевидение йолдызына әверелә. Озакламый реклама максатында кыя өстендә дистәләгән самолет оча башлый, алар товар җитештерүчеләр исеменнән парашютчыга азык-төлек ташлый. Ашарына күп булса да, кыя әсиренең хәле бетә бара. Хопкинсны коткару өчен махсус оештырылган комиссия тәҗрибәле альпинист Эрнст Филдка мөрәҗәгать итә. Кыяны бер сәгать өйрәнгәч һәм өч сәгать менгәч, ул кире борылырга мәҗбүр була. 8000 метр биеклектәге тауларны буйсындырган һөнәрмәнд 386 метрлы кыя алдында көчсезлеген таный! Шуннан соң Джек Дюрансны эзләп табалар, аның җитәкчелегендәге альпинистлар төркеме кыя башына менеп җитә һәм тәмам хәлдән тайган Хопкинсны махсус әрҗә ярдәмендә җиргә төшерә. Джордж кыя башында барлыгы бер атна яши. Хәзер исә Шайтан манарасы янына ел саен 400 меңгә якын турист килсә дә, шуларның бер проценты гына югарыга үрмәләп карарга җөрьәт итә.

("Daily Mail").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

15 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Заповедники». 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Каравай». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рөстәм Мингалим турында телеочерк. 6+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бергә булыйк!» 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.25, 21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Первая Мировая». 12+
16.30 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МАГОМАЕВ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГРОЗНЫЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Первая невеста империи».
7.30, 15.05 «Крым. Загадки цивилизации».
7.55 Легенды мирового кино. Рудольфо Валентино.
8.25 «КРОВЬ И ПЕСОК».
9.30, 19.00 «Дворянские деньги».
10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Савва Чевакинский. Николо-Богоявленский Морской собор.
10.45 Абсолютный слух.
11.25 Academia. Владимир Мясников. «История востоковедения в России».
12.10, 21.15 «ТУЗ В РУКАВЕ».
14.00 «Евгений Павловский. Как выживать в невидимых мирах».
14.30 «Эрмитаж».
15.35 Музыка эпохи барокко. Василиса Бержанская и оркестр Pratum Integrum.
16.25 «Властелины кольца. История создания синхрофазотрона».
16.50 Цвет времени. Марк Шагал.
17.00 «Книги, заглянувшие в будущее».
17.30 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Валентин Плучек. Места и главы жизни целой...»
23.00 Отсекая лишнее. «Дмитрий Цаплин. Утраченный гений».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.55 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

16 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рөстәм Яхин турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бергә булыйк!» 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+
16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МАГОМАЕВ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГРОЗНЫЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Мой ангел-хранитель - мама».
7.30, 15.05 «Крым. Загадки цивилизации».
7.55 Легенды мирового кино.
8.25 «В РОДНОМ ГОРОДЕ».
9.30, 19.00 «Дворянские деньги».
10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Андреас Шлютер, Жан-Батист Леблон, Никола Микетти. Большой каскад Петергофа.
10.45 Абсолютный слух.
11.25 Academia. Владимир Мясников. «История востоковедения в России».
12.10, 21.15 «ДРУГОЕ ВРЕМЯ, ДРУГОЕ МЕСТО».
13.45 «Игорь Сикорский. Чертежи судьбы».
14.30 «Эрмитаж».
15.35 Музыка эпохи барокко. Уильям Кристи, Пол Эгнью и ансамбль Les Arts Florissants.
16.50 Цвет времени. Леонардо да Винчи. «Джоконда».
17.00 «Книги, заглянувшие в будущее».
17.30 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.45 Письма из провинции. Муром.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 К 90-летию со дня рождения Василия Аксенова. Легендарные дружбы. «Прекрасные черты. Ахмадулина об Аксенове».
21.00 Цвет времени. Рене Магритт.
22.45 «Первые в мире».
23.00 Отсекая лишнее. «Степан Эрьзя. Шаг в бездну».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.55 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

17 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40 «Ком сәгате». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Газинур Морат турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бергә булыйк!» 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+
16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МАГОМАЕВ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГРОЗНЫЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Именем Анны».
7.30, 15.05 «Крым. Загадки цивилизации».
7.55 Легенды мирового кино. Гарри Купер.
8.25 «ПОЗНАКОМЬТЕСЬ С ДЖОНОМ ДОУ».
9.30, 19.00 «Дворянские деньги».
10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Андреас Шлютер, Жан-Батист Леблон, Иоганн Браунштейн, Никола Микетти. Дворец «Монплезир» в Петергофе.
10.45 Абсолютный слух.
11.25 Academia. Алексей Маслов. «Секрет устойчивости восточноазиатской культуры».
12.10, 21.15 «СЫГРАЙ ЭТО ЕЩЕ РАЗ, СЭМ».
13.40 «Николай Федоренко. Человек, который знал...»
14.30 «Эрмитаж».
15.35 Музыка эпохи барокко. Уильям Кристи, Пол Эгнью и ансамбль Les Arts Florissants.
17.00 «Книги, заглянувшие в будущее».
17.30 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 «Слепок судьбы».
22.45 «Первые в мире».
23.00 Отсекая лишнее. «Леонид Соков. Быть необходимым».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.55 «Муслим Магомаев. Возвращение». 16+

Пәнҗешәмбе

18 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40 «Кунак БИТ Шоу». Зәйнәб Фәрхетдинова. 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Әхтәм Зарипов турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бергә булыйк!» 6+
23.05 «Кәмит Җәвит». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+

15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+
16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МАГОМАЕВ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГРОЗНЫЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Свеча горела».
7.30, 15.05 «Крым. Загадки цивилизации».
7.55 Легенды мирового кино.
8.25 «ПОЗНАКОМЬТЕСЬ С ДЖОНОМ ДОУ».
9.30, 19.00 «Дворянские деньги».
10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Адам Менелас, Николай Бенуа, Андрей Штакеншнейдер. Петергоф. Дворцово-парковый ансамбль «Александрия».
10.45 Абсолютный слух.
11.25 К 85-летию Андрея Кончаловского. Academia. Андрей Кончаловский. «От «Черного квадрата» к черной дыре».
12.10, 21.15 «ЭТОТ МЕХ НОРКИ».
13.50 «Дмитрий Чернов. Секрет русской стали».
14.30 «Эрмитаж».
15.35 Музыка эпохи барокко. Сэр Джон Элиот Гардинер, Хор Монтеверди и Английские барочные солисты.
16.30 «Австрия. Зальцбург. Дворец Альтенау».
17.05 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 К 85-летию со дня рождения Александра Вампилова. Больше, чем любовь.
22.50 «Первые в мире».
23.00 Отсекая лишнее. «Вадим Космачёв. Возвращение».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.55 «ПЁС». 16+

Җомга

19 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Җыр - ул хиснең балкышы!» Наил Касыймов турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Родная земля». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.45 «Бергә булыйк!» 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПЯТНИЦА». 16+
14.30 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+
16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Бенефис Любови Успенской на музыкальном фестивале «Белые ночи Санкт-Петербурга». 12+
23.45 «Пространство свободы, или Потом значит никогда. Михаил Шемякин». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ДОРОГИЕ ТОВАРИЩИ!» 16+
23.30 «РАЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Лето Господне.
7.00 «Другие Романовы». «Рождение королевы».
7.30 «Одинцово. Васильевский замок».
8.00 Легенды мирового кино.
8.25 «ТРЕВОЖНАЯ КНОПКА».
10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Иоганн Браунштейн, Жан-Батист Леблон, Франческо Бартоломео Растрелли. Петергоф. Большой дворец.
10.45 Абсолютный слух.
11.25 Андрей Кончаловский. «От «Черного квадрата» к черной дыре».
12.10 «ДВОРЯНСКОЕ ГНЕЗДО».
14.00 «Точка отсчета - планета Земля. Никита Моисеев».
14.30 «Эрмитаж».
15.05 Музыка эпохи барокко. Сэр Джон Элиот Гардинер, Хор Монтеверди и Английские барочные солисты.
15.55 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 Искатели. «В поисках «Неизвестной».
20. «Россия в моём кино». Творческий вечер Андрея Кончаловского.
21.50 «ДВОРЯНСКОЕ ГНЕЗДО».
23.40 Новости культуры.

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.35 «ПРОСТО ДЖЕКСОН». 16+

Шимбә

20 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 6+
13.30 Спектакль «Гайфи бабай, өйлән давай!» 6+
16.20 «Бәхетемне килә табасым». Айдар Рәкыйпов. 6+
17.45 «Бердәм булыйк». 6+
18.00 «Көмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «С ВЕЩАМИ НА ВЫЛЕТ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 14.00 «Җыр - ул хиснең балкышы!» Наил Касыймов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Көмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Су буенда учак яна». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты. 6+
22.20 Спектакль «Хуҗа Насретдин». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30, 14.30 «Карамзин. Проверка временем». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
8.30 «Реки России». 12+
8.55 «МАРАФОН ДЛЯ ТРЕХ ГРАЦИЙ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «УСПЕТЬ ЗА 2 ЧАСА». 12+
15.00 «Русский граф Болгарое». 12+
15.45 «СИНДРОМ ШАХМАТИСТА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЭЙФОРИЯ». 16+
22.45 «КОГДА ЗОВЕТ СЕРДЦЕ 5». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10, 12.15 «Видели видео?»
13.30 «ИСТОРИЯ АСИ КЛЯЧИНОЙ, КОТОРАЯ ЛЮБИЛА, ДА НЕ ВЫШЛА ЗАМУЖ». 12+
15.25 «РОМАНС О ВЛЮБЛЕННЫХ». 16+
18.20 «Андрей Кончаловский. Разрушитель иллюзий». 12+
19.25 РЭБ. 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «ГРЕХ». 16+

«РОССИЯ»

6.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.55 «Доктор Мясников». 12+
13.00 «СВЯТАЯ ЛОЖЬ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВТОРАЯ ПОПЫТКА». 12+
0.55 «ТИЛИ-ТИЛИ ТЕСТО». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.00 Мультфильмы.
7.55 «ОТЕЛЛО».
9.40 «Передвижники. Василий Перов».
10.10 «ГОСТЬ С КУБАНИ».
11.20 Черные дыры. Белые пятна.
12.05 Диалоги о животных.
12.45 Легендарные спектакли Мариинского. Ирина Колпакова и Сергей Бережной в постановке Мариуса Петипа «Спящая красавица».
15.30 «Энциклопедия загадок».
16.00 «Слепок судьбы».
16.45 «Муслим Магомаев. Мои любимые мелодии».
17.45 «Бумбараш». Журавль по небу летит».
18.25 «БУМБАРАШ».
20.35 85 лет Андрею Кончаловскому. «Белая студия».
21.50 «ДЯДЯ ВАНЯ».
23.30 «Мальта».

«НТВ»

4.50 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.30 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.00 Концерт «Все лучшее для вас». 12+

Якшәмбе

21 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Бер язмыш - ике моң». «Фәридә-Алсу» дуэтының юбилей концерты. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Туган авылым». 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Әйләнә деньяә». Ришат Фазлыйәхмәтов концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Күңелемдә бер моң». Рөстәм Асаев концерты. 6+
15.45 «Бердәм булыйк». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Башмагым». 12+
8.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.15, 22.50 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.15 «Туган авылым». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 Спектакль «Беренче театр». 6+
13.00 «Синең өчен сөюләрем». Азат һәм Алсу Фазлыевлар концерты. 6+
15.20 Спектакль «Ул бит кичә иде». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Көмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Яңа сулыш». Айдар Галимов концерты. 6+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30, 15.25 «Карамзин. Проверка временем». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Русский граф Болгаров». 12+
8.45 «СИНДРОМ ШАХМАТИСТА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЭЙФОРИЯ». 16+
14.55 «Путеводитель по вселенной». 12+
15.55 «МАРАФОН ДЛЯ ТРЕХ ГРАЦИЙ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «УСПЕТЬ ЗА 2 ЧАСА». 12+
22.30 «БЛИЗКИЕ КОНТАКТЫ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.10, 6.10 «ИСТОРИЯ АСИ КЛЯЧИНОЙ, КОТОРАЯ ЛЮБИЛА, ДА НЕ ВЫШЛА ЗАМУЖ». 12+
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
7.05 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Муслим Магомаев. Лучший голос Земли». 12+
11.25, 12.15 «Видели видео?»
14.05 К 80-летию Муслима Магомаева. «Эксклюзив». 16+
15.35 «Тамара Синявская. Созвездие любви». 12+
16.30 Концерт, посвященный юбилею Муслима Магомаева. 12+
18.15 «Следствие по путчу. Разлом». 16+
19.10 «Батальон «Пятнашка». На стороне добра». 16+
19.55 «Безумный риск. Часть вторая». 16+
21.00 «Время».
22.35 «ВЕРБОВЩИК». 12+

«РОССИЯ»

5.35 «БЛЕСТЯЩЕЙ ЖИЗНИ ЛЕПЕСТОК». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.40 «СОЛНЕЧНЫЙ УДАР». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.00 Мультфильмы.
8.10 «ДЯДЯ ВАНЯ».
9.50 «Обыкновенный концерт».
10.20 «БУМБАРАШ».
12.30 Диалоги о животных.
13.10 Концерт «Людмиле Зыкиной посвящается...»
15.15 «Мировая литература в зеркале Голливуда».
16.05 «КАК ВАМ ЭТО ПОНРАВИТСЯ».
17.45 К 75-летию Бориса Токарева. Линия жизни.
18.40 «Пешком...»
19.10 К 100-летию со дня рождения Павла Аедоницкого. «Романтика романса».
20.05 К 95-летию со дня рождения Ирины Скобцевой. Линия жизни.
20.55 «ОТЕЛЛО».
22.40 Большая опера.

«НТВ»

4.45 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
10.55 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 Итоги недели.
20.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.45 «ПЕЧЕНЬ, ИЛИ ИСТОРИЯ ОДНОГО СТАРТАПА». 16+

Авыр җинаятьләр кылган япь-яшь кешеләр явызлыгы хәйран калдыра, әлбәттә. Еш кына аларның тумышы һәм тормышы белән танышкач та әлеге вәхшилекләр очраклы түгел, ә бәлки бала чак, яшүсмер вакытлардан ук башлангыч ала дигән фикер туа. Чөнки җинаятьчеләрнең күпчелеге юньсез гаиләләрдән чыга.

Йөгәнсез явызлык

Яшел Үзән каласында туган Владислав Осокин шундыйларның берседер. Башлангыч чорда барысы да ярыйсы гына бара кебек. 2003 елгы малай балалар бакчасына йөри, яше җиткәч, гомуми белем бирү мәктәбенә укырга керә. Тора-бара сәрхушләр гаиләсендә вәзгыять кискенләшә, хатын-кызның ирен пычак белән җәрәхәтләгәне дә була хәтта. 2017 елда ата-ана бердәнбер улларына хокукларыннан мәхрүм ителәләр. Яшүсмер малайның опекуны итеп әнисенең туганнан туган сеңлесе Лилия Абдулхарова билгеләнә. Тагын өч елдан малайның үз әнисе үлеп үк китә, 1980 елгы әтисе Алексей Осокин Яшел Үзәндәге тулай торак бүлмәсендә көн күрә.

Лилия ханым элек-электән ошбу гаилә белән элемтәдә тора, сәрхушләр яныннан малайны ике-өч атнага алып китеп үзе янында яшәткән, шул сәбәпле ата-анада ризасызлык вә ачу-нәфрәтләр уяткан чаклары да була. Әлбәттә, холыксыз эчкечеләрне акылга утырта алмый ул. 7 яшендә хәмер авыз итүен Владислав үзе әйтеп тора, Лилия ханым аның 9 яшендә исерек килеш косып ятуын күрдем, самогонны үзләре эчертә иде, ди. Ул гына да түгел, 10-12 яшендәге Владиславның «БФ» җилеме (?), зажигалкалар тутыра торган баллоннан газ иснәп тилереп йөрүләрен искә ала. Шөкер, наркотик матдәләр кулланганын сизгәнем булмады, ди. Малай җинаятьләр дә кыла башлый. Ике мәртәбә урлап тотыла, беренчесендә 14 яше тулмаганга, икенчесендә зарар күрүчеләр мәрхәмәтлелеге аркасында җәзадан котылып кала.

Әлбәттә, укуы да әйбәт булмый аның. Л. Абдулхарова кечерәк чакта төрле чараларда актив катнашуын әйтә, ләкин үсә төшкәч дәресләргә юньләп йөрмәгән укучы кичке мәктәпкә күчерелә һәм 9 сыйныфны тәмамлавы турында кәгазь алып чыга. Аннан соң Югары Ослан районының Матюшино авылындагы интернатта укый, ял көннәрендә апасы янына кайтып йөри. Һәрдаим күз уңаенда булганга, укуында да уңай якка үзгәрешләр сизелә. 2021 елда 18 яшьлек егет Тәтештәге авыл хуҗалыгы көллиятенә кереп тулай торакта яши башлый.

Техникумга кергәндә, психиатрлар тарафыннан бигрәк тә озак тикшерелә ул. Чөнки 2017 елда ук зур булмаган психик кимчелекләре аркасында исәпкә куелган була, ләкин хәрби хезмәткә яраклы санала. Өстәвенә, төрле тәртипсезлекләре, башлыча, исерек килеш җәмәгать урыннарында йөргән өчен берничә тапкыр административ җаваплылыкка тартылуы да билгеле.

Ике ай ярым Тәтештә яшәгәндә, үзен юньсез яктан күрсәтеп өлгерә егет.

В.Осокинның үз-үзен тотышы, холык-фигыле хакында күбрәк опекун ханым сөйләгәннәр буенча фикер йөртергә туры килә. Чынлыкта, Владиславның бер генә уңай ягын – үзенең кечкенә баласын һәм йорт хайваннарын яратуын телгә ала да, начарлыкларын санап китә ул. Аны, ягъни үзен тәрбияләгән, кайгырткан кешене детдомда торсам яхшырак булыр иде, дип яманларга керешә яисә ник алданрак алмадың, исерекләр янында интектердең дип котырына башлый, бәйләнергә сәбәп таба, бары тик үзен яхшы, ә әйләнә-тирәдәгеләрне начар дип саный икән. Шул ук вакытта Лилия ханым япь-яшь кешене, исергәч эченә иблис оялый дип, котырынкы эчкече итеп сурәтли, әнисе үлемендә гаепләп, әтисен дөмбәсләвен дә әйтә. Ул гына түгел, исерек егетнең дулап, ишекләрне җимереп йөрүләрен тулай-торактагы күршеләр дә сөйләп тора. Кыскасы, ошбу холыксыздан барысын да көтәргә була.

В.Осокин Тәтештән 17 ноябрьдә китеп бара, уку калдырып йөргән өчен ачуланачагын белеп апасы янына кайтмый, әтисе бүлмәсендә пәйда була, Л.Абдулхаровага үзенең кайда икәнен дә әйтми. 23 ноябрьдә атасы Алексей шалтыратып, Владиславның кулга алынуын хәбәр иткәч, ханым тулай торакка килеп җитә. Алексей аңа малаеның Геннадий Хурастеев дигән кунак белән 69 яшьлек күрше картын үтерүен әйтә. Исерек идем, йокладым, күрмәдем, дип сүзен кыска тота.

1987 елгы Г.Хурастеев Самара өлкәсендә туган, бала вакытында гаиләләре таркалгач, ике агайнесе, әнисе белән Ульяновск өлкәсендә үги ата белән яшәгән, берничә елдан бер абыйсы белән үз әтисе һәм үги ана янына кайткан, мәктәпне тәмамлагач, Самарадагы техникумда укыган, хәрби хезмәттә булган. 26 яшендә ике балалы Ирина Семенова белән никахлашкан. 2019 елда үз исеменә яздырылган кызларның олырагын әбисе янында калдырып, кечерәген үзләре белән алып Яшел Үзәнгә килеп урнашалар. Бу калада ел ярым чамасы тулай торак бүлмәсендә А. Осокин һәм 1952 елгы Игорь Евграфов күршесендә яшиләр. Геннадий эчү аркасында шәхси тормышын җайга сала алмаучылар рәтеннән, саташып-котырынып йөрүгә җиткәнче эчеп дәваланган кеше булса да, соңгы вакытта Серго исемендәге заводта эшли, шул ук калада түләүле фатирда яши.

Ирле-хатынлылының әйтүенчә, 21 ноябрьдә Игорь абзыйның хәлен белергә дип килә алар. Сүз уңаеннан, әлеге бабайның да күп еллар элек гаиләсе белән аерылышып, Красноярск өлкәсендә яшәүче балалары белән хәбәрләшмәүче һәм пенсия акчасы беткәнче эчүче карт икәнен әйтеп үтик. 2016 елда ул авыр җинаять кылган, әмма акылга зәгыйфь дип табылып ике ел чамасы мәҗбүри дәвалану узган. Рәсми рәвештә рухи яктан чирле дип табылган И.Евграфовны сеңлесенең кызы Наталья караштырып тора. Ул Геннадий белән Иринаның ошбу сәфәрен абзыйның төрле микрозайм оешмаларыннан кредитлар алып, анда дусты Геннадийның телефон номерын биреп һәм вакытында түләмичә аның өчен мәшәкать чыгаруы белән аңлата. Ләкин тикшерү барышында сәфәр нияте расланмый, ә бәлки карт кешенең берниндиси сәбәпсез исерек ахмаклык аркасында үтерелүе ачыклана.

Полициягә хәбәр 23 ноябрьдә кич белән, мәет тәүлек ярым ятканнан соң гына, Владислав Осокин телефоныннан килә. Мәрхүм тәнендә санап бетергесез җәрәхәт булуы, 22 урыннан кабырга сөякләре сыну, бөер, бавыр һәм башка әгъзаларга зыян килү, баш миенә кан саву, хәтта күкрәгендә пешкән урын булу ачыклана. Соңгысы кызган электр плитәсе куеп яндыру нәтиҗәсе икәне дә мәгълүм була. Җинаять эше аеруча ерткычлык белән газаплап үтерү очрагы буенча кузгатыла. Ошбу явызлыкның кемнәр эше икәне билгеле була.

Владислав шунда ук тоткарлана, Г.Хурастеев биш көн иректә йөри әле. Чөнки икенче көнне хатыны белән Самара өлкәсенә китә, аннан кайтышлый шул ук эчү аркасында үзен начар хис итә башлап, Казанда сырхауханәгә килә, аннан чыгып килгәндә, полиция хезмәткәрләре тарафыннан тоткарлана. Яшел Үзән шәһәр суды аларның икесен дә сак астына ябарга фәрман бирә.

Тикшерү эшләре чагыштырмача тиз төгәлләнә, ике ай дигәндә җинаять эше суд карамагына тапшырыла. Бар да шома гына бармый, иң беренче чиратта, һәркайсының үтерүгә керткән өлешен ачыклау мәшәкатьле була, чөнки хәлсез картны кыйнаганда бик тә батыр кыланган вәхшиләр гаепне бер-берсенә аударырга тырышалар, кызганып кына суктым, үтерерлек итеп типмәдем дип, гаепләрен кире кагалар, туктаусыз күрсәтмәләрен үзгәртәләр. Ләкин тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Е.Ә.Ергизова барысын да үз урыннарына куя.

Фаҗигале вакыйганы, башлыча, рәсми нәтиҗәләр һәм, әлбәттә, шаһитләр күрсәтмәләре нигезендә сурәтлик. Кунаклар элеккегә күрше янына салмыш хәлдә, бер ярты кыстырып килә. Алдагы көнне пенсия алган хуҗа да көндез аталы-уллы Осокиннар белән сыйлана. Игорь бүлмәсенә сыра тотып Владик белән Алексей килеп керә, бераздан мәҗлес алар торагында дәвам итә. Эчә торгач, хәмер чишмәсе кипши, Игорь вахтердан аракы алу ниятеннән беренче катка төшә, аңа салмыш Ирина да ияреп, әйтүенчә, аек чагында да авыр хәрәкәтләнүче бабайны озата бара. Ләкин юллары уңмый аларның.

Аракыны исә яшь сәрхуш белән кунак Гена алып кайта. Шактый гына утырганнан соң, исенә килгән соңгысы өстәл артында хатыны булмауны күрә, аның Игорь карт белән чыгып киткәннән соң кире кайтмавын аңлый, анысы Ирина юкка чыгу сәбәбен әйтә алмый. Бу инде ярсу сәрхуштә көнләшү хисләре уятмый калмый.

Чынлыкта, Ирина бабайны лифтка утыртып югарыга озаткannan соң, өенә тәпили, әйтүенчә, бөтенләй исереп егылудан курка. Төннең икенче яртысында 35 яшьләрендәге тагын бер сәрхуш хатын иярткән Гена белән Влад пәйда була. Алар алып кайткан ике литр аракыны эчеп утырганда, В.Осокин бик зур батырлык кылган кеше кыяфәте белән бабайны «шәпләп» дөмбәсләп ташлауларын әйтеп мактанып ала. Иринага моны аның телләнүе нәтиҗәсе икәнен дә искәртеп куя.

Бу юлы озак утырмый алар, хуҗабикә көнләшә башлау сәбәпле алдан сәрхуш хатын чыгып китә, аннан соң хуҗаларны кунакка дәшкәндәй итеп, Осокин да кузгала. Инде әйтелгәнчә, Ирина белән Геннадий иртә белән Казанга, аннан Самарага юл ала, димәк ки, калган аракыны аталы-уллы сәрхушләр эчә, ә күрше бүлмәдә шешәдәш карт мәете ята. Икенче көнне кич белән генә күрше хатыны Игорьның коридорда йөргән мәчесен кертергә кушкач, исерек егет аның ишегән ача һәм үзләре явызлыгы нәтиҗәсен күрә.

Тикшерү барышында ачыкланганча, бәрелеш көнне Г.Хурастеевтан башлана, чөнки иң алдан берничә тапкыр сугып хәлсез картны ул идәнгә ега, бу эшкә бер катнашы булмаган В.Осокин аңа «ярдәмгә» килә. Икесе ике аягыннан тотып аны башта коридорга, аннары үз бүлмәсенә өстериләр һәм рәхимсез рәвештә типкәлиләр, яшь явыз ике конфоркалы электр плитәсен кыздырып идәндәге ярым аңсыз хәлдәге абзыйның өч мәртәбә күкрәгенә көйдереп тә ала. Законда «аеруча кансызлык» дип аталган бу гамәлен танымый ул.

Яшел Үзән шәһәр суды аларның үләрлек итеп кыйнамадык дип торуларын да нигезсез дип таба һәм В.Осокинны 9 ел ярым, ә Г.Хурастеевны 9 елга ирегеннән мәхрүм итәргә карар кыла. Хөкем гамәлгә кермәгән әле. Җинаять эшенә Татарстан Югары судында нокта куелачак.

Наил ВАХИТОВ.

Татар күлмәген күреп кал!

Казан Кремленә кергәч тә, уң якта, министрлыклардан бушаган һәм яңартылган җәмәгать бинасының беренче подъездында, Милли костюм театры ачылгач, әй шатланган идек. Чөнки, республикабызның башкаласы Казанда татар костюмын көпә-көндез шәм кабызып эзләсәң дә табып булмый. Милли музейдагы хайван скелетлары татар мәдәнияте турында бирәр нинди мәгълүмат бирсә икән...

Милли костюм театрының экспозициясе зур булмаса да, анда XV-XVI гасырлар затлы катлам хатын-кызлары костюмын да, XVIII-XIX гасыр шәһәр туташ-ханымнарының классик милли күлмәкләрен дә күрергә мөмкин. Костюм реконструкцияләренең беришен «Милли хәситә» иҗат берләшмәсе башкарган, кайберләре «Туран Арт» оешмасы архивыннан алынган. Рәссамнардан Елена Гыймранова исеме истә калган. Алтын белән чигүче Луиза Фәсхетдиновадан башка затлы татар костюмын җиренә җиткереп бизәкләп буламы соң? Костюмнар янында күннән эшләнгән дивар панновлары, сандык, мендәрчекләр экспозицияне тулыландырып, үткән гасырлар интерьерын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Аларны Н.Фешин исемендәге сәнгать училищесында күн остасы Әлфия Җәмиловадан дәресләр алган Камилә Зыятдинова, Анастасия Колесова, Йолдыз Гәрәева, Ләйсән Нәҗмиева башкарган.

Экспозицияне республикабызның Мәдәният министрлыгы, «Казан Кремле» һәм «Мисс Татарстана» иҗтимагый оешмасы оештырган. Тантаналы ачылышта министрыбыз Ирада Әюпова әлеге чараның беренче карлыгач кына булуын, киләчәктә яңа дизайнерларны, туристлар төркемнәрен җәлеп итеп, аны кинрәк җәелдерү кирәклеген әйтсә һәм «Мисс Татарстана» җитәкчесе Изольда Сахарова музыкант, җырчы, биючеләрне катнаштырачакларын вәгъдә итсә дә, беренче күргәзмә шундый кыска булыр дип кем уйлаган? Сәнгать белгечләребез, галимнәребез дистә еллар буе даими эшли торган милли костюм күргәзмәсе кирәклекне әйтеп килде. «Милли хәситә», «Туран Арт» берләшмәләренең ничә еллык эшчәнлеге тупланган шушы күргәзмәдә! Урыны да шәп – Казаныбызның үзәгендә, Кремльдә. Шундый күргәзмәнең гомере нибары тулыр-тулмас дүрт ай булырга тиеш идеме? Дөрес, бирелдә ачылганнан бирле байтак чаралар узды. Бәйрәм көннәрендә костюмнар бушлай күрсәтелде. Чечен Республикасы мәдәният министры А.Кадыров килгәч, беренчеләрдән булып затлы татар күлмәкләрен күрсәтергә алып бардылар. Күптән түгел «Мәдәни код» II Этно-fashion халык иҗаты һәм гамәли бизәү сәнгате фестивале атна буена биредә узып, Россиянең төрле шәһәрләреннән җыелган дизайнерлар өчен яраткан урынга әйләнде. Әмма бу кыска вакыт эчендә күргәзмәне югары даирәләр һәм дәрәҗәле кунаклар гына күреп өлгергәндер. Сәнгать уку йортларында белем алучы студентларыбызның имтиханнары, аннары каникулларына туры килде. Бүген экспозицияне ябарга санаулы көннәр калып бара. Белгечләребез хыялланган даими күргәзмә шушы булдымы? Яңасы кайчан оештырылыр әле. Затлы күлмәкләр бер көндә тегелми. Бер костюмны фәнни өйрәнеп реконструкцияләү өчен айлар-еллар кирәк.

Сүз уңаеннан, Милли костюм театры белән күрше бүлмәдә Коръән һәм намазлыклар күргәзмәсе дә эшли. Өчесе дә Болгарда ислам кабул итүнең 1100 еллыгына оештырылган. Милли костюм театры Кремльнең рекламасында берникадәр күренгәләсә, Коръән һәм намазлыклар турында күбебез белми, ишетми дә калгандыр. Затлы сәнгатебезне шаулатып күрсәтә белергә дә кирәк. Бәйрәмнәр уза, милли хәзинәләребез һәрвакыт күз алдыбызда булсын иде...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:
222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 12.08.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2765

16+